ОНЛАЙН АВЫЛ

Якташлар «Инстаграм»да аралаша

> 5

НӘРСӘ БУЛДЫ СИҢА, КҮҢЕЛ?

Тормыштан ямь таба алмаучыларга гади киңәшләр

> 6

КЕШЕНЕКЕ КИЛЕШӘ

Россиядә кулланылган кием-салым сатып алучылар арткан

> 7

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 1 (28774) | Чәршәмбе | 5 гыйнвар | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены беләν бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

Рәмис НӘҖМИЕВ

БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ:

ШӘВӘЛИГӘ АЛМАШ БАРМЫ?

Ә синең яраткан героең кем? Мөгаен, балаларга иң еш бирелә торган сораудыр бу. Бигрәк тә Чыршы бәйрәменә әзерләнгәндә. Балалар геройлары кайларда «яши» соң? Кайсы китапларда, кайсы фильмнарда? Татар балалар китабы фильмга кайчан дәгъва кыла алыр икән? Гомумән, татар балалар әдәбияты ни хәлдә? Балалар әдәбиятына катнашы булган кешеләр белән әнә шул хакта сөйләштек.

> 18

РАШТУА БӘЙРӘМЕ КОТЛЫ БУЛСЫН!

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм МИҢНЕХАНОВның Раштуа бәйрәме уңаеннан КОТЛАВЫ

Православие динендәге хөрмәтле ватандашлар!

Бик борынгы заманнардан, ике мең елдан артык вакыт дәвамында дин тотучыларның йөрәгенә илаһи нур өсти торган ямьле Раштуа бәйрәме уңаеннан һәрберегезне ихластан тәбрик итәм.

Ерак һәм серле Фәләстыйн җирләреннән пәйгамбәрләр тараткан хәерле хәбәрләр миллионлаган христианның күңелендә бакыйлыкка, гөнаһлардан котылуга өмет уята, аларның язмышында һәм хәтта кешелек тарихында үзгәрешләр, борылыш китереп чыгара. Лев Мей – XIX гасырда яшәгән рус шагыйре – Христосның дөньяга килүен: «Галәм ярлыкау көткән бер мәлдә, Вифлеемда мәдхияле җырлар яңгырый, шул чакта күркәм бер сабый туып, җиһанга нур чәчә», – дигән тантаналы сүзләр белән тасвирлый.

Хакыйкатьнең асылына төшенеп һәм Иисус Христосның тиңдәшсез батыр гамәлен аңлап, төрле илләрдә һәм кыйтгаларда яшәүчеләр, җәмгыятьнең төрле катлау вәкилләре, яше-карты – барысы да дини инануга салынган иң тирән мәгънәләрне ачуга, рухи хөрлеккә ирешәләр, аларга Илаһтан мәхәббәт һәм мәрхәмәт сабаклары иңдерелде. Православиедә Раштуаны гадәттә һәркем могҗиза көтеп каршы ала, һәм ул, һичшиксез, чынга аша һәм көндәлек гадәти тормышка бәйрәм төсе бирә: бу көнне күмәкләп догалар кылына, гаиләләр мул сыйлы табыннар тирәсенә җыела, балалар уйный, сөенә, йортларда ямь арта, муллык, иминлек хакимлек итә. Бу катлаулы һәм каршылыклы заманда безгә болар барысы да аеруча тансык.

Төрле милләт вәкилләренең һәм төрле дин тотучыларның килешеп яшәве барыннан да кыйммәтлерәк дип танылган Татарстанда Раштуа башка дини бәйрәмнәр белән беррәттән игелекле гамәлләр кылу, үзара хөрмәт-ихтирам шартларында билгеләп үтелә. Узган елда республикабызның дини тормышында күп кенә мөһим вакыйгалар булды. Мәскәү һәм бөтен Русия Патриархы Кириллның Богородица монастыренда яңадан торгызылган Казан Мәрьям Ана иконасы соборын изгеләндерүе – шуларның иң күренеклесе. Сүз дә юк, бу – безнең уртак казанышыбыз, рухи яңарышка, милләтләр һәм диннәр арасындагы тынычлыкка, дуслык-татулыкка омтылуыбыз гәүдәләнеше.

Яңа ел безнең бай рухи һәм иҗади мөмкинлекләребезнең тагын да киңрәк мәйдан алуына ярдәм итәр, тулаем республикабызга һәм, аерым алганда, һәрберебезгә яңа уңышлар, зур җиңүләр китерер дип ышанам.

Сезгә нык сәламәтлек, бәхет, хәерле озын гомер, бәйрәмне күтәренке кәеф белән уздыруыгызны телим!

Районнарда ни хәлләр?

Әлки

Район ЗАГС бүлеге белгече Розалия Сафина әйтүенчә, узган ел никахларын теркәүчеләрнең иң олысына – 70, кәләшенә 62 яшь икән. Моңа кадәр икесенең дә гаиләләре булган.
– Олы яшьтәгеләрнең, ялгызлыктан котылып, гаилә корулары аеруча сөендерә. Статистика күрсәткәнчә, тулы гаилә булып яшәүчеләрнең гомере ялгызакларныкына караганда шактый озынрак, – ди ЗАГС хезмәткәрләре.
Иң яшь кәләшләргә 18 яшь булган, ел дәвамында шундый өч кыз кияүгә чыккан. Гомумән, былтыр 77 никах теркәлгән. Кызганыч, аерылышучылар саны борчый: 2021 елда 48 гаилә таркалган.
(«Әлки хәбәрләре»)

Алабуга

Киләсе елда Алабугадагы ат спорты мәктәбе үзенең 25 еллыгын билгеләп үтәчәк. Юбилей алдыннан зур төзелеш башланган. Мәктәп директоры Ильяс Горбунов сөйләвенчә, төзелеш эшләре киләсе елның җәендә төгәлләнергә тиеш, хәзергә алар 50–60 процентка үтәлгән.
– Республикада ат спорты төре үсештә, шуңа да «Татнефть» безнең мәктәпне яңартуга матди ярдәм бүлеп бирергә булды. Без эшнең зур күләмен башкардык, алдагысы да җитәрлек, – ди ул.
Мәктәпне киңәйтеп, үзгәртеп корганнан соң, бу спорт төре белән тагын да күбрәк кешеләр шөгыльләнә алачак.
(«Алабуга нуры»)

Түбән Кама

Түбән Камадан 26 чакрым ераклыкта яңа аттракцион ачылган. Сухарево җирлегенең Сименеево авылында чана шуу өчен 150 м озынлыктагы махсус тау булдырганнар. Теләгән һәркем текә таудан чана шуа ала хәзер.
Ачылыш көнендә таудан 150ләп кеше шуарга өлгергән инде. Мондый аттракционның авылда пәйда булуы очраклы түгел. Авылның өлкән яшьтәгеләре элегрәк биек таудан шуып уйнауларын әле дә хәтерли. Уртак көч белән шуу мәйданчыгын яңадан төзекләндерергә насыйп булган.
(e-nkama.ru)

Апас

Район мәдәният йортында 50, 55, 60 ел бергә гомер итүче үрнәк парларны хөрмәтләделәр. Алар өчен «Ак карларга салынган эзләр» дигән бәйрәм чарасы оештырылды.
– Шатлыкларны да, авырлыкларны да бергә кичереп, пар канат булып, шушы көнгә кадәр килеп җиткәнсез икән – моңа сокланмый мөмкин түгел, – диде район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Луиза Сафина.
Районның ЗАГС мәгълүматлары буенча, узган елның икенче яртыеллыгында 10 пар алтын туйларын билгеләп үткән. Зөбәрҗәт туйларын (55 ел) 12 пар каршылаган, 10 пар, 60 ел бергә гомер итеп, бриллиант туйларына җиткән. Өлкәннәргә түбәтәй, шәл һәм Рәхмәт хатлары тапшырдылар.
(«Апастово-информ»)

БЕРЕНЧЕСЕ – БОЛГАРДА

Болгарда россиякүләм мөселман җыены ачылды. Ул Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы кысасындагы тәүге чара булып санала. Шулай итеп, ил һәм Татарстан күләмендә әлеге мөһим тарихи датаны билгеләп үтүгә старт бирелде.

Болгардагы җыенга килгәндә, ул Россия мөселманнары корылтае рәвешендә үтәчәк. Анда катнашу өчен, Татарстан, Мәскәү, Ленинград һәм Свердловск өлкәләре, Кузбасс, Башкортстан, Мари Иле республикаларыннан һәм башка төбәкләрдән дин кардәшләр җыелган. Җыен 4 көн – 8 гыйнварга кадәр дәвам итәчәк. Катнашучыларны күренекле белгечләр, галимнәр, вәгазь сөйләү осталары белән очрашулар, лекция, остаханәләр, спорт чаралары көтә.

Җыенның төп вакыйгасы бүгенгә – 5 гыйнварга туры килә. Форум катнашучыларын Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин сәламләр һәм олы юбилей вакыйгасы турында сөйләр дип көтелә. Аннан соң Россия ислам институты ректоры, Россиянең ислам мәгарифе советы рәисе Рәфикъ хәзрәт Мөхәммәтшин белән очрашу узачак. Ул Россиядә ислам тарихы, шулай ук Идел буе Болгар дәүләтендә 922 елгы вакыйгаларның сәбәпләре һәм әһәмияте хакында лекция укыячак.

dumrt.ru

Җыен күп кенә премьералар белән дә истә калачак. Әйтик, бирелдә тәүге тапкыр «Ибн Фадлан» документаль-нәфис фильмының трейлеры һәм «Хозур ТВ» телеканалында татарчага тәрҗемә ителгән «Билал» мультфильмын күрсәтәчәкләр. Җыен кысасында «Туган батыр» милли проектын тәкъдим итү күздә тотыла. Ул, татар батыры образын торгызу максатыннан, «Туган авылым» комплексы белән берлектә тормышка ашырыла.

ЮЛБАРЫС ЕЛЫ: ҮЗГӘРЕШЛӘР

Быел күп кенә яңа законнар, кагыйдәләр үз көченә керә. Шуларның иң мөһимнәренә тукталып үтәбез.

Пенсияләр һәм иң кечкенә хезмәт хакы

Ел башыннан пенсиянең иминиятләштерелгән өлеше 5,9 процентка арта. 2022 елның 1 гыйнварыннан аның күләме 6401 сум тәшкил итәчәк.

Моннан тыш хезмәткә түләүнең минималь күләме (МРОТ) һәм яшәү минимумы күләме үсә. МРОТ – 13890 сумга, җан башына яшәү минимумы күләме 12654 сумга җитәчәк. Шулай ук, инфляциягә карап, ана капиталы күләмен арттыру да күздә тотыла.

2022 елда эшсезлек буенча пособиенең минималь күләме – аена 1500 сум, максималь күләме беренче өч айда – 12792 сум һәм шуннан соңгы өч айда 5000 сум тәшкил итәчәк.

Байлар һәм сәрхушләр күбрәк түли

Банкта 1 миллион сумнан артыграк акча саклаучылар салым түли башлаячак. 13 процентлы салым бер яки берничә депозиттагы акчадан (барысы бергә 1 миллион сумнан артып китсә) кергән процентларга салына.

Шулай ук 1 гыйнвардан алкогольле барлык эчемлекләргә ГОСТлар үз көченә керә. Хәмер базары белгечләре әйтүенчә, бу хәл хәмер бәясе үсүгә китерәчәк.

IT-компанияләр вәкиллекләрен ача

Ел башыннан чит илләрнең IT-компанияләреннән Россиядә тулы кыйммәтле вәкиллекләр ачуны таләп иткән закон гамәлгә керә. Бирелдә тәүлегенә 500 меңнән артык кешене үзләренә җәлеп итүче гигантлар – Google, Apple, Meta Platforms, Twitter, TikTok, Telegram, шулай ук Zoom, Viber, Spotify, Likeme Pte. Ltd, Discord, Pinterest һәм Twitch турында сүз бара.

Закон, мондый компанияләргә Россиядә офислар ачудан тыш, башка таләпләр дә куя. Әйтик, аларга үзләренең сайтларында кешеләр белән кире элемтәгә керү мөмкинлеген күздә тотарга кирәк булачак.

Агачны чит илләргә сату тыела

Ел башыннан эшкәртелмәгән агачны чит илләргә сату тыела. Президент Владимир Путин инде июль аенда ук Хөкүмәткә бүрәнәне читкә озатуга каршы катгый чаралар күрергә кушкан иде. Моңа кадәр агачны экспортлауга каршы көрәш зур күләмдәге пошлиналар билгеләү рәвешендә алып барылган. Әйтик, 2019 елда пошлина товар бәясенең 40 процентын тәшкил итсә, 2020 елда – 60, 2021 елда – 80 процентка җиткән.

Цифрлы рубль

Үзәк банк гыйнвар аенда цифрлы сумны сынап карауга керешә. Ул кулда йөри торган һәм картадагы акча белән беррәттән әйләнешкә керәчәк. Электрон валютадан, гадәттәгечә, интернет аша, шулай ук гади кибетләрдән товар сатып алганда файдалану күздә тотыла. Цифрлы рубль электрон акча белән түләүләрне үстерүнең чираттагы этабына әйләнә. 2021 елның өченче кварталы йомгаклары буенча электрон исәп-хисапларның өлеше инде 75 процентка җиткән.

Вычет алу җиңеләя

Ел башыннан спорт белән шөгыльләнүгә түләнелгән акча буенча салымны кире кайтарып алу мөмкинлеге турында закон эшли башлый. Шулай итеп, бассейннар, фитнес-клублар спорт залларына абонент сатып алучылар хәзер аның бәясенең 13 процентын кире кайтаруга исәп тота ала, дигән сүз.

Шул ук вакытта вычет алу җиңеләя: декларация һәм түләнгән салымның бер өлешен кире кайтаруга хокукны раслаучы документлар тапшырырга кирәк булмаячак. Моның өчен Салым федераль хезмәте сайтындагы шәхси кабинет аша заявка гына калдырырга кирәк. Салым органы барлык тикшерүләр белән үзе шөгыльләнәчәк. Заявка алынганнан соң, салым хезмәте эш бирүчегә хезмәткәрнең вычетка хокукы турында хәбәр җибәрәчәк.

Кредит тарихы яңача языла

Кредит тарихында мәгълүматлар саклау вакыты кими: 10 елдан 7 елга кала. Шунысы мөһим: яңа кредит алгач, «тарих» шуның буенча гына язылып барачак, элеккесе онытылачак. Әйтик, моннан биш-алты ел элек алынган кредитның бер-ике тапкыр вакытында түләнелмәгән булуы турында мәгълүматлар юкка чыгачак.

Барыбызны да исемлеккә кертәләр

1 гыйнвардан Россиядә яшәүчеләр турында мәгълүматларның федераль исемлеге пәйда булачак. Анда физик затлар турында Пенсия фонды, Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды, Эчке эшләр министрлыгы һәм башка дәүләт оешмалары тарафыннан җыелучы мәгълүматлар кертелә. Исемлектә кешенең исем-фамилиясе, туу датасы (үлү датасы), туу урыны (үлү урыны), җенесе, гаилә хәле, гражданлыгы күрсәтелә. Аны Салым федераль хезмәте алып барачак.

Исемлектәге мәгълүматлардан, кирәк булган очракларда, прокуратура, ФСБ, таможня органнары һ.б. файдалана алачак.

Медицина белешмәсе алу кыенлаша

1 марттан машина йөртүчеләргә медицина белешмәсе алу тәртибенә үзгәрешләр кертелә. Исерек хәлдә рульгә утыру сәбәпле «права»сыннан мәхрүм ителүчеләргә яки көпшәгә өреп караудан баш тартучыларга кан һәм бәвел анализларын тапшырырга кирәк булачак. Ә инде тәнендә укол эзләре булганнар кыйммәтле анализларга җибәреләчәк. Машина йөртүченең йөрәк тибеше чиктән тыш түбән булса, куллары калтыраса, йокымсырап утырса яки, киресенчә, ярсыган хәлдә булса, тирәнтен анализлар тапшырырга туры киләчәк. Йөртүче язмышын, анализ нәтиҗәләреннән соң гына, махсус комиссия хәл итәчәк.

ВАСИЛИЙ ЛИХАЧЕВ: «ТАТАРСТАН МИҢА БИК ЯКЫН БУЛДЫ»

Үзгәртеп кору елларында Шәймиевнең уң кулы, Президенттан кала икенче кеше. Республика бәйсезлеге турында Декларацияне, Татарстан Конституциясен төзүдә катнашкан шәхесләрнең берсе. Талантлы дипломат. Искиткеч әңгәмәдәш. Бу сүзләр барысы да – Татарстан үсешенә зур өлеш керткән Василий Лихачев турында. 2022 елның 5 гыйнварында аңа 70 яшь булыр иде. Моннан ике ел элек каты авырудан соң ул арабыздан китте.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең әгъза-мөхбире, Россия Табигать фәннәре академиясе академигы, юридик фәннәр докторы, профессор. Халыкара һәм дәүләт хокуклары мәсьәләләре буенча 600дән артык фәнни эш һәм монографиясе бар. Португал, француз, инглиз телләрен белә.

1991 елда Татарстан Республикасы вице-президенты иседе белән яңа гамәлгә кергән вазыйфага Лихачев билгеләнә. Дөрес, 1995 елда бу вазыйфа юкка да чыгарыла. Шул сәбәпле Василий Николаевичны Татарстанның беренче һәм бердәнбер вице-президенты дип атарга мөмкин.

Василий Николаевич 1952 елда Горький шәһәрендә (хәзер Түбән Новгород) туа. Аның Татарстанга килеп чыгуы югары университет белән бәйле. Мәктәпне тәмамлагач, егет юридик факультетка юл тота. 1975 елны югары уку йортын уңышлы тәмамлаганнан соң, аспирантурада кала, 1978дә диссертация яклый. Үзгәреш еллары дулкынында 36 яшьлек Василий Николаевичны КПСС өлкә комитетының бүлек мөдире итеп куялар (аңа кадәр ул Гвинея-Бесау Республикасының хокук мәктәбендә, аннан Мадагаскар Республикасы университетында эшләргә өлгерә). Ике елдан Татарстан Конституцион күзәтчелек комитеты рәисе итеп билгелиләр. Бу хакта бер әңгәмәсендә ул: «Татарстан Конституциясен кабул иткән авыр көннәрне искә төшерәм. Баш китәрлек бәхәсләр булды анда! Конституциянең һәр бүлеге, һәр статьясы – бәхәсләр һәм компромисслар нәтиҗәсе. Без һәрбер статья өчен генә түгел, хәтта һәр сүз өчен көрәштек», – ди искә ала.

Бу вазыйфалардан соң Лихачев Татарстан Дәүләт Советы Рәисе һәм Федерация Советы Рәисе урынбасары итеп сайлана. Дәүләт Советының ике телдә эшләвенә ирешә, әлеге тәкъдимне кертүдә инициатор буларак чыгыш ясый.

1998 елда Василий Николаевич тормышында дипломат буларак яңа этап башлана. Ул Брюссельдә Россия вәкиле итеп билгеләнә. Аннан, Ингушетия вәкиле буларак, Федерация Советына әйләнеп кайта. Матбугат чараларында язылганча, ул халыкара юрист белгечлеге буенча алыштыргысыз була. Димәк, башта Халыкара эшләр буенча комитет рәисе урынбасары, аннан Россия юстиция министры урынбасары постын биләве дә очраклы гына түгел. 2011 елдан 2016 елга кадәр ул алтынчы чакырылыш Дәүләт Думасы депутаты – БДБ эшләре, Евразия интеграциясе, Ватандашлар белән элемтәләр комитеты әгъзасы була. Аның депутатлыктан китүе Россия Президенты Владимир Путин дәрәҗәсендә хәл ителә. Бу хакта Лихачев бер әңгәмәсендә түбәндәгеләрне җиткерә: «Мин үз эшемнең юнәлешен үзгәртергә теләвем турында Россия Президентына хат юлладым. Шуннан соң мине Вячеслав Володин янына чакыртып алдылар һәм Россия Үзәк сайлау комитетында эшләргә тәкъдим ясадылар. Мин килештем». Үзәк сайлау комитетында Лихачев халыкара юнәлеш һәм Түбән Новгород, Омск, Самара, Ростов өлкәләре буенча куратор була. 2016 елда соңгы тапкыр билгеләнгәндә ул: «Ничек кенә булса да, Татарстан миңа бик якын булды һәм булачак, мин аның өчен һәрвакыт җан атам», – дигән сүзләр әйтә.

Татарстандагы хезмәттәшләре искә алганча, Василий Николаевич, чыннан да, Татарстанны, аның халкын бик ярата, аларның сәламәтлеге турында кайгырта, киңәшләре белән ярдәм итә. Гаиләсендә дә һәрвакыт тәртип була аның. Хатыны Наилә Иматовна ире кебек үк юридик белем ала. Татарстанда прокурор ярдәмчесе булып эшли. Илнара һәм Рената исемле ике кыз тәрбияләп үстерәләр. Василий Лихачевны озату мәрасиме Мәскәүдә була, мәрхүмнең васыятен үтәп, аны Казандагы Арча зиратына җирлиләр.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Василий ЛИХАЧЕВ лаек булган бүләкләр:
- IV дәрәҗә «Ватан алдындагы хезмәтләр өчен» ордены;
- Почет ордены;
- Дуслык ордены;
- «Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгының мактаулы хезмәткәре» исеме;
- Россия Президентының Рәхмәте.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Сөнгатуллин** Фарук Фатыйх улы; Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен **Гарифуллина** Гүзәл Габделвәли кызы, Луцкова Фәридә Әхкам кызы; хезмәт ветераннары: **Абражеев** Василий Алексеевич; **Әкбәрова** Фәридә Әхәт кызы; **Гыйльметдинова** Наилә Җәләлетдин кызы; **Кәримова** Гөлсәрия Салих кызы; **Степанова** Людмила Ивановна; **Шәмгунова** Диләрә Нигъмәтҗан кызы; **Юнысова** Мәрьям Хәертдин кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм республикада автомобиль спортын популярлаштыруга зур өлеш кертүе өчен «БАЕР Студия» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Ручкан** Евгений Валентинович **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Казан шәһәренең «Профессор К.Ш.Зыятдинов исемендәге 18 номерлы үзәк шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының амбулатория-поликлиника часте буенча урынбасары **Бахарева** Гөлмирә Илгиз кызына, «Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтнең 16 номерлы медицина-санитария часте» федераль казна сәламәтлек саклау учреждениесенең «Хастаханә» филиалы башлыгы – табибы, эчке хезмәт подполковнигы **Бондарева** Ирина Юрьевнага, «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең балалар поликлиникасы табиб-офтальмологы **Гобәйдуллина** Розалия Рафаэль кызына, «Корд-Клиника» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте табиб-офтальмологы **Коробицин** Артем Николаевичка, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 2 номерлы хирургия бүлекчәсе табибы – балалар хирургы **Линьков** Владимир Михайловичка, Россия Федерациясе Хезмәт һәм халыкны социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Медицина-социаль экспертиза баш бюросы» федераль казна учреждениесенең 34 номерлы бюросы җитәкчесе – медицина-социаль экспертиза табибы **Мохтарова** Ризеда Зиннур кызына, «Буа үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең участок педиатрия кабинеты табиб-педиатры **Сабитова** Фәридә Габдрахман кызына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор Е.В.Адамюк исемендәге Республика клиник офтальмология хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы **Хөсәенова** Динә Камил кызына, Казан шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының медицина часте буенча урынбасары **Шәкүрова** Кадрия Иршат кызына, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Медицина-санитария часте 1 нче терапия бүлекчәсе мөдире – табиб-терапевты **Шәфигуллина** Илсөяр Әдип кызына «**Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш акушеркасы **Әхмәтшина** Зөлфия Равил кызына, «Татарстанның медицина техникасы һәм фармациясе» дәүләт унитар предприятиесе даруханә складының сату бүлеге баш белгече **Сәгъдиева** Резеда Мөнир кызына, Казан шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең физиотерапия бүлекчәсе дәвалау физкультурасы буенча инструкторы **Сафина** Залия Зөфәр кызына **«Татарстан Республикасының атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«АСТЕЙС» акционерлык җәмгыяте башкарма директоры **Бабаев** Владимир Николаевичка, «Казан приборлар төзү конструкторлык бюросы» акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Курбиев** Илдус Өлфәт улына, «АСТЕЙС» акционерлык җәмгыяте директорының производство буенча урынбасары **Сыриков** Олег Валентиновичка **«Татарстан Республикасының атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең Скважиналарны җир астында төзекләндерү идарәсе башлыгының технология һәм сервис буенча урынбасары **Макаров** Дмитрий Николаевичка **«Татарстан Республикасының атказанган нефтьчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Агросәнәгать һәм транспорт комплексын проектлау институты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш белгече **Варыгина** Мария Ивановнага, «НЭО СТРОЙ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Гафуров** Ирек Хатыйп улына, «ПЦ Град» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры урынбасары **Манучаров** Дмитрий Александровичка, «ТАИФ-СТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең смета-шартнамәләр бүлеге башлыгы урынбасары **Надыршина** Чулпан Радик кызына, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының төзелеш комплексын үстерү идарәсе башлыгы **Сәгъдәтуллин** Динар Габбас улына, «Алтын Групп» төзелеш компаниясе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең финанс директоры **Сафиуллин** Рөстәм Рәшит улына **«Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең Социаль объектлар идарәсе М.Хуҗин исемендәге спорт-сәламәтләндерү комплексының футбол буенча тренеры **Абдуллин** Назиф Нури улына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «1 номерлы олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең спорт гимнастикасы буенча тренеры **Әхмәтҗанова** Гөлнара Мөхәммәтхан кызына, Свердловск өлкәсенең бертуган Нәҗметдиновалар исемендәге спорт мәктәбе дәүләт автоном учреждениесе тренеры **Нәҗметдинова** Ильмира Билал кызына, Свердловск өлкәсенең бертуган Нәҗметдиновалар исемендәге спорт мәктәбе дәүләт автоном учреждениесе тренеры **Ратманская** Розалия Билал кызына **«Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Әйтеп кенә бактым

Демократик централизм

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Комсомол сафларына кабул иткәндә һәркемнән: «Демократик централизм нәрсә ул?» – дип сорамый калмыйлар иде. Шуңа күрә һәркем җавабын да белә иде. Чөнки укытучыларыбыз безгә алдан ук «ликбез» үткәреп, җавапны сүзен-сүзгә ятлаталар иде. Комсомолга кабул итү комиссиясе каршына баскач, без: «Демократик централизм ул – азчылыкның күпчелеккә буйсынуы», – дип шартлатып җавап бирә идек. «Политически подкованный» икәнлегебезне шулай раслыдык. «Демократик централизм»ның асыл мәгънәсен тулысынча аңлап бетермәсәк тә, шушы ике сүзнең җәмгыять идеологиясен тәшкил итүен чамалый идек.

Ул еллардан соң күпме сулар акты, җитәкчелек бар халыкларга тигез хокук бирергә тиешле җәмгыять төзү уе белән янудан туктамады. 1980 елдан без инде коммунизмда яши башларга тиеш идек, әмма коммунизм урынына Мәскәүдә узган Олимпия уеннары белән канәгатьләндек.

Ә 1990 нчы елларда исә, гомумән, 180 градуска кире борылдык. Тик бөтен халыкка бердәй хокук бирердәй федератив дәүләт төзү уе һаман да яши бирде. Әйе, яши бирде уй уй, әмма федерация урынына «хакимият вертикале» дигәннәре тормышка ашырыла башлады. Бу инде азчылыкның күпчелеккә түгел, ә күпчелекнең азчылыкка, ягъни астагыларның өстәгеләргә берсүзсез буйсынуы иде. Без «вертикаль»сез яши алмыйбыз, күрәсең. Горбачев белән Ельцин халыкка ирек биреп караган иде, ил сүрүләреннән сүтелгән мендәр кебек таралды да бетте. Ярый әле хакимлеккә Владимир Путин килеп, таркалган илне яңадан җыйды, бөтенебезне бер җепкә тезә башлады. Бу эш һаман да дәвам итә. Россия Думасы әле күптән түгел генә гавами хакимият органнарын оештыру принциплары турында закон проектын хуплады. «Кул чабулар» туктап өлгермәде, Думага тагын бер закон проекты керергә тора. Ул – гавами хакимиятнең гомуми системасында җирле үзидарәне оештыру принциплары турында. Авторлары шул ук – Андрей Клишас һәм Павел Крашенинников. Моңа хәтле җирле үзидарә үз бюджеты булган мөстәкыйль оешма кебек иде. Кебек кенә иде шул, асылда җирле үзидарәләр район хакимиятенә буйсынды. Проект хупланса, әлеге буйсыну рәсми рәвештә законлаштырыла гына булып чыга. Һәм инде җирле үзидарәләр Президентка, төбәк хакимиятләренә буйсыначаклар. Гадирәк әйтсәк, эреле-ваклы бөтен түрәләрне дә өстән билгеләячәкләр.

Закон проектында язылганча, биш ел эчендә җирле үзидарәнең түбәнге буынын юкка чыгарачаклар. Бу – авылларда, кечкенә шәһәрләрдә, шәһәр тибындагы бистәләрдә моңарчы яшәп килгән 18 мең тирәсе муниципаль органнар. Федераль әһәмияткә ия шәһәрләр – Мәскәү, Петербург, Севастополь территорияләрендәге муниципаль берәмлекләргә кагылмаячаклар икән үзе, «покага». Тора-бара... Хәер, күрәзәчелек итми торыйк әле. Кыскасы, закон проекты Россия «көчле кул» белән идарә ителә торган ил ягына таба атлый. Яхшымы бу, яманмы – кистереп әйтү кыен, әмма федерализм принципларының юкка чыга баруы хак.

Күптән түгел Мәскәү телевидениесеннән сәяси шоу карадым. Атаклы режиссер Карен Шахназаров империяне яклап сөйләде. Үзен дә «империк» дип атады. Нәрсә әйтмәкче булды ул? Бәлки, безнең бары тик империядә генә яшәргә хаклы икәнебезне тагын бер кат расларга теләгәндер. Безнең, заманча сүзләр белән әйтсәк, «менталитет» шундыйдыр һәм аны үзгәртү дә кирәк түгелдер. Теләсә нинди халыкның үз дигәнчә яшәргә хокукы бар бит. Мин чордашларым, ягъни өлкән буын кешеләренең яратып әйтә торган сүзе белән язмамны тәмамлап торам: «Дөньялар гына тыныч булсын инде!» Бөек үзгәрешләр чорында туган буын нәрсә әйтер тагын?!

БАЗАРГА АЯК БАСКАНДА,

ЯКИ БӘЙДӘН ЫЧКЫНГАН БӘЯЛӘР ЮБИЛЕЕ

Моннан утыз ел элек без, совет кешеләре, беренче тапкыр ирекле бәяләр стихиясенә килеп кердек. 1992 елның гыйнвар башын мин яхшы хәтерлим, чөнки Казанда идем, Бауман урамындагы ашханәгә тамак ялгарга кердем. Элекке совет ашханәсе ничек иде? 70 тиен – 1 сумга ярыйсы гына ашап чыгарга була, тамак туеп ук бетмәскә мөмкин, билгеле, чөнки, бердән, мин ул чакта әле яшь, икенчедән, ашханә тәлинкәсендә өлешләр артык зур булмый. Әле студент чакта «Сөт кафесы» дип аталган кафеда, кесәдә бер дә акча калмаганда, 1 өлеш манный боткасы, 1 стакан чәй, ике кисәк ипи алып, 6 тиенгә дә ачлык тойгысын басып чыгарга бик була иде. Махсус студент ашханәләре бар, аларда ассортимент ярлы, әмма бәяләр шактый ук түбән иде.

Күз алдыгызга китерегез: менә шундый бәяләргә күнеккән совет кешесе ашарга дип ашханәгә керә һәм чиратка баса. Алда минем кебек берничә мокыт бар, әмма кассага килеп җитүгә, алар алган ашларын һәм боткаларын кире куеп, ач килеш чыгып китәләр. Бу юлларның авторы исә чигенмәскә булды. Кассага килеп, ризыкның бәясен исәпләттем, ис китмәгән кыяфәт белән кесәдән егерме бишлек купюраны чыгарып салдым, сдача булмады шикелле. Аңлый торгансыздыр инде кешеләрдә нинди шок булганын.

Базарга без менә шулай килеп кердек. Көнкүреш техникасы, өс-аяк киемнәре, ашау-эчүгә бәяләр табадагы борчаклардан да болайрак сикерә иде. Акчаның бер дә бәрәкәте калмады. Совет кешеләренең гомере буе туплаган маясы санаулы көннәр эчендә тиенлек тә кыйммәткә ия булмаган чүпкә әйләнде. «Каракстан кала, янгыннан калмый» дигән әйтем бераз искерде. Базар мөнәсәбәтләре безне шундый итеп талый иде: җеп тә калмый, инә дә калмый. Хезмәт хаклары бәяләргә иярергә тырышып үсә, әмма гадәттәгечә инфляция локомотивы алдан чаба. Исеме дә ул чакта гиперинфляция иде аның. Айлап түгел, көнләп һәм сәгатьләп үсә бәяләр. Эшләп торган кеше ачтан үлми иде үлүен. Әмма халыкның фәкыйрьлеге (бер көн эчендә фәкыйрьлеккә төшүе) икътисадка ник сукты: товарларын сата алмаган завод-фабрикалар ябыла башлады яисә эшчеләрне кыскарттылар. Безнең сүзлеккә акрынлап «челнок» дигән сүз килеп керде. Вак сәүдәгәрләрне ни өчендер шулай дип атый башладылар.

Ельцин бер яхшылык эшләде: урам сәүдәсен либеральләштерде, берниндi рөхсәтсез-лицензиясез кайда теләсәң, шунда сәүдә оештырырга мөмкин була башлады. Бу элекке инженерларга, урамга куылган галимнәргә, паекка утыртылган мәдәният өлкәсе хезмәткәрләренә ач үлемнән котылу юлын ачты. Тормышка чытырдап тотынырга кирәк икәнлекне аңлап алучылар Төркиягә очып, зур сумкалар белән сыйфатсыз товар төяп кайтырга һәм сәүдә итәргә керештеләр. Урамнары арзанлы чүпрәк, киемнәр басты.

Үзебезнең ательелар, кием фабрикалары алар белән көндәшлеккә чыдый алмады. 1993 елның апрелендә бу юлларны язучы Казан тимер юл вокзалы янындагы иске җимерек урамнарның берсеннән барганда, кием фабрикасы ишеге төбендә костюм сатучы хатынга юлыкты. Үзебездә җитештерелгән тукымадан үзебездә тегелгән костюм белән кызыксындым, бәясе дә юнь генә иде, сыйфаты да яхшы күренде. Сатып алырга теләгәнемне күреп, хатын мине фабриканың «проходное»на чакырды, әчтә, вертушка янында, костюмнарның мул коллекциясе бар, теләгәнеңне сатып алырга була иде. Шунда мин гомеремдә соңгы тапкыр ник итеп тегелгән сыйфатлы костюм сатып алдым. Андый сыйфатны һәм ныклыкны бүтән очрата алмам дигән уй башка да килмәде. Ул костюм миңа байтакка чыдады, тузды, дигәч тә кара эшкә бернигә ел кидем әле. Үзебезнең җитештерүчеләр киемнәрне базарга һәм кибетләргә чыгара алмыйча ябылды, чөнки алар теккәнгә арадашчылар да килеп кысылгач, күтәрә алмаслык салымнар өстәгәч, товар янына якын килмәслеккә әйләнә иде. «Проходной»да костюм сатып, ерак китеп булмый, әлбәттә.

pixabay.com

1992 елның гыйнварында Мәскәү янындагы Киров исемендәге колхоз рәисе, журналистлар сорагач, сөт бәясен исәпләп күрсәтә. Бер литр сөтнең үзкыйммәте гыйнвар башында, Пенсия фондына һәм Социаль иминиятләштерү фондына взнослар түләгәч, 6 сум 26 тиен тирәсе чыга. Әмма 28 процентлык өстәмә кыйммәт салымы килеп ялганып, үзкыйммәтне шунда ук 8 сум 76 тиенгә кадәр күтәрә. Бу – колхоздан озату бәясе. Искә төшерик: совет кибетләрендә сөт бәясе 24 тиен тора иде. Әле ул вакытта пальма маеннан сөт ясарга өйрәнмәгәннәр иде, базарның беренче айларында чын сөт сатылды.

Гиперинфляцияле базар кешеләргә бик каты сукты ул елларда. Эше булганнар ачтан ук үлмәде, әмма эшсез калу һәлакәткә тиң иде. Бәяләр туктаусыз үзгәреп торганлыктан, запас акча җыеп булмый, булса да, ул бер-ике айдан бернигә дә ярамаслык хәлгә килә. Завод ишеге төбендә эләккә менгән яшьтәшләр булды, кайгысын агулы аракы белән юып, дөнья белән бәхилләшүчеләр дә җитәрлек иде. Россия халкы бик ник кырылды ул елларда, тирән демографик упкын пәйда булды. Кешеләр бик тиз катлауларга бүленә башлады. Ягулык-энергетика тармагында эшләүчеләр муллыкка тиенде, авыл крестьяны һәм бюджеттагылар фәкыйрьлек сазлыгына батты.

1993 елның сентябрендә илдә уртача хезмәт хаклары менә болайрак иде. Ил буенча уртача хезмәт хакы 80,9 мең сум дип исәпләнгән. Яшәү минимумы бер кешегә 30 мең дип саналган. Дүрт россиялене берсе яшәү минимумыннан кимрәк хезмәт хакы алган. Газ тармагында эшләүчеләрнең уртача хезмәт хакы – 237,2 мең сум, нефтьчеләрнеке – 221,1 мең сум, мәгариф өлкәсендә – 57,2 мең, галимнәрнең акчасы – 50,3 мең, уртача пенсия – 26,5 мең. Фән докторлары нефть компаниясенә идән юарга керергә хыялланган еллар бу. Яшьрәк галимнәр кайсы кая таралышты: чит илгә китүчеләр дә булды, сәүдә рәтендә дә күренделәр, коммерция оешмаларында үз фәненнән ерак эш белән шөгыльләнүчеләр дә байтак иде. Вуз өстәле янында утырып калучылар ришвәтле имтиханнар белән нәфесләрен канәгатьләндерергә ияләнә башлады.

Телгәң һәм дәртең булса да, эшмәкәрлек белән шөгыльләнү хәвефле иде. Бердән, криминал чәчәк ата, үз көче белән нәрсәдер булдырырга тырышканнарны карап кына торалар. «Түбә» булырга теләүчеләр чиратка баса, түләп бетерерлек түгел. Урам атышлары еш оештырыла, шунда җиңгән һәм исән калганнар үз территорияләрендә бөтен бизнесны «савып» яшәү белән көн күрәләр. Икенчедән, эшмәкәрләргә караш халыкта да, чиновникларда да тискәре, бер дә яратмыйлар, аяк чалырга гына торалар. Өченчедән, башлангыч капитал табып булмый, ул чакта кредит бик аз процентлы, әмма хакимият башлыгы имзасыннан башка банктан кредит ала алмыйсың. «Тагарак»ка исә теләсә кемне китермиләр. Йонлач кулың булса гына. 1991 ел белән 1992 ел очрашканда, безнең төбәкнең беренче фермеры Равил абый районга кайткан бердәнбер тракторны сатып алып калу бәхетенә ирешә. Әле бәяләр ычкынмаган, тракторның бәясе – 280 мең сум гына (әмма совет кешесе өчен котчыккыч сумма). Авыл хуҗалыгы техникасы кайтарту белән шөгыльләнүче таныш чиновниклар тракторны, акча тапса, фермерга бирергә риза, әмма хакимият башлыгы кредитка рөхсәт бирми. Банкта эшләүче таныш хатын булышырга риза була. Имза салырга дигән бер кочак кәгазь арасына фермерга кредит рөхсәт итә торган документны да кыстырып җибәрә, түрә абайламыйча имзалый. Шулай итеп 1992 елга аяк басканчы, фермер хуҗалыгына соңгы совет бәясеннән трактор алып кайтып бастыра.

– Әни: «Бөтен нәселең түләп бетерә алмаслык бурыч алгансың», – дип елады, – дип искә алды ул хәлне егерме елга якын вакыт узгач.

Базарга без менә шулай килеп кердек. Бары тик 2004–2014 еллар арасында гына берникадәр тотрыклылык булып алды. Бәяләр сәгатьләп үк үсми иде. Хәзер инде артка борылып карагач, ул унъеллык безгә муллык чоры булып тоела. Базарның утыз еллыгын без капитализмның көчле тетрәнүе шартларында каршы алабыз. Күңел сизә: глобаль система зур ишелү алдында тора. 1990 нчы елларда алган чыныгу янә кирәк булмагае.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Илдар Мөхәммәтҗанов

ОНЛАЙН АВЫЛ

ЯКТАШЛАР «ИНСТАГРАМ»ДА АРАЛАША

Авыл халкы заман белән бергә атлый. Блогерлык, социаль челтәрләр сала тормышына да ныклап кереп урнашты. Авылның актив бер кешесе үз битләрен ачып, сәхифәне кызыклы, файдалы һәм мәгълүматлы итеп алып барырга тырыша. Халык өчен исә ул аралашу, яңалыклар бүлешү, истәлекләр барлау мәйданчыгы булып хезмәт итә. Без «Инстаграм»да актив булган авыл аккаунтларын барладык.

Элеккеге фотолар – иң популяры

Саба районының Явлаштау авылының «Инстаграм» битенә 1263 кеше язылган. Җанлы итеп алып баралар, кызыклы сәхифәләргә бай аккаунт. Авторы – Рәфидә Галимҗанова.

– Безнең авылда яшьләр бик актив, – диде ул безгә. – Алар спорт, мәдәни тормышта кайнап яши. Бер җыелышып, сөйләшеп утырганда, «Инстаграм»да авылыбызның аккаунтын эшләү идеясе туды. Ул вакытта миннән бигрәк егетләрдә кызыксыну зур булды. 2018 елның гыйнвары иде ул. Беренче постлар авыл яңалыкларын, табигать күренешләрен куюдан башланды. Шунда ук халыкта кызыксыну барлыгын сиздек. Февральдә без авылда спектакль куйдык. Аккаунт бу турыда хәбәр итәргә дә шәп мөмкинлек иде. Бераздан безгә укытучылар, мәдәният хезмәткәрләре дә тартылды. Халык элеккеге фотоларын җибәрә башлады. Хәзер бу сәхифә аеруча яратып кабул ителә. Шуннан соң аккаунт мәдәният, спорт юнәлешенә таба борылды. Чөнки егетләр футбол уйнаганда «туры эфир»ларга чыга. Мин үзем мәдәни тормышны күбрәк яктырттым. Гомумән, ул елларда вакыт та иркенрәк, шунлыктан без дә активрак идек. Казанда эшли башлагач, яңалыклар биреп бару сирәгәйде. Хәзер исә мин атнаның ике көнендә авылда булырга тырышам. Яңа рубрика да ачып җибәрдек. Ул «Мин бит – авыл баласы» дип атала. Ул безнең – «туры эфир»лар сериясе. Китапханәче белән бергәләп, авылдан читкә киткән, озак еллар кайтмаган кешеләр белән элемтәгә чыгабыз. Киләсе елда алар белән берлектә концерт оештырырга уйлыйбыз. «Туры эфир»лар эшли башлагач, язылучыларыбыз саны артты. Моннан тыш, «Күршем, нәрсә пешердең?» рубрикасы бар. Монда без тәм-том пешергәнне видеога төшереп кертәбез.

Шәһәрдә торып, авыл сәхифәсен алып бару бик җиңел түгел, чөнки аның өчен яңалыклар эчендә кайнау кирәк. Ләкин авылга кайткач, һәрвакыт контент буенча эшлим. Киләчәктә авылда узган чаралардан видеорепортажлар эшләү планы бар. Аннан соң, өлкәннәр белән интервьюлар да эшләргә телим. Халык дини өлкәгә кагылышлы сорауларына да җаваплар көтә. Менә шул юнәлеш буенча да эшлисе иде.

Лайфхаклы тормыш

Актаныш районының Такталачык авылы аккаунтының 1369 язылучысы бар. Аны алып баручы Юлия Мансурова әйтүенчә, «Инстаграм»да авыл битенең беренчел максаты – мәгълүмат бүлешү мәйданчыгы булуда.

– Авылыбызда кеше күп булгач, «Ватсап» төркемнәренә генә сыешмый башлады. Барлык мәгълүматны анда куеп бетереп тә булмый, – ди ул. – Читтә яшәүче авылдашларыбыз да бар бит. «Инстаграм»да авыл турында аккаунт ачу ихтыяҗы менә шуннан туды. Шулай итеп, узган елның 29 гыйнварында беренче пост куелды. Мин – укытучы, иптәшем авыл җирлеге башлыгы булып эшли. Шуңа күрә икебез дә авыл яңалыклары эчендә кайныйбыз. Беренче вакытта аккаунтның да төп максаты авыл эшчәнлеген күрсәтү иде. Соңрак авылдашлардан, читтә яшәүчеләрдән рәхмәт сүзләре ишеткәч, кызыксыну сизгәч, тагын да дәртләнеп эшли башладык. Сәхифәләргә килгәндә, иң күп караулар, комментарийларны элеккеге фотолар җыя. Берничә тапкыр ирем «туры эфир»га чыгып, халыкның сорауларына җавап бирде. Анысын да яраттылар. Котлауларны да матур итеп биреп барабыз. Уеннар, авыл күренешләрен дә эләбез. «Хәйләсез дөнья файдасыз» дигән сәхифәдә гади, кешегә аңлаешлы лайфхаклар, киңәшләр биреп барабыз. Кыскасы, аккаунтны төрләндереп торабыз. Декабрьгә кадәр көнгә 2–3 пост эленә иде. Хәзер мәшәкатьле вакыт булгач, бераз сүлпәнәйде. Киләсе елдан битне тагын да кызыклырак, җанлырак итеп алып бару планнарыбыз бар.

Балтач районы Алан авылы аккаунтын исә һәрдаим 1060 кеше карап бара. Сәхифәнең «хуҗа»сы Рузалия Тимербаева әйтүенчә, язылмыйча гына караучылар саны ике тапкыр күбрәк:

– Мин – белемем буенча икътисадчы, ләкин күңелем белән иҗади кеше. Әлеге аккаунтны 2019 елның июнендә ачып җибәргән идем. Әбием – авылның иң өлкән кешеләренең берсе, тыл ветераны. Без кечкенәдән үк авыл тарихына кагылышлы мәгълүматларны ишетеп үстек. Аларны башкаларга да җиткерәсе килде. Бәби белән декрет ялына чыккач, әлеге мәгълүматларны туплап, фотолар белән бизәп, «Инстаграм»дагы шәхси битемә урнаштыра идем. Ләкин минем аудиториягә бик үк кызык булмас дип, авылның аерым битен булдырып, кечкенә генә тарихи белешмәләрне шунда урнаштырдым. Бераздан авылдашлардан да фото, видеоматериаллар кабул итә башладым. «Татар блогеры» бәйгесендә җиңгәч, башка авыл кешеләре дә кушылды.

Казанда булсам да, авыл сәхифәсен алып бару авыр түгел. Әбием – төп ярдәмчем. Җыелган материаллар булу да бик булышты. Авылдашларым кешеләр турында язган постларны аеруча яратып укый. Гадәттә, халык арасында абруе булган, тырыш, үрнәк апа-абыйлар, гаиләләр турындагы постлар күп игътибар җыя. Читтә яшәүчеләрдән рәхмәт сүзләре еш ишетәм. Алар авыл тарихы белән аеруча нык кызыксына.

«Китап итеп чыгару хыялым бар»

Яшел Үзән районының Урысбага авылы аккаунтына 1116 кеше язылган. Аны Руфия Мөхетдинова алып бара.

– Милли музейда эшләгән вакытта журналист Данил Сәфәров «Татар китабы йорты»нда «Инстаграм» буенча укулар алып барган иде. Шуның нәтиҗәсе буларак, 2019 елның җәендә «Инстаграм»да авылыбыз бите ачылды, – ди Руфия. – Сирәк кенә булса да фотолар куя идем. «Сабантуй» журналына баш мөхәррир урынбасары булып эшкә урнашкач, авыл аккаунтын тагын да кызыксынып алып бара башладым, язылучылар саны да артты. Җирлеккә 4 авыл керсә дә, мин күпчелек Югары һәм Түбән Урысбага авыллары тормышын күрсәтәм. Элеккеге фотоларны бик яраталар. Аларны халык үзләре җибәреп тора. Үзем Казанда яшәгәч, авылда ярдәм итүчеләрем бар. Клуб мөдире Гөлсия Садриева, авыл җирлеге башлыгы Хәйдәр Сибгатуллин, укытучылар һәрдаим хәбәрләр белән бүлешәләр. Фәнис Шакиров видеолар төшерүгә җаваплы. Апалар шигырьләр яратканга, аларны күп куярга тырышам. Рөстәм Сәйфуллин авыл тарихын барлый башлады. Аның язмаларын көтеп алам. Киләчәктә китап булып чыгар дип тә хыялланабыз әле. Аккаунтта өлкән кешеләребезне тәбриклибез, төрле бәйгеләр үткәрәбез.

Аккаунтыбыз «Татар блогеры» бәйгесендә дә җиңеп чыкты. 20 мең сум акча биргәннәр иде. Аның бер өлешенә авылыбызның табигать күренеше төшерелгән календарьлар ясаттым. Яңа ел бәйрәмендә авылдашларыма менә шундый бүләк ясыйсым килде. Авылыбыз зур булмаса да, халкы тыныш һәм бердәм. Кышын кардан төрле сыннар ясыйлар.

Арча районы Наласа авылы аккаунтын да күпләрегезнең күргәне бардыр. Аның 1288 язылучысы бар. Аккаунтның авторы Рамил Мөхетдинов сүзләренчә, бу бит – тарих белән кызыксыныр өчен менә дигән форсат.

– Бу идея белән күптәннән янып йөри башлаган идем, – ди ул. – 2019 ел башында ачып та җибәрдем, ләкин телефон алышынгач, паролен югалттым һәм битне кабаттан тергезергә туры килде. Иң элек «Наласа авылы көе» дигән флешмоб башлап җибәргән идек. Ул бүгенгә кадәр дәвам итә. Көйне төрле уен коралларында, төрле артистлар башкаруында ишетергә мөмкин. Икенчедән, бу аккаунт – авыл яңалыклары белән бүлешү, истәлекләрне барлау урыны. Элеккеге фотоларны, кешеләрне, авыл күренешләрен карарга яраталар. Бу безгә дә тарихны онытмас өчен стимул

биреп тора. Мәсәлән, авылда тегермән, алма бакчасы, тавык фермасы булган, умарталыкта эшләүче кешеләр турында да мәгълүматлар туплыйсы бар әле. Язышу, фотолар алышу вакытында бәхәсле тарихи фактлар да ачыла. Әле менә Яңа ел алдыннан «Бизәкле Наласа» дигән бәйге игълан иттек. Февральдә «Әтием дә, бабам да солдат булган» дигән акция уздырган идек. Авылдашлар солдатта булган берничә буын фотолары белән бүлеште. Авыл урамнары, чатлары, кешеләрнең кушаматлары буенча уздырган сораштырулар да шактый кызыклы килеп чыкты. Мондый алымнар кешеләрне җәлеп итә, якынайта. Шуңа күрә авыллар турындагы аккаунтларны алып бару бик кирәкле эш дип саныйм мин.

Зөһрә САДЫЙКОВА

НӘРСӘ БУЛДЫ СИҢА, КҮҢЕЛ?

Бәйрәм кайгысы түгел әле! Игътибар итәсездер, мондый сүзне еш ишетергә туры килә. Яңа елның ун көнлек ялы да, мандарин исе дә, Кыш бабай бүләге дә сөендерә алмый андыйларны. Күпләр тормыштан ямь таба алмый интегә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Табиб ешрак бирешә

Илкүләм халык фикерен өйрәнү үзәге (ВЦИОМ) тарафыннан уздырылган соңгы сораштыру нәтиҗәләре дә шул хакта сөйли. Ни гаҗәп, ил халкының дүрттән бере Яңа елны, гомумән, каршыларга җыенмавын әйткән булган. Күпләр моны бәйрәм кәефе булмау белән аңлаткан. Социологлар бу күренешнең дә сәбәбен ачыкларга тырышкан. Баксаң, бүген ил халкының 75 проценты эмоциональ сүнүдән интегә икән. Дәрте дә, дәрманы да юк, кыскасы. Казанда яшәүчеләрнең 85 проценты исә даими рәвештә депрессия, арыганлык халәтендә яши. Әлеге төркемгә керүчеләр аларны бу тормышта берни дә сөендермәүдән, тормыштан ямь тапмауларыннан зарланган. Эмоциональ яктан иң нык эштән чыгучылар Новосибирск (92 процент), Казан (85 процент), Санкт-Петербург (78 процент) шәһәрләрендә яши икән. Кәефне хәтта күптән көтелгән Яңа ел, озын бәйрәм яллары да уңай якка үзгәртә алмый, ди белгечләр.

Психология фәннәре кандидаты Эльмира Ахунова төшенкелеккә бирелүнең төп сәбәбе дип пандемияне атый.

– Соңгы ике елда тормышыбыз тамырдан үзгәрде. Вирус дигән зәхмәтнең бер мизгелдә иребегезне чикләп, күңел тынычлыгын югалттырырга сәләтле булуын аңладык. Бүген Җир йөзендә яшәүчеләрнең күбесе ковид белән авырып, аннан соң яшәргә өйрәнә. Икенче берләре әле дә булса чир йоктырудан куркып яши. Кайчак Җир йөзендә башка берниндн борчу, авырулар да калмаган кебек тоела. Ә бит әле, моңа өстәп, көндәлек мәшәкатьләр, борчулар да бар. Бүген кеше моннан ике ел элек булган чагыштырмача тыныч тормышына кире кайтырга хыялланa. Әмма моның мөмкин түгеллеген күрә дә тагын төшенкелеккә бирелә. Мондый халәт бик күп энергияне, көчне ала, – ди белгеч.

Эльмира Ахуновага психологик ярдәм сорап килүчеләр арасында да эмоциональ сүнүдән азапланучылар шактый икән. Соңгы ярты елда гына да берничә табиб, коткаручы, социаль хезмәткәргә ярдәм күрсәтергә туры килгән аңа.

Белгечләрнең бер ише ил халкының сүлпәнлеген икътисадтагы тотрыксызлык белән бәйләп аңлата. Финанс аналитигы Булат Җәләлов фикеренчә, бәяләр котырып үскән, әмма халыкның керемнәре үзгәрешсез калган шартларда эмоциональ сүнү, депрессия кебек күренешләрнең артуына аптырыйсы юк.

– 2014 елда башланган кризис әле һаман дәвам итә. Халыкның керемнәре әнә шуннан бирле үзгәрми, бәяләрне, үзегез күреп торасыз, йөгәнләрлек түгел. Яңа елны зур өметләр белән каршылыйсың да, ел башыннан ук торак-коммуналь хуҗалык тарифлары, штрафлар арта башлый. Монда ничек күңел үссен дә нинди бәйрәм кәефе булсын, – ди ул.

Җил исми яфрак селкенми

Әмма күңел барыбер яхшыга өметләнә. Яңа елны яңа уйлар, максатлар белән башлыйсы килә. Моның өчен көчне каян табарга? Тормыштан кабат ямь табып яшәр өчен эшне нидән башларга?

Бу сораулар белән психотерапевт, «Яшәү территориясе» социаль инициативалар үзәге башлыгы Антон МИРОНОВка мөрәҗәгать иттек.

:: Без ни өчен тормыштан тәм таба белми башладык?

– Төп сәбәбе – җитеш, мул тормышта яшәвебездә. Хәзер җаның ни тели – шул бар, сайлау мөмкинлеге зур. Кызыл уылдыкны әллә нигә бер генә ашыйсың икән – ул тансык ризыкка әйләнә, көн дә шуның белән тамак ялгый башласаң, аның тәме дә, кадере дә калмый. Тормышыбызда әнә шундый тансык дип әйтерлек әйберләр калмады да бугай инде. Кеше юк кына әйбердән дә тәм таба белми хәзер. Аннары хәзер тормышыбыз шулкадәр зур тизлек белән бара. Башыбыз төрле мәгълүмат белән шыплап тулган. Кеше организмы, бигрәк тә баш мие исә алар артыннан өлгереп, үзләштереп бетерә алмый. Тормыштан тәм таба алмый башлавыбызның тагын бер сәбәбе әнә шуннан гыйбарәт. Кеше күп вакытын телефон, гаджетлар каршында уздыра. Шуңа күрә аның җанлы аралашуга вакыты да, теләге дә калмый. Нәтиҗәдә кеше әйләнә-тирәдә булган вакыйгаларны күрми, алар белән кызыксынмый башлый. Анда күңел төшенкелеге, эч пошу кебек күренешләр күзәтелә. Өстәвенә социаль челтәрләр аша даими рәвештә башкаларның тормышын күзәтеп барган кеше үз тормышыннан, үз-үзеннән канәгать булмый башлый. Тагын шунысы да бар: хәзер замана кешесенә гел максат куеп яшәргә кирәк дип тукып торалар. Кеше гел шул максатларга ирешергә, нәрсәнедер куып тотарга, узып китәргә хыялланып яши. Аларның очы-кырые күренми.

:: Рухи яктан бетеренүгә пандемия сәбәпче дигән фикерне еш әйтәләр...

– Бу фикер белән килешеп бетмим. Монда чир, аның белән бәйле рәвештә кертелгән пандемиядән бигрәк, коронавирус турында көн дә ишетелеп торган хәвефле хәбәрләр сәбәпчедер. Күз алдына гына китерик. Кеше берниндн элемтә чаралары булмаган кечкенә генә авыл яки шәһәрдә яшәп ята, ди. Көннәрдән бер көнне монда кемдер килә дә: «Ишеттеңме соң әле, дөньяда яңа төрле бик куркыныч вирус таралган икән», – ди. Теге кеше, бу хәбәрне ишеткәч, бер куркып куяр да шуның белән онытыр иде. Коронавирус, вакцинация, фәлән кеше вирус йоктырган, фәлән кеше үлгән ише хәбәрләрне көн дә ишетеп торганда исә кешенең психикасы үзеннән-үзе бозыла башлый.

:: Яшәүдән тәм тапмау дигән күренешнең фәнни аңлатмасы бармы?

– Психиатриядә «ангедония» дигән төшенчә бар. Ул бик күп кенә психик тайпылышлар вакытында күзәтелә торган билгене аңлата. Гади генә итеп әйтсәк, ангедония – шатлык булмау дип тәрҗемә ителә. Тормыштан ямь, тәм тапмый башлаган кешенең тормышыннан шатлык югала. Аның мәшәкатьләре, максат-бурычлары бар, ләкин шатлыгы юк. Шатлык нәрсә ул? Биологик яктан аңлатсак, ул – эндорфин, дофамин кебек бәхет гормоннарыннан гыйбарәт. Яшәүдән тәм тапмаган кеше организмында әнә шул гормоннар азая.

:: Арабызда үзеннән-үзе кешенең энергиясен суыручы кешеләр була. Алар белән аралашканнан соң җеп өзәрлек тә хәл калмый. Тормыштан ямь тапмый башлавыбызда бу төркемгә керүчеләрнең дә өлеше бармы?

– Сүз дә юк, әйләнә-тирәдәге кешеләрнең дә йогынтысы зур. Әгәр янәшәдәгеләр гел нәрсәнедер тәнкыйтьләп, канәгатьсезлек белдереп, тискәре энергия тарата икән, телисезме-юкмы, сез дә аның йогынтысына бирeләчәксез. Мондый кешеләрдән ерак торуың хәерле. Әгәр бу мөмкин булмаса, әйтик, андый кешеләр эш урыныгызда икән, эштән соң күңелегезгә яткан берәр шөгыль табыгыз. Көн дәвамында җыелган тискәре энергияне уңай хис-тойгылар белән юарлык булсын.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Мөхәммәд хәзрәт МИФТАХОВ, Усад бистәсе мәчете имам-хатыйбы:

„ Эмоциональ сүнү, депрессия кебек күренешләрнең ни сәбәпле артуын ачыклар өчен иң элек җәмгыятебезгә күз салырга кирәк. Бүген анда төрле җинаятьләр, хөсетлек, эгоистлык, урлау, ата-ана хакын, туганлыкны белмәү кебек аяныч күренешләр тулып ята. Болар бар да бәрәкәткә йогынты ясый. Бәрәкәт булмаган тормышта яшәү ямен, тәмен тоеп булмый. Алар кешенең бүген белән генә яшәве, кылган гамәлләре өчен киләчәктә җавап тотасы булмаячак дип тынычлап көн күрүе аркасында килеп чыга. Шуңа күрә эмоциональ сүнү, депрессияләрдән саклану өчен, иң беренче чиратта, бу тормышның ахыргы урын булмавын, мал-акчаның гына бәхетле итмәвен аңларга кирәк. Пәйгамбәребез – Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «һәрбер бала фитри иман белән туа», – ди. Шушы фитри иман кешегә программа рәвешендә салынган. Әгәр кеше аңа рухи ризык бирми икән, ул бәхетне, тормыш тәмен сизә алмый. Рухи ризык дигәндә, Аллаһы Тәгаләгә итагать итеп, аның әмерләрен үтәү күздә тотыла. Алда телгә алынган бәрәкәт тә турыдан-туры әнә шуңа бәйле.

Тормыштан ямь табып яши башлар өчен гади генә кагыйдәләр

✓ Иң элек үзегездән гел нәрсәдер таләп итүдән туктагыз. Миңа насыйбы миңа була, диюдән яхшысы юк.

✓ Элегрәк эмоциональ сүнү дигән күренеш психолог, табиб кебек «коткаручы» һөнәр ияләренең генә баш бәласе санала иде. Хәзер ул гел бертөрле яшәү рәвеше алып барган һәркемгә кагыла. Шуңа күрә гадәтләрегезне, көндәлек режимыгызны даими рәвештә үзгәртеп, төрләндереп торыгыз. Мисал өчен, мин үзем эшкә көн саен төрле юлдан барырга тырышам. Ерагракмы ул, якынракмы – мөһим түгел. Моны гадәткә керткәндә, баш та яхшырак эшли, көнегез азмы-күпме төрләнгән кебек була.

✓ Кулыгызга кәгазь алып, тормышыгызны нинди итеп күрергә теләвегезне тәфсилләп язып чыгыгыз. Теләкләрегезнең дә исемлеген төзегез. Болай эшләгәндә алар тизрәк чынга ашачак. Тормышыгызны үзгәртү дә җиңелрәк бирeләчәк.

✓ Тормышыгызны яңа хис-тойгылар белән баетып торырга тырышыгыз. Моның өчен сәяхәт итүдән дә яхшысы юк. Баш бәясенә чит илләргә барып ял итү мәҗбүри түгел. Үзебезнең илдә дә ял итәрлек, үзең өчен яңалык ачарлык урыннар җитәрлек. Диванда хыялланып ятып кына булмый!

✓ Үз организмыгызны тыңларга, ишетергә өйрәнегез. Армый-талмый көн итәр өчен аңа, ким дигәндә, сигез сәгать йокы кирәк икән, аны биш-алты сәгатьлек кенә йокы белән азапламагыз. Тәнегезне формада, тонуста тотарга ярдәм итә торган (физик күнегүләр, контраст душ, медитация һ.б.) гадәтләрне булдырыгыз.

✓ Ялгыз калып, ял итәргә дә вакыт табу мөһим. Йоклар алдыннан барлык мәгълүмат чараларын, телефон, гаджетларны сүндереп, ярты сәгать булса да тынлыкта ял итеп алырга кирәк. Уй-фикерләр тәртипкә салына, көн дәвамында җыелган киеренкелек юкка чыга, арыганлык бетә.

ИСКЕ ЯҢАНЫ САКЛЫЙМЫ?

Исемендә түгел эш, җисемендә. Россиядә, 2021 ел нәтиҗәләре буенча, кулланылган (б/у. – Ред.) кием-салым сатып алучылар һәм сатучылар саны 13,4 процентка арткан. Алыш-биреш күләме 110,6 млрд сумга җиткән, ди белгечләр. Кеше кигәнне кию, башкалардан кием кабул итү – үзеңне кимсетүме, акчаны янга калдыру ысулымы? Әллә соң, берәүнең яңасыннан үзеңнең искең яхшы, дип яшәү дөресрәкме?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Кызыксыну кабат уянган

Секонд-хендлар (кулланылган кием-салым сата торган кибетләр. – **Ред.**) чәчәк аткан чор узган гасырның 90 нчы елларына туры килә. Көнбатыштан кайтартылган кием-салым өем-өем ята иде, дип искә ала шул чор кешеләре. Кытай, Төркия, Польша кебек илләрдә аларга алмаш булырдай товарлар җитештерелә башлагач, секонд-хендларга булган кызыксыну да кимеде. Хәзер исә кытлык заманасы да түгел, кибетләрнең күплегенә, алардагы киемнең чуарлыгына ис-акылың китәрлек. Шулай да Россиядә кулланылган әйберләр базары да үсештә. Белгечләр әйтүенчә, «Юла», «Авито» кебек игъланнар өчен сайтларда, социаль челтәрләрдәге махсус төркемнәрдә кулланылган кием-салымны бушка бирүчеләр яисә үз бәясен киметеп сатучыларның төгәл санын белеп тә булмый.

Кайбер сораштырулардан күренгәнчә, Россиядә яшәүчеләрнең 25 процентының кайчан да булса бер секонд-хендтан кием-салым сатып алганы бар икән. Андый кибетләргә иң еш мөрәҗәгать итүчеләр – 44 яшькәчә булган кешеләр. Бигрәк тә 1984–2000 еллар аралыгында туучылар – икенчел кием-салым базарының үсешен тәэмин итүчеләр, ди белгечләр.

Пандемия генә сәбәпчеме?

Финанс белгече Ләйсән Халикова әйтүенчә, бу мәсьәләгә кешеләрнең төрле булуыннан чыгып карарга кирәк. «Һәр кешенең фикерләү рәвеше дә, тормыш дәрәҗәсе дә төрле. Кемгәдер кулланылган кием-салым кибетләрендә киенү гадәти хәл тоелса, башкалар моны тәнкыйтьләргә мөмкин», – ди ул.

Кызыксынуга китергән сәбәпләр арасында төп урынны коронавирус пандемиясе били, дигән фикердә белгеч. «2020 елда кешеләрнең кереме кимеде. Кәттә, «бренд»лы киемнәр кияргә генә күнеккән кешеләр яңа товарны үз бәясенә сатып алмаслык дәрәҗәгә җитте. Секонд-хендларның активлашуы шуңа да бәйле. Яхшы кибетләрдә киенергә иялэнгән кешеләр сыйфатка да иялэшкән була. Шуңа күрә алар, сыйфат та төшмәсен, артык акча да чыкмасын дип, шундый ук товарны арзангарак тәкъдим итә торган сату урыннарына йөри башлагандыр да. Үзләренең кесәсенә карап, тагын да түбәнрәк дәрәҗәдәге кибетләргә күчүчеләр дә булмады түгел», – ди Ләйсән Халикова.

Аның сүзләренчә, Россиядә генә секонд-хенд кебек кибетләргә сәер караш яши. «Европа, АКШта бу – норма. Бер генә киелгән яисә бер дә киелмәгән киемнәрне сату – анда гадәти күренеш. Бездә «Авито», «Юла» кебек белдерү сайтларын куллана башладылар инде. Моны мин оптимальләштерү ысулы дип саныйм. Әйтик, бер бәйрәмдә кигән күлмәгебез бар, ди, файдаланмый ята инде ул. Үзегезгә инде ярамаса да, ошамаса да, бүтән берәүгә ошарга һәм ярарга мөмкин бит. Ике якка да файдалы. Тузан җыеп ятасы кием матди ярдәм дә китерәчәк», – ди ул.

Ләйсән Халикова әйтүенчә, секонд-хенд кебек кибетләр тематик чаралар булганда аеруча ярап куя.

Зәвыклы һәм заманча киенергә булышучы белгеч Наилә Шиһапова, кешеләрнең кием-салымга булган карашы үзгәрә баруына шатланам, ди. Монда инде икътисади сәбәпләр белән генә чикләнергә кирәкми. Моны аңлы куллануга (разумное потребление. – **Ред.**) бер адым дип саный ул.

– Мондый кибетләрнең «хәерчеләр кибете» дигән аты бар. Россиядә бу хәрәкәткә карата фикер үзгәреше булуына сөенәм генә. Бу – дөрес юнәлештә фикер йөртү. Андый кибетләрдә еш кына бик матур, үзенчәлекле, башкаларда булмаган нәрсәләргә тап булырга мөмкин, – ди ул. – Бу кибетләр кешеләрнең акчасын да янга калдыра, үзенчәлекле итеп киенергә мөмкинлек тә бирә. Кайберәүләр гигиена ягыннан моңа шикләнеп карыйдыр. Шулай да, кием-салымны эшкәртмичә сатарга куймыйлар инде. Кайберәүләр әле аны кимичә, яңа килеш бирә. Мондый кибетләрдә нидер табуны сәләт дип саныйм.

Арзан, димәк, начар сыйфатлы. Практик психолог Зөһрә Кәримова сүзләренчә, баш миен мондый фикерләү рәвешеннән азат итәргә кирәк. Еш кына бик кыйммәтле саналган кием-салымнан да күңел кайтырга, аның сыйфаты түбән булырга мөмкин.

– Кием-салым сатып алганда да кеше өстенлекләрне билгеләсен иде. Әйтик, чүпрәк-чапрак җыю минем тормышымда ни дәрәҗәдә әһәмиятле? Белем алу, күнекмәләрне арттырудан мөһимрәкме ул? Шуны онытмыйк: кием кешене түгел, кеше киемне бизи. Бик кыйммәтле кием киеп тә фәкыйрь күренергә бик җиңел һәм киресенчә. Кием астында нинди күңел, җан асравың мөһимрәк, – ди белгеч. – Секонд-хендларга бу арада гына еш йөри башладылар димәс идем. Бу элек тә бар иде һәм шулай булачак та. Асылда, кешегә күп кием кирәкми дә. База булар берничә булса, җиткән. Кием-салым тиз туйдыра. Туйдырмасын өчен, стилист белән эшләргә кирәк. Шуңа да арзанракны сатып алып, аны берничә кат кию юлын сайлауны кулайрак күрәләр.

Кешегә дә бирәм, кешенекен дә киям

Кытлык заманасы түгел, дисәк тә, барлык кешенең дә бер төрле яшәмәвен күрсәтә торган күренешләр бар инде ул. Хезмәттәшебез Гөлгенә Шиһаповаңың фикере бу. Хәйрия, кешеләргә ярдәм итү юнәлешендә эшләгән журналистка кием-салым сорап игълан бирүчеләр аз түгел.

– Начар илдә яшәмибез, әмма шушы эш белән җәмгыятьнең кемгәдер күренеп бетмәгән китек якларын да күрәбез. Элегрәк башка берәүнең киемен киюдән кеше читенсенгән булса, соңгы елларда бу бер дә алай түгел. Бөтен әйбер кыйбат. Кеше кием кисенме, ашарына алсынмы? Кием сорап мөрәҗәгать итүчеләрем дә, сыйфаты ягыннан яраклы булган кигән киемнәре белән даими рәвештә бүлешүчеләрем дә, размерларын туры китереп өләшүче гаиләләрем дә бар, – ди ул. – Киемнәрне үзем белгән кешеләргә таратам. Кабул итеп алганнар гел рәхмәт әйтеп яши, кием кигән саен рәхмәт укый. Кемгәдер киемләтә булышу да сөенеч бирә. Булганны саклап ятканчы, кемгәдер файда китерсә, яхшырактыр.

Казаннан Энҗе Шакирҗанова, кеше кигән киемнәрне кияргә күңел тартмый, ди.

– Кечкенә вакытта апалардан калган киемнәрне еш кияргә туры килде инде. Хәзер бик күңел ятмый. Ничек кенә булса да, индивидуальлек яклымын. Киемдә кешенең энергиясе кала сыман. Секонд-хендлардан киемне шуңа да алмас идем, – ди ул.

Кукмарадан Айгөл Гатауллина һәр нәрсәнең, шул исәптән кием-салымның да практик кулланышта булуы яклы.

– Мин киемнең элгечтә эленеп торуын яки чормада тузан җыеп исраф булып ятуын яратмыйм. Кием искергән, киярлек түгел икән, мин аны чүпрәккә тотам яки ягам. Әле киярдәй, ләкин инде туйдырган яки тар калган киемнәрне мин очсызга гына сатарга куям. Шул рәвешчә, кием әрәм булмый, яңа хуҗасын таба, – ди ул. – Кайбер кеше энергия алмашы дигән ырымнарга ышана. Киемемне кешегә биргәннән соң энергиям сүнгәнен сизгән юк. Минемчә, бу – әкият. Киресенчә, шкафым кирәкмәс киемнәрдән бушап калгач, рәхәт булып китә. Мин үзем дә башкаларның киелгән киемнәрен сатып алып кигәлим, күптән түгел бик матур блузка алдым, мәсәлән. Кешедән алгач, әйбәтләп юам, үтүклим дә киемгә яңа тормыш бүләк итәм.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ФИКЕР

Александр ВАСИЛЬЕВ, мода, сәнгать белгече:
– Секонд-хенд – әйберләрне аңлы куллану урыны ул. Мода һәм текстиль җитештерү базары дөньяда әйләнә-тирә мохитне пычрату буенча икенче урында тора. Күп су, электр һәм буяулар сарыф ителә. Өстәвенә соңгы елларда дөньяда сыйфатлырак материалдан шактый матур кием-салым җитештерә башладылар. Кешегә теге яисә бу кием стиль буенча да, төс буенча да туры килә икән, кисен. Әлбәттә, ул кием-салым артык таушалган булмаса. Хәер, ертык джинс һәм өс киемнәре әле дә модада. Россиядә яшәүчеләрнең күпчелегенә кулланылган кием-салым сатып алырга мәҗүсилеккә ышану киртә булып тора. Күпләр, иске киемдә элеккеге хуҗасының җаны яши, дип саный. Шул кигән киемнән аның җаны чыгар төсле. Берәү дә чыкмый инде. Көя күбәләге очып чыкса гына...

(«Аргументы и факты» басмасына әйткән фикере)

САН

«PwC» хезмәте тикшеренүләреннән күренгәнчә, 2020 елгы коронавирус пандемиясе аркасында Россиядә яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы өс һәм аяк киемен сатып алуда үзен чикли башлаган. Шуларның 36 проценты кибетләрдә була торган ташламаларга ешрак игътибар бирә, 18 проценты арзанрак товарларга күчкән.

КИҢӘШ

- Киеп туйган, әмма әле киярлеге булган кием-салымны зур сәүдә үзәкләрендәге кибетләргә эшкәртүгә тапшырып, яхшы гына ташламага да ия булырга мөмкин. Минекен башка берәү кимәсен, дисәгез, шулай итәргә була.
- Зур шәһәрләрдә кием-салым кабул итә торган махсус пунктлар бар. Алар кулланышта булган ярыйсы гына сыйфатлы киемнәрне мохтаҗлар өчен җыя.
- Башкалада секонд-хенд кибетләре дә бар. Сыйфатлы, үзенчәлекле киемнәрне тапшырсагыз, алар да ташлама тәкъдим итәргә мөмкин.

10 гыйнвар | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК» 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ» 16+
11.00 «Оныта алмыйм...» 0+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «РОЖДЕСТВО НА ЛЬДУ» 12+
14.45 «Аулак өй» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Акыл баттл» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Әдәби хәзинә» 6+
18.00 «Мин» 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
00.00 «Вехи истории». Там, где в Каму врезаются лодки 12+
00.25 «Черное озеро»12+
00.50 «Соотечественники». София Губайдуллина 16+
01.15 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара» 6+
02.50 «ТАМАК» 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
07.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 6+
09.50 «Яратам». Концерт 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Наил Әюпов турында телеочерк (субтитрлы) 6+
14.00, 02.00 «Ком сәгате» 12+
15.20 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Ике аккош». Фатыйх Кәрим 6+
18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
19.10 «Ачытау». Зөһрә Шәрифуллина җырлый 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
03.25 «Оныта алмыйм» 6+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 02.15, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 Премьера. Анна Банщикова. «ИЩЕЙКА». Новый сезон (S) 12+
23.30 «Познер». Гость Марина Неелова 16+
00.35 «Вечерний Ургант». Лучшее (S) 16+
01.30 «Наедине со всеми» 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Детективный телесериал «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ» 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир». 16+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
00.40 «ЧЕЛНОЧНИЦЫ. ПРОДОЛЖЕНИЕ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.00, 12.30, 15.05, 18.35, 22.15 Новости
06.05, 22.20 Все на Матч! Прямой эфир
09.05 «Дакар – 2022» 0+
09.35 «КИКБОКСЁР 2: ВОЗВРАЩЕНИЕ» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.35, 02.45 Специальный репортаж 12+
12.55 «ДЕСАНТ ЕСТЬ ДЕСАНТ» 16+
15.10 Зимние виды спорта. Обзор 0+
16.10 «ГЛАДИАТОР» 16+
18.15, 18.40 «НОЛЬ-СЕДЬМОЙ» МЕНЯЕТ КУРС» 16+
20.25 «Громко» Прямой эфир
21.30 Смешанные единоборства. UFC. Лучшее 16+
22.55 Футбол. Кубок Англии. 1/32 финала. «Манчестер Юнайтед» – «Астон Вилла». Прямая трансляция
01.00 «ГОРОДСКОЙ ОХОТНИК» 16+
03.05 Новости 0+
03.10 Волейбол. Чемпионат России «Суперлига Париматч». Женщины. «Тулица» (Тульская область) – «Динамо – Ак барс» (Казань) 0+
05.00 «Громко» 12+

НТВ

05.05 «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
06.50 Детектив «НЕВСКИЙ. ПРОВЕРКА НА ПРОЧНОСТЬ» (S) 16+
08.00 Сегодня
08.25 «НЕВСКИЙ. ПРОВЕРКА НА ПРОЧНОСТЬ» (S) 16+
10.00 Сегодня
10.25 «НЕВСКИЙ. ПРОВЕРКА НА ПРОЧНОСТЬ» (S) 16+
13.00 Сегодня
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «НЕВСКИЙ. ПРОВЕРКА НА ПРОЧНОСТЬ» (S) 16+
16.00 Сегодня
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
19.00 Сегодня
20.00 «БИМ» (S) 16+
00.20 «ШУБЕРТ» (S) 16+
02.20 «ТАКСИСТКА» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.40 «Реальная мистика». «Смертельная любовь» 16+
07.40 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведёмся!» 16+
09.55 «Тест на отцовство» 16+
12.10 «Понять. Простить» 16+
13.15 «Порча». «Фамилица» 16+
13.45 «Знахарка» 16+
14.20 «Верну любимого» 16+
14.55 «ПИСЬМА ИЗ ПРОШЛОГО» 16+
19.00 «ЗДРАВСТВУЙ, ПАПА!» 16+
23.10 «ЧТО ДЕЛАЕТ ТВОЯ ЖЕНА?» 1-я – 5-я серии 16+
03.50 «Реальная мистика» 16+
04.40 «Верну любимого» 16+
05.10 «Порча» 16+
05.35 «Знахарка» 16+
06.00 «Понять. Простить» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «РЫСЬ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.25, 01.20 «ГОРОЖАНЕ» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир» 12+
13.25 «Сделано в СССР» 12+
13.40, 14.05 «РАЗВЕДЧИЦЫ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.30 «Специальный репортаж» 16+
19.00 «Битва коалиций. Вторая мировая война». Док. сериал 16+
19.45 «Скрытые угрозы» 16+
20.30 «Загадки века». Док. сериал 12+
21.15 Новости дня 16+
23.05 «Между тем» 12+
23.40 «ПИРАТЫ XX ВЕКА» 12+
02.45 «Другой атом». Док. фильм 12+
03.35 «РАЗВЕДЧИЦЫ» 16+

11 гыйнвар | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.00 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК» 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Оныта алмыйм...» 0+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 « Не от мира сего...» 12+
14.45 «Аулак өй» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Таяну ноктасы» 16+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. СКА – «Ак барс». Прямая трансляция 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
00.00 «Видеоспорт» 12+
00.25 «Соотечественники». На перепутье. Фатых Амирхан 12+
00.50 «Черное озеро». Базаровский беспредел 16+
01.15 «Реквизиты былой суеты» 12+
01.30 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
02.50 «ТАМАК». Телесериал 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Ком сәгате» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
07.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
08.00, 17.00, 22.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40, 16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 22.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.55 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
14.00, 02.00 «Ком сәгате» 12+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Тамчы-шоу» 6+
19.30 Хоккей. КХЛ чемпионаты. СКА (Санкт-Петербург) – «Ак барс» (Казан) 6+
23.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
03.25 «Оныта алмыйм» 6+
04.15 «Җырлыйк әле!» 6+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 02.10, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 «ИЩЕЙКА». Новый сезон (S) 12+
23.35 Мировая премьера. Экранизация романа Жюля Верна «ВОКРУГ СВЕТА ЗА 80 ДНЕЙ» (S) 16+
00.30 «Вечерний Ургант». Лучшее (S) 16+
01.25 «Наедине со всеми» 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека» 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Детективный телесериал «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ». 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
00.40 «ЧЕЛНОЧНИЦЫ. ПРОДОЛЖЕНИЕ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.50, 12.30, 15.05, 18.35, 21.50 Новости
06.05, 18.40, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
08.55 «Дакар – 2022» 0+
09.25 «ГЛАДИАТОР» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.35, 05.15 Специальный репортаж 12+
12.55 «ДЕСАНТ ЕСТЬ ДЕСАНТ» 16+
15.10 «МатчБол» 12+
15.45, 02.30 Матч! Парад 16+
16.10 «СЛЕД ТИГРА» 16+
18.15 «Есть тема!» 12+
19.25 Хоккей. КХЛ. СКА (Санкт-Петербург) – «Ак барс» (Казань). Прямая трансляция
21.55 Баскетбол. Евролига. Мужчины. «Монако» (Франция) – УНИКС (Россия). Прямая трансляция
00.45 «БОЛЬШОЙ БОСС» 16+
03.20 Новости 0+
03.25 Баскетбол. Евролига. Мужчины. «Зенит» (Россия) – АСВЕЛ (Франция) 0+
05.35 «Голевая неделя» 0+

НТВ

05.15 «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
06.50 Детектив «НЕВСКИЙ. ПРОВЕРКА НА ПРОЧНОСТЬ» (S) 16+
08.00 Сегодня
08.25 «НЕВСКИЙ. ПРОВЕРКА НА ПРОЧНОСТЬ» (S) 16+
10.00 Сегодня
10.25 «НЕВСКИЙ. ПРОВЕРКА НА ПРОЧНОСТЬ» (S) 16+
13.00 Сегодня
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 Детектив «НЕВСКИЙ. ПРОВЕРКА НА ПРОЧНОСТЬ» (S) 16+
16.00 Сегодня
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
19.00 Сегодня
20.00 «БИМ» (S) 16+
00.20 «ШУБЕРТ» (S) 16+
02.15 «ТАКСИСТКА» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.45 «Реальная мистика». «Сонное село» 16+
07.45 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.55 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча». «Засушка» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «ВТОРОЙ БРАК» 16+
19.00 «РЕФЕРЕНТ» 16+
23.00 «ЧТО ДЕЛАЕТ ТВОЯ ЖЕНА?» 6-я – 10-я серии 16+
03.45 «Реальная мистика» 16+
04.35 «Верну любимого» 16+
05.05 «Порча» 16+
05.30 «Знахарка» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «РАЗВЕДЧИЦЫ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.25, 18.30 «Специальный репортаж» 16+
09.45, 01.20 «К ЧЕРНОМУ МОРЮ» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир» 12+
13.25, 03.25 «Сделано в СССР» 12+
13.40, 14.05 «РАЗВЕДЧИЦЫ» 16+
14.00 Военные новости. 16+
19.00 «Битва коалиций. Вторая мировая война». Док. сериал. 2-я серия 16+
19.45 «Легенды армии». Иван Пересыпкин 12+
20.30 «Улика из прошлого» 16+
21.15 Новости дня. 16+
23.05 «Между тем» 12+
23.40 «НАЙТИ И ОБЕЗВРЕДИТЬ» 12+
02.35 «Антарктида. 200 лет мира». Док. фильм 12+
03.35 «РАЗВЕДЧИЦЫ» 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 10 – 16 ГЫЙНВАР

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Бу чор сезнең өчен тоташ кояшлы көннәрдән генә торыр. Башыгызга кызыклы идеяләр килер: аяз күктән яңгыр көтеп утырмыйча, аларны тиз генә тормышка ашыра башлыйсы! Җитәкчегез эштән китүегездән курка: шуңа күрә үзегезгә әйбәт кенә премия язмакчы...

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Хезмәттәшләрегез арасыннан берсе уңышларыгыздан көнләшә башламагае. Шуңа уй-фикерләрегезне сер итеп тотыгыз, уңышларыгыз белән мактанмагыз. Бу атна финанс мәсьәләсендә шәп кенә сюрпризлар белән сөендерер.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Яңа танышларыгыз барлыкка килер. Әмма арада әрсез-сөмсезләре дә булыр кебек. Һөнәри өлкәдә бик шәп үзгәрешләр көтелә: җитәкчегезгә хәтле талантыгыздан мәмнүн калачак. Тегеннән-моннан акча керү мөмкинлекләре нык артачак.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Барысы да әйбәт – борчылырга бер генә сәбәп тә юк. Ләкин артык хисләнеп китеп, тузга язмаган планнар гына кормагыз (әйтик, ел башында чираттагы ял алып, чит ил курортына барып кайту). Шулай да сәфәр чыгу көтелә. Бер генә тапкыр да түгел әле...

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Бу атнада кемнәргәдер юл куярга, кемнәрнеңдер сүзләренә колак салырга туры килер. Чынында сезгә бернинди дә авырлык тудырмаячак, киресенчә, үзегезнең өстенлекне генә күрсәтәчәк бу. Эшегез, моңарчы күрелмәгәнчә, искитмәле зур канәгатьлек хисе китерә башлаячак. Сәбәбе гади генә...

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Кыенлыкларсыз яши алмыйсыз, юк икән – үзегез уйлап чыгарырга әзерсез кебек. Шулай түгелме? Әмма бу көннәрдә барысы да тел-теш тидергесез булачак. Гәрчә җитәкчегез юктан да эш табып, бер секунд кул кушырып утырырга ирек бирмәсә дә.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Кайвакыт үзегезгә җиңелчәлек хас булса, бу атнада бу сыйфатыгызның эзе дә калмаячак. Җитәкчегез проблемаларны ничек итеп тирәнтен чишә белүегезгә шаккатачак. Атна ахырында дусларыгыз матди хәлегезне уңай якка борып җибәрердәй яңалыклар хәбәр итәчәк.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Эшләрегез, күз тимәсен, бик әйбәт барыр. Җитәкчегез үзегезне әледән-әле башкаларга үрнәк итеп куяр. Ләкин бер проблема бар: ул да булса – эшегездәге көнче күбәләкләр... Хәер, сезгә моннан әллә ни зыян юк, чөнки барыбер дусларыгыз алардан күбрәк.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Бу атна бик күңелле, мәгънәле узар. Шуңа көчегезне бер йодрыкка туплагыз да – алга! Кыенлыкларны җиңә белүегезне истә тотып, җитәкчегез үзегезне күп көч таләп итә торган, әмма акчалы проектлар белән күмәр.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Уңышлы, әйбәт атна. Тик ачыграк йөзле, аралашучанрак кешегә әйләнергә кирәк бугай. Шулай икән, бик кирәкле шәхесләр белән танышып, җылы һәм файдалы элемтәләр корачаксыз. Атна башында ук финанс хәлегез яхшырып китәчәк.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Кайвакыт үзегезгә зыян салырлык дәрәҗәдә кешеләргә шатлык китерергә яратасыз бугай. Әмма бу атнада үзегез турында кайгыртыгыз: карьера баскычы бушарга тора. Мөмкинлек булганда, үзегезне гаеплегә санамыйча гына, шуннан менеп китсәгезме!..

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Сез зирәк һәм сабыр, ә бу атнада нәкъ менә шушы сыйфатлар кирәк. Мөмкинлекләр күп булачак. Иң мөһиме – эчке сиземләүне югалтмаска. Җитәкчегез белән үзара киеренкелек узганда калып, бик яхшы мөнәсәбәтләр урнашачак.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Казан шәһәре «Факел» пионер штабының чыгарылыш укучылары дусларына, коллегаларына, танышларына штабның җитәкчесе, Казан шәһәре Вахитов районының Балалар иҗаты үзәге директоры, «Фанта» балалар авылы президенты

ЯРУЛЛИНА
Фаина Георгиевнаның

вакытсыз вафат булуын хәбәр итә. Ул һөнәргә тугрылык үрнәге булды, аның турында якты истәлек күңелләребездә мәңге саклаyнып.

КАТНАШ АЗЫК, АШЛЫК САТАМ.
Йомырка салучы тавыклар өчен катнаш азык

Адрес:
Казан, Техническая урамы, 15.
Телефон:
8 (927) 049-97-06

БИЗМӘННЕ ҮЗГӘРТЕР ЧАК

Озын бәйрәм яллары узып бара. Берничә көннән тормыш яңадан үз җаена кайтачак. Организмны да элеккеге халәтенә кайтарырга вакыт. Баллы, майлы, кыздырган ризык, тәм-томнар ашауга күнегеп өлгергән ашказаныбызны бушану көннәре генә коткарачак. Эшне нәрсәдән башларга? Укучыларыбыз игътибарына диетологлар киңәшләрен тәкъдим итәбез.

pixabay.com

1 Бәйрәмнәрдә артыгын ашап ташлаган өчен үзегезне тиргәмәгез. Теләге булган кеше дөрес тукланмау аркасында килеп туган проблемаларны берничә көн эчендә дә хәл итә ала.

2 Шулай да бер-ике көндә тиз генә артык авырлыктан котылып буласына өметләнмәгез. Бушану көннәре дөрес тукланмау аркасында пәйда булган күңел болгану, эч күбү, ашказаны борчу, хәлсезлек кебек билгеләрдән генә арындырачак.

3 Ашказаны-эчәк авырулары, хроник чирләре булган, өлкән яшьтәге кешеләргә, йөкле ханымнарга исә бу эштән тыелып торырга киңәш ителә.

4 Бушану көннәрен кисәк кенә башларга ярамый! Теләсә кайсы эшкә тотынгандагы кебек үк, аңа да алдан әзерләнергә кирәк. Бер-ике көн алдан аз-азлап җиңелчә ризык белән тукланыгыз. Клетчаткага бай ризыкларга (кишер, чөгендер, кыяр, кәбестә, карабодай һ.б.), кефир кебек ачы сөт ризыкларына өстенлек бирегез.

5 Бушану көннәрен атнага ике тапкыр гына үткәрү рөхсәт ителә. Бу көнне кабул ителгән калория күләме 1000нән дә кимрәк булмаска тиеш.

6 Бушану көнендә артык авыр эшләр, физик күнегүләр башкарудан да тыелып торырга кирәк. Көндәлек ризык күләмен чикләүне организм болай да авыр кичерә. Шуңа өстәп, әле аңа физик яктан да авырлык китерсәгез, тырышлыгыгыз озакка бармас.

7 Бушану көненнән соң кабат күп итеп ашаудан да сакланырга кирәк.

8 Бушану көннәрендә иң мөһиме: кәефегез күтәренке булсын! Сез бу адымга организмны матур һәм сәламәт итү өчен барасыз бит! Канәгатьсезлек хисе исә бөтен эшне бозып ташларга мөмкин.

Алмалы бушану көннәре. Көненә 5–6 тапкырга бүлеп, 1,5–2 килограмм алма ашарга кирәк. Алманың 1/3 өлешен пешереп ашау да файдалы булачак. Чөнки пешкән алмада пектин күбәя. Ә ул исә, үз чиратында, организмнан шлак һәм холестеринны яхшы чыгара.

Кефирлы бушану көннәре. Көн буена 2 литр майсызландырылган кефир эчәргә мөмкин. Шулай ук аңа яшел тәмләткечләр белән кыяр да өсти аласыз. Кефир авырлыкны гына көйләп калмыйча, иммун системасын да ныгыта.

Йогыртлы бушану көннәре. Майлылыгы 2,5% булган 8–10 стакан йогырт эчәргә киңәш ителә. Саклану вакыты ике атнадан артмаган йогыртны сатып алырга кирәк. Аларда тере культуралар күбрәк була.

Эремчекле бушану көннәре. 400 грамм эремчекне бер литр майсызландырылган кефир белән көнгә дүрт тапкыр ашагыз. Шикәр кушарга ярамый.

Карабодайлы бушану көннәре. Карабодайлы кефир белән ашарга кирәк. Бер стакан карабодайны кичтән 2–3 стакан кайнар суга салып, төнгә калдырыгыз. Тоз һәм май кушу тыела. Кефир белән эчкән очракта, карабодай ашкайнату системасын яхшырта, организм өчен кирәкле макро- һәм микроэлементларны арттыра.

Бушану көннәре өчен яшелчә ашы. Ашка өйдә булган бөтен яшелчәләрне салыгыз. Иң мөһиме – кәбестәне күбрәк турагыз. Ник дигәндә, ул ашкайнату юлларын чистарта. Кәбестәне эшкәртүгә организм бик күп энергия сарыф итә. Шуңа күрә ул артык калорияләрдән дә арындыра. Моннан тыш көн буена ике литрга якын сыеклык эчәргә тырышыгыз.

Белеп тор!

Билдәге майдан бер атна эчендә (!) дә котылып була икән! Германия табиб-диетологы Михаэль Деспегель шундый шаккатыргыч ачыш ясаган. Нечкә билле буласың килсә, «2+2+4» формуласы буенча яшәргә кирәк, дип өйрәтә табиб. Моның өчен атнасына ике тапкыр кардиокүнегүләр, ике тапкыр көч таләп итүләр торган тренировка ясарга кирәк икән. Беренче төркем күнегүләр, матдәләр алмашын көчәйтеп, йөрәк һәм үпкәләр эшчәнлеген яхшырта, икенчесенә кергәннәре мускулларны ныгыта. Тренировка булган көннәрдә, ягъни атнасына дүрт тапкыр дөрес итеп тукланырга, рациондагы калорияләрне дә санарга кирәк. Калган көннәрдә исә гадәти режимда тукланырга, югары калорияле ризыклар ашамаска киңәш ителә.

Киңәш-табыш

Тирләү авыруга булмасын

Гадәти булмаган тир исе берничә житди авыру, шул исәптән яман шеш билгесе булырга мөмкин. Россия дерматологы Ирина Скорогудаева шулай дип белдергән. Табиб сүзләренә караганда, яман шеш авыруы башланган кеше күбрәк тирли башлый һәм тирдән бозылган ит исе килә. Яман шешкә каршы көрәшкәндә, кешенең тән температурасы күтәрелә һәм аны төшерү өчен, организм терморегуляция системасын эшләтеп җибәрә. Шул рәвешле кеше нык тирли. Табиб белдерүенчә, шикәр авыруы булган кешеләрдән – еш кына ацетон яки пешкән алма исе, бавыр һәм бөер авырулары булганнардан аммиак исе килә башлый.

Лимон согы коткара

Аягын көзән җыерудан интеккән кешеләргә лимон согы ярдәмгә киләчәк. Моның өчен табан астын иртә-кич лимон согы белән уарга кирәк. Оекбашны сок аякка тулысынча сеңеп беткәч кенә киясе. Нәтиҗәсе булсын өчен, моны 14 көн дәвамында эшләргә кирәк. Суган кабыгын төнәтү дә көзән җыерудан котылырга ярдәм итә. Моның өчен бер чәй кашыгы вакланган суган кабыгына бер стакан кайнар су салып, 10 минут төнәтергә кирәк. Аны йоклар алдыннан эчсәң, төнлә аякны көзән җыерудан куркасы юк.

Чәч коелмасын, дисәң...

Алоэ гөле чәчләр өчен иң файдалы чараларның берсе санала. Ул чәчләрне ныгыта, тукландыра, иң мөһиме, коелуын туктата. Алоэ гөленең аскы яфракларын кисеп, марляга төрегез дә бер атна суыткычта тотыгыз. Аннары яфракны чистартып, блендерда ваклагыз. Килеп чыккан катнашманы марляга салып, согын чыгарасы. Шушы сокны атнага бер тапкыр чәч төпләренә сөртергә кирәк. Юып төшерәсе юк!

Файдасын күрегез

Чыршы мае шифалы

Ак чыршы (пихта) мае бик күп чирләрдән дәва булып тора.

✷Тын юллары өчен файдалы. Аны астма, пневмония, бронхит, грипп вакытында кулланалар. Ютәлләгәндә аны аркага, күкрәккә сөртеп, җиңелчә массажлап ятарга кирәк.

✷Бактерияләрне юк итә. 5 тамчы пихта маен су белән кушып, аромалампага салырга кирәк. Шул рәвешле ул бүлмәне дезинфекцияли.

✷Авыртуны баса, тукымаларны яңарта. Җиңелчә яраланганда, пешкәндә ярага ак чыршы маен сөртеп куйсаң, авырту басылачак.

✷Ютәл вакытында эмальле кәстрүлдә кайнап торган суга 3–4 тамчы май тамызып, башны сөлге белән каплап, шифалы парны суларга мөмкин.

✷Борынга томау төшкәндә, борын тишегенә берәр тамчы май тамызсаң да файдасы тия. Ак чыршы мае йөткерүне дә бетерә.

✷Грипп, ОРЗ, ОРВИ вакытында, үпкәләр ялкынсынганда, күкрәкне коры тукыма белән ышкып, ак чыршы мае сөртеп, ябып йоклау да бронхитка каршы үтемле чара булып тора. Моның өчен һәр 5–6 сәгать саен арка, күкрәкләрне яхшылап ышкырга, массаж ясарга кирәк. Һәр процедурадан соң авыруны яхшылап төрергә, йон оекбаш киертергә, өстенә җылы юрган ябарга һәм үләннәрнең кайнар төнәтмәсен эчерергә киңәш ителә. Иртән һәм кичен пипетка белән тел төбенә 3–5 тамчы ак чыршы яки көнҗет мае тамызсаң да, файдасы тими калмас.

Үзем сынадым

Иммунитетны ныгытабыз

Соңгы елларда иммунитетны ныгыта торган бер катнашма кулланабыз. Аллага шөкер, файдасы сизелә. Аны ясау өчен 300–350 грамм имбир тамыры, 150–200 грамм бал һәм 1–2 лимон кирәк. Имбир тамырының кабыгын әрчеп, зур булмаган кисәкләргә бүләбез. Лимонны өлешләргә кисеп, орлыкларын алабыз һәм икесен дә иттарткычтан чыгарабыз. Бал кушып, бик яхшылап болгатабыз. Шуны көнгә бер бал кашыгы ашарга кирәк. Катнашма бик әче. Шуңа аны чәйгә болгатып эчсәң дә була. Имбирне, башка дарулар кебек үк, сак кулланырга кирәк. Ашказаны-эчәк авырулары көчәйгәндә, аны эчми торырга киңәш итәбез.

Әлфия З. Әлмәт

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

БЛЕНДЕРНЫ НИЧЕК САЙЛАРГА?

Хуҗабикәләрнең алыштыргысыз ярдәмчесе – блендер сайлау өчен хәзер менә дигән вакыт. Бердән, сайлау өчен вакыт иркен, икенчедән, кибетләрдә Яңа ел ташламалары белән алу мөмкинлеге бар. Әлбәттә, бәйрәм ялларында табын янында озаклап утырулар да үз эшен эшләми калмады. Чамадан артык калорияле ризыклардан соң файдалы, җиңелчә смузи, коктейльләргә күчү өчен дә блендерның кирәге чыгар. Аны сайлау буенча электроника кибете консультанты Дамир Ильясов биргән киңәшләр укучыларыбызга файдага булыр.

pixabay.com

Кайсын сайларга?

Сабыннан тотып, савыт эчендәге ризыкны вата-ваклый торган батырма (погружной) блендер яхшыракмы әллә касәсенә салып болгата торган стационармы? Дамир Ильясов әйтүенчә, халык батырма блендерны күбрәк сатып ала. Ул җыйнак, шкафка тыгып куярга да, кирәк чагында үзең белән йөртергә дә уңайлы. Ә смузи, коктейльләр, аш-пюрелар, гомумән, сыек ризыклар ясау өчен касәле, ягъни стационар блендер яхшырак. Ник дигәндә, батырмасыннан аермалы буларак, ул сыеклыкны чәчрәтми. Ризыкны ваклаганда, болгатканда кулда тотып торасы юк – үзе генә «эшли».

Ничек сайларга?

• **БАТЫРМА БЛЕНДЕР.** Иң мөһиме – егәрлегенә игътибар итегез. 140тан 20000 Ваттка кадәр егәрлектә була. Никадәр көчлерәк булса, ризыкны шуның кадәр тизрәк эшкәртә һәм моторы да азрак җылына. Иттән фарш ясау, боз, чикләвек, туңдырылган яшелчә ваклау өчен 600–800 Вт егәрлегендәге җайланма сатып алырга кирәк. Йомшак продуктларны ваклау өчен 450 Вт егәрлегенә кадәргесе дә җитә. 1000 ваттан зуррак булганы «профессиональ» дип атала һәм ул асылда барлык ризыкны да эшкәртә ала. Әмма мондый җайланма кыйммәт тора.

Колагыбызга киртләп куелырга тиешле тагын бер әйбер – төп насадкасының тимердән эшләнгән булуы әйбәт. Бу бик кайнар ризыкларны да эшкәртү мөмкинлеге бирәчәк, озак ватылмаячак. Ул шулай ук исне сеңдерми һәм яшелчә төсенә буялмый. Тизлегенә килгәндә, бик күп тизлеклесен (блендер1дән 30га кадәр тизлеккә ия) алудан мәгънә юк. Ышанычлы, гади җайланмага ия булырга теләсәгез, 1–2 тизлек режимына ия булганына тукталыгыз. Күп дигәндә, 5–6 тизлеклесен алыгыз, башкасы кирәкми.

• **СТАЦИОНАР БЛЕНДЕР.** 250дән 1500 Ваттка кадәр егәрлектә була. Смузи, коктейльләр һәм аш-пюрелар әзерләү өчен артык көчле блендерның кирәге юк: 300–500 Ваттлысы да җитә. Чикләвек, туңдырылган җиләк, бозны еш ваткларга кирәк икән, 750–900 Вт егәрлектәгесе әйбәтрәк. Ә инде камыр басу өчен кимендә 1000 Ваттлысын сайлап алырга кирәк. Стационар блендер гадәттә 1–20 тизлеккә ия. Артык күп тизлеклесенә кызыгырга кирәкми. 2–4 тизлеклесе дә хуҗабикәләргә бик зур ярдәмче булачак. Мондый блендер бер яки ике пычаклы булырга мөмкин. Күбрәк пычаклысы ризыкны тизрәк ваклый. Бөгелгән пычаклысы әйбәтрәк: ризыкны бик тиз генә боламыкка әйләндерәчәк.

Күләменә килсәк, 1,5–2 литрлы касәдә берничә кешегә эчемлек яки аш әзерләргә була. Ә инде 1 литрлысы балалар ризыгын әзерләү өчен җитә. Пластик касәле блендер арзанлырак, юу-чистартуы да җиңелрәк. Кайнар ризыкларны еш болгатырга кирәк булмаса, шунысын алыгыз. Ә пыяла касәлесе чыдамрак, кайнарга да бирешми. Ләкин кулдан төшеп китсә, эштән чыгачак. Иң әйбәте – тимердән эшләнгәне. Ләкин кимчелекләре дә юк түгел. Беренчедән, башкаларына караганда кыйммәтрәк, икенчедән, үтә күренмәле булмау сәбәпле, ризыкның ничек ваклануын күзәтеп торып булмый. Шуңа кайсына өстенлек бирәсен үзегезгә хәл итәргә кала.

Белеп тор!

Кайры тун серләре

Беркайчан да модасы чыкмый торган бик уңайлы, җылы, җиңел тун бу. Ләкин аны саклык белән генә кияргә кирәк.

✓ Җылытып җибәрсә, юеш кар явып торса, кайры тунны элгечтә калдыруың хәерле.

✓ Бигрәк тә ачык төстәгесе яктылыкны яратмый. Шуңа күрә аны шкафта саклау хәерле. Шул ук вакытта аның башка киемнәргә тимичә генә эленеп торуы кирәк.

✓ Кием өстенә сезонга берничә тапкыр су үткәрми торган аэрозольле сыекча сиптерегез. Ул тиренең төсен үзгәртми, аның каравы, тышкы катламын дымнан саклый.

✓ Юеш карга эләксәгез, утырмаска тырышыгыз. Юкса билдән түбән өлешендә тап барлыкка киләчәк. Кыска тунның аскы төймәләрен чишеп, киемне күтәреп утырыгыз.

✓ Төймәсе өзелеп төшсә, болай эшләгез. Берәр нинди иске киемнән төймә зурлыгында күн кисәге кисеп алыгыз. Тунның эчке ягында төймә турындагы мехны кыркыгыз. Шуңа «Момент» җилеме белән күн кисәген ябыштырыгыз. Ике төймә (берсе – тунныкы, икенчесе – кечкенә төймә) алып, шуларны тире кисәге аша тегеп куегыз. Тегеп бетергәч, җепнең очын янә җилем белән ябыштырыгыз.

✓ Иң кыены – яка, җиң, кесә кырыйларының пычранып, ялтырап торуын бетерү. Бу очракта нашатырь спирты һәм теш пастасы ярдәм итәчәк. Шушы ике әйберне болгатып, тунның пычранган урыннарына сөртегез һәм табигый кылдан эшләнгән щетка белән ышкыгыз. Пычрак таплар, һичшиксез, юкка чыгачак.

Шушы киңәшләрне тотканда, кайры тунны, матурлыгын саклап, бик озак киеп йөри алачаксыз.

Исеңдә тот!

Тузан сөртү өчен – «лимонлы» чүпрәк

Йорт җиһазларына тузан тиз генә кунмасын өчен нишләргә? Хуҗабикәләрне иң нык борчыган сорауларның берсе бу. Моның өчен, «химия» кулланмыйча, болай эшләргә мөмкин. Бер лимонны кечерәк өлешләргә бүлеп, шуңа 7 аш кашыгы үсемлек мае салабыз һәм бер атна тотабыз. 1 стакан кайнап торган су өстәп, эремәне сөзәбез. Чүпрәкне шунда чылатып, корытып сыгабыз һәм киптерәбез. Җиһаздагы тузанны шул чүпрәк белән сөртәбез. Чүпрәкне чиста суда юып, янә шулай әзерләп куябыз.

Тәмле булсын!

БАНАНЛЫ-ИМБИРЛЕ СМУЗИ

Римма Хафизова рецепты

Ашкайнатуны яхшырта, организмны шлаклардан чистарта.

Кирәк булачак: *1 аш кашыгы бал, ярты чәй кашыгы угыч аша уылган имбир, бер банан, 1 стакан йогырт.*

Барысын да блендерга салып күпертәбез. Тәмле, шул ук вакытта бик файдалы эчемлек!

ФАСОЛЬЛЕ ЯШЕЛЧӘ АШЫ

Гөлчәчәк Сәгыйтова рецепты

Кирәк булачак: *500 г тавык ите, кечерәк кенә 1 ташкабак, 300 г кабак, 1 банка консервланган кызыл фасоль, 1 баш суган, 2 сабак сельдерей («черешковый»), уртача зурлыктагы 1 кишер, дәфнә яфрагы, түгәрәк борыч, тәменчә тоз һәм үсемлек мае.*

Итне 3–5 литр суга салып, кайнап чыкканнан соң туртасын алгач, 40 минут пешерәбез. Кишер һәм сельдерейны – шакмаклап (ваграк), суганны – боҗралап турыйбыз да үсемлек маенда 3–4 минут кыздырып алабыз. Ташкабак һәм кабакны да шакмаклап турап, шунда салабыз. Тагын 3–4 минут кыздырабыз. Фасольне суыннан саркытып, кыздырылган яшелчә белән бергә шулпага салабыз. Аш әзер булганчы пешерәбез.

ЧӘЧӘКЛӘР ОЗАК САКЛАНА

Чәчәк вазасына салынган су тиз болгана, исләнә. Бу хәлдән котылу өчен суга 1 чәй кашыгы кер агарткыч (отбеливатель) өстәргә кирәк. Су бер атна чамасы тонык килеш сакланачак, чәчәкләр дә тиз сулмаячак. Бәрәңгене ваграк кисәкләргә бүлеп, вазадагы суга салганда да шулай булачак.

Валентина СЕМЕНОВА әзерләде

АВЫРУДАН АРАКЫ КОТКАРМЫЙ

Күп кенә тыелган нәрсәләрне дә рөхсәт итәрлек сәбәп кенә бир безнең халыкка. Хәмер эчү белән дә шулай. «Табиб кушты», «сәламәтлек өчен» дип, берне тотып куючылар азмыни?! Юкка гына хәдисләрнең берсендә: «Аракы – бөтен усаллыкның анасыдыр», – диелми инде. Динебездә хәмер эчүне гөнаһ буларак кабул итмәгән искәрмә очраклар бармы? Хәмер белән ешрак нинди кешеләр дуслаша? Аракы сату – гөнаһмы?

Сәхифәбез кунагы – «Тәүбә» мәчетеннән Артур хәзрәт ГАБДУЛЛИН белән шушы һәм башка сорауларга җавап эзләдек.

:: Адәм баласына Аллаһы Тәгалә тыйган гамәлләр арасында хәмер эчү дә бар. Пәйгамбәребез чорында эчкечелек булганмы?

– Пәйгамбәребез (с.г.в.) бу дөньяга килгәнче, гарәпләр бик әдәпсез җәмгыятьтә яшәгән. Бүген гарәпләр дигәндә күз алдыбызга мөселман кешесе килеп басадыр. Ул чорда алай булмаган. Хәзерге заманда нинди бозыклык гамәлләр таралган булса, 1400 ел элек пәйгамбәребез (с.г.в.) туганчы да шулай булган. Аларда шәраб эчү киң таралган булуы мәгълүм. Пәйгамбәребез (с.г.в.) дөньяга килеп, Аллаһы Тәгалә аны пәйгамбәр иткәч, ул дингә, яхшылыкка өнди башлый. Әдәплелеккә чакыруын шундук кабул итмиләр. Каршы торучылар була. Аллаһы Тәгалә хәмерне ничек тыя? Сез эчкән хәмердә сезнең өчен файда бар, әмма зыяны күп тапкыр артыграк, ди ул. Бу – хәмерне тыюның беренче этабы, дисәк тә була. Аллаһы Тәгалә шундук «бетте, эчмисез» дигән мәгънәдәге аятьне индерми. Чөнки аны кабул итмәсләр, эчүләрен дәвам иттерерләр иде. Аллаһы Тәгалә монда да үзенең хикмәт иясе булуын күрсәтә. Күпмедер вакыт үткәч, Аллаһы Тәгалә икенче аять җибәрә. Монда инде тыю да каттыйрак була. «Исерек килеш намазга якын килмәгез», – диелә. Моннан соң кеше тагын да ныграк уйланырга тиеш була. Бу – икенче этап. Өченчесе – хәмерне тулысынча тыю. Аллаһы Тәгалә бу аятендә комарлы уеннарны, исерткеч эчемлекләрне, ирләргә ефәк киемнәрне хәрам кылды. Күргәнегезчә, хәмер эчү тиз генә тыелмаган. Галимнәр: «Шуннан соң гарәпләр яшәгән урамнар шәраб белән тулды, ул урамнардан елга шикелле акты», – дип әйтә.

:: Кайберәүләр, стрессны киметү өчен, кичен берне тотып куя. Мәшәкатьтән котылуның бер ысулын шешәдә күрә.

– Кеше хәмер эчәр өчен йөз төрле сәбәп табарга мөмкин. Бәйрәм булсынмы, күңелне күтәргән берәр вакыйга, стрессны киметүме... Алар күп. Әлбәттә, бу бик үк дөрес гамәл түгел. Кеше кайвакыт: «Тормышымда авыр вакыт. Бераз эчсәм, ярдәм итәр», – дип уйлый. Ләкин бу кеше үз-үзен алдый бит. Бу гамәле аны берничек тә коткармый. Ул аның аңын томалап, исертеп, берничә мизгелгә сызлавын басып кына тора. Айныгач, янәдән шул ук мәшәкатьләр өермәсенә кайта. Сызлануы көчәя генә.

Кеше гомере буе максат куеп яши. Әйтик, өй салырга тели ди. Аны төзү өчен күпме көч, акчасын сарыф итә. Зур теләк бит! Максатына ирешә ди. Ләкин берничә ел яшәгәннән соң, бу өй дә гадәти бер нәрсә булып кала. Нидер үзгәртәсе килә башлый. Кешенең психологиясе шундый. Нидер тели, максатына ирешә, сөенечe күңеленә вакытлыча гына тынычлык бирә. Эчкән кеше белән дә шул ук хәл. Мәшәкатьләрдән арыну юлларын ул башкадан эзләргә тиеш.

Аллаһы Тәгалә безне юктан бар иткән. Кем безнең мәшәкатьләрне хәл итә ала? Сине бар иткән зат. Ул безгә мәшәкатьләрне бирә. Уйласын өчен бирә. Хәмергә бата башлыйсың икән, Аллаһы Тәгалә дә ныграк чарасын күрәчәк. Андый мисаллар күп.

Бер гөнаһка да сәбәп эзләргә кирәкми. Аны бөтенләй кылырга ярамый. Түзеп, тыелып калганың өчен Аллаһы Тәгалә әҗерен дә бирер.

:: Хәзрәт, хәмер эчү – бер хәл. Аның белән сату итү, тарату, буләккә бирү дә гөнаһ саналадыр инде?

pixabay.com

– Аллаһы Тәгалә исерткеч эчемлекне эчүчене, эчертүчене, сатучыны, сатып алучыны, ясаучыны, ясатучыны, алып килүчене һәм китертүчене – бөтен кешене дә ләгънәт кылды. Гомумән, бу гөнаһлы эштә катнашкан, үз өлешен керткән һәр кеше гөнаһлы санала. «Мин бит күтәреп кенә тордым, илтеп кенә бирдем», – дип котылып та, тынычланып та булмый. Ниндидер гөнаһны эшләүгә өлеш кертүдән баш тарту кирәк.

:: Хәзер исерекләр сизелерлек кимеде. Авылларда да исереп ятучылар юк. Ни өчен алар бетми соң?

– Чынлыкта, эчүчеләр кимеде дип әйтеп булмый. Ул бит әле урамда исерек килеш аунап ятучы гына түгел. Хәмер капкан һәр кеше эчүче санала. Күпләр өйдә генә эчә. Хәбәрләрдә дә еш ишетәбез бит: фәлән кеше өендә эчкән дә фәләнне үтергән. Барыбер дә бу гөнаһтан барысы да баш тартмаган. Аннан баш тарта алмаган кешеләр һәр чорда да була. Ул имансыз кешенең тормышындагы бер яхшы дусты кебек. Дус белән аерылышып булмый. Тик бу дус куркыныч нәрсәләргә китерергә мөмкин. Аллаһы Тәгалә сакласын.

:: Хәзер коронавирус һәм башка чирләрне дәвалау өчен дә халык арасында «берне тотып куярга кирәк» дигән сүзләр йөри. Чир дәвасы хәмер була аламы?

– Аллаһы Тәгалә чирне бирә икән, ул аннан дәвасын да бирәчәк. Кеше үз-үзен алдарга, шифа юк җирдән шифа табарга тырыша. Чынбарлыкта, дәвалану, шифа алу Аллаһы Тәгалә рөхсәт иткән нәрсәләрдә бар. Ниндидер чирдән азат булу өчен шәраб, аракы эчәргә кирәкми. Әйттек бит: файдасы булса да, зыяны мең кат күбрәк. Киресенчә, бу нәрсә сине һәлак итәчәк. Бер эчеп карагач, иртәгә туктаячагыңны гарантияли аласыңмы?

Пәйгамбәребез (с.г.в.) кара әнечтә (тмин) үлемнән кала барлык чиргә дәва барлыгын әйтә. Аның тормышына игътибар итсәк, ул иң гади нәрсәләрдән файдаланган. Әйтик, иртән торгач, суга бал болгатып эчкән. Кара әнеч кулланган. Мондый мисаллар күп.

:: Хәмер белән кемнәр ешрак дуслаша? Шайтан коткысына кемнәр бирелә?

– Аллаһы Тәгаләне танымый торган, диннән ерак, иманы зәгыйфь кешеләр хәмер белән дуслаша. Хәзер җырларда да, кинода да андый тискәре күренешләр бар. Алар да тәэсир итә. Шайтан үзенекен эшли.

:: Намаз да укый, уразасын да тота, әмма шул ук вакытта хәмер дә эчә торган кешеләр турында ни әйтерсез?

– Җавап гади: андый кешенең уразасы да, намазы да кабул булмый. Кеше ике фронтка хезмәт итә алмый. Берсен генә сайларга кирәк. Шайтан вәсвәсәсенә бирешергә кирәкми.

КЕШЕЛӘР АНЫ ЭЗЛӘМИ

Гыйбрәт ал!

Бер кеше чәчтарашханәгә чәчен алдырырга килгән. Чәч остасы белән сөйләшә башлагач, аларның сүзләре Аллаһы Тәгалә турында ялганып китә. Чәчтараш шулвакыт:

– Миңа ни генә сөйләсәләр дә, Аллаһы Тәгалә бар дип уйламыйм, – дигән.

– Ни өчен?

– Бу болай да аңлашыла бит инде. Урамга гына чыгып карагыз. Менә әйтегез әле, Аллаһы Тәгалә бар икән, каян килә шулкадәр мохтаҗлар, авыру кешеләр? Каян килә ятим, караучысыз калган балалар? Әгәр ул чынлап да булса, Җир йөзендә кайгы-хәсрәт, михнәт-золымнар, авырулар булмас иде. Бәндәләрне яратучы Аллаһы Тәгаләнең шундый кайгы-хәсрәтне, михнәт-золымнарны, авыруларны күрми калуын күз алдына да китерү кыен.

Кеше бу сүзләрдән соң уйга калды, тик бәхәскә кермәс өчен, дәшмәде. Чәч остасы үз эшен тәмамлады, кеше аңа акчасын түләде дә чәчтарашханәдән урамга чыгып китте. Һәм аның каршысына чәч-сакаллары кендегенә кадәр диярлек үскән, кырынмаган бәндә очрады. Шулчак кеше чәчтарашханәгә кире борылып керде дә чәч остасына сүз катты:

– Беләсезме, мин сезгә нәрсә әйтәм? Чәчтарашлар юк.

– Ничек инде юк?! – дип гаҗәпләнде чәч остасы. – Ә мин нәрсә? Мин чәчтараш түгелме? Менә бит ул мин, сезнең каршыгызда...

– Юк! Алар булса, әнә теге адәм кебек, чәч-сакалы кендегенә җиткән бәндәләр булмас иде, – дигән кеше, урам буйлап китеп баручыга ымлап.

– Соң бит монда гаеп чәчтарашларда түгел. Кешеләр миңа үзләре килми.

– Соравыгызга үзегез үк җавап та бирдегез. Аллаһы Тәгалә бар һәм бер! Адәм балалары Аны эзләми, Аңа гыйбадәт кылмый. Шуңа күрә дә дөньяда шулкадәр күп гаделсезлек, кайгы-хәсрәт һәм авырулар...

Өч хәдис

- Дәреслектә, Аллаһы Тәгалә сезнең тәннәрегезгә, йөзләрегезгә карамый, әмма Ул сезнең йөрәкләрегезгә карый.
- Әти-әнигә бәйле иң мәрхәмәтле эш – алар якын иткән, аралашкан, яраткан кешеләр белән элемтәне өзмәү.
- Йокыдан торгач, кулыгызны, өч мәртәбә юмый торып, аш савытына таба сузмагыз, чөнки йоклаганда кулыгызның кайда йөргәнен белмәс.

Мисвак – Аллаһы ризалыгына бер сәбәп

Мисвак турында күпләрнең ишеткәне бардыр. Бу – теш чистарту өчен арак дигән агачтан ясалган таякчык. Ул көндәлектә кулланыла торган теш щеткасына охшаган. Исламда мисвакны куллану хәерле гамәл (сөннәт) санала.

Расүлебез: «һәр намаз алдыннан тешләрегезне мисвак белән чистартыгыз, дип әйтер идем. Тик сезнең моны фарыз дәрәҗәсенә җиткерүегез бар дип куркам. Шуңа күрә кат-кат әйтмим», – дигән.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

ЭЛЬМИР НУРГАЛИЕВ:

«КАЙЧАК ТАМАШАЧЫ БЕЗ АҢЛАМАГАННЫ ДА АҢЛЫЙ»

«Ни хәл?» сәхифәсенең яңа елдагы беренче кунагы – Әлмәт театрының яшь артисты Эльмир НУРГАЛИЕВ. Ни өчен егет театрны сайлаган? Башкаладан читтә эшләүче актерларга игътибар җитәме? Әлмәт театрындагы экспериментлар, рэп һәм хыяллар – без әнә шул хакта сөйләштек.

:: Эльмир, балачагың турында сөйлә әле.
– Тумышым белән Сарманнан булам. Балачагым да шунда узды. Сәхнәнең тарту көчен электән сизгәнмен, ахры: кечкенәдән үк төрле иҗади түгәрәкләргә йөрдем, чараларда катнаштым. Театр дөньясына беренче адымнарымны Сармандагы халык театрында ясадым. Мәктәпне тәмамлагач, нинди һөнәр сайлыйм икән, дигән уй булмады диярлек. Әти-әнием – сәнгать кешеләре, алар Алабуга сәнгать көллиятендә табышып кавышканнар. Мин дә нәкъ менә шул уку йортын сайладым.

:: Сәнгать өлкәсендә эшләүчеләр арасында үз балаларын бу юлдан җибәрергә теләмәүчеләр дә бар бит. Синең әти-әниең каршы түгел идеме?
– Юк, киресенчә, сөенделәр генә. Алар өчен иң мөһиме минем үземә ошаган юлны сайлавым иде. Шулай булды да.

:: Ни өчен театр?
– Янәшәмдәге кешеләр һәрвакыт: «Сиңа театрда уйнарга кирәк!» – дип әйтәләр иде. Иң көчле этәргеч менә шул булгандыр.

:: Ә менә нәкъ Әлмәт театрын сайлавыңның сәбәбе нидә?
– Әлмәткә кадәр мин Әтнә театрында эшләп алдым. Анда безне көллиятне тәмамлагач чакырдылар. Ел ярым эшләгәннән соң, туган якка кайтасым килде. Әтнә – Сарман арасы бик ерак бит, сирәк кайтыла иде. Әлмәт театрына барып карадым. Бердән, якын булгач, икенчедән, мондагы шартлар да күңелемә хуш килде. Беренче мәлләрдә җиңел чаклар да, авырлыклар да булды. Монда эшли башлавыма дүрт ел инде.

:: Киләчәктә Казанга килү теләгең юкмы?
– Теләк бар, ләкин әлегә кистереп кенә әйтә алмыйм. Бүген мин үз урынымнан канәгать.

:: Гомумән, театрны ташлап, башка юнәлеш сайлыйсың килгән чакларың буламы?
– Була, ләкин мондый мизгелләрне вакытлыча авырлык итеп кабул итәргә кирәк дип уйлыйм. Андый чакта игътибарымны башка эшкә юнәлтеп, онытылып торам. Шуннан соң барысы да үз урынына кайта.

Блиц-сораштыру

– Актерлар арасында дуслык бармы?
– Үзебезнең мисалдан чыгып, «әйе» дип җавап бирәм.
– Йөрәгең бушмы?
– Әйе.
– Өйләнү турында уйланасыңмы?
– Ашыкмыйм. Һәр нәрсәнең үз вакыты бит. Әлегә күңелгә ятышлы кешемне очратмадым.
– Актер булмасаң, ...
– ... музыкант булыр идем.
– Нәрсәне кичермәс идең?
– Хыянәтне.
– Иң зур хыялың?
– Бу тормышта эз калдыру.

:: Башкаладан еракта булганга микән, сез – безнең өчен тансык...
– Казан тамашачысы башка инде ул. Алар каршында уйнау үзе бер рәхәт. Без дә бик сагынып киләбез, елга бер мәртәбә булса да спектакльләребезне тәкъдим итәргә тырышабыз. Кыскасы, безнең якын араларны чакрымнар гына ерагайта алмый.

:: Казан тамашачысы башка, дисең, ә әлмәтлеләр нинди алайса?
– Кемнедер яхшы, кемнедер начар, дип һич әйтәсем килми. Тамашачыларның без күрсәткән әсәрләрне ничек кабул итүләре аерыла. Мәсәлән, Әлмәт тамашачысыннан тәнкыйтьнең көчлерәге әләгергә мөмкин. Тамашачыларның энергетикалары төрле, ә без моны яхшы сизәбез.

:: Әлмәт театры экспериментлар ярата. Сез еш кына чит ил авторларына да мөрәҗәгать итәсез. Актерлар өчен катлаулы тәҗрибәме бу?
– Хәзер моңа ияләнеп киләбез инде. Без – чыннан да, экспериментлар өчен ачык театр. Төрледән-төрле фестивальләрдә дә еш катнашабыз. Башта кыенрак булды. Күп нәрсә аңлашылмый, күргән булмагач, күрсәтергә дә авыр иде. Фестивальләрдә йөри-йөри, башкаларны күзәтә-күзәтә тәмам күнектек моңа. Хәзер исә барысына да җиңел карарга тырышабыз.

:: Ә тамашачы сез керткән яңалыкларны, экспериментларны аңлыймы?
– Төрлечә. Әмма кайвакыт тамашачы без аңламаган әйберне дә аңлый ул.

:: Эльмир, сезнең труппада җырлый белмәүчеләр юк, ахры?
– Укыганда ук, Әлмәт театрына җырлый белүчеләрне генә алалар, дигән сүзләр ишетелә иде. Үзем биредә эшли башлагач, аны-моны сизмәдем кебек. Барыбызның да диярлек яхшы җырлавы, бәлки, очраклы хәлдер. Дөрес, спектакль алдыннан вокалга зур игътибар бирелә бездә. Ләкин шул ук вакытта бездә җырлый белмәүчеләр дә юк түгел.

:: Синең бит әле үз җырларың да бар. Рэп жанрындагы татарча җырлар – безнең җыр сәнгатендә сирәк күренеш. Ни өчен нәкъ менә шушы юнәлешне сайларга булдың?
– Мин кечкенәдән әлеге жанр белән кызыксынам. Ниндидер аңлатып булмаслык мәхәббәт... Беренче җырларымны мәктәптә укыганда ук язган идем. Хәзер дә җыр сүзләрен, ә кайчакта көен дә үзем иҗат итәм.

:: Җырлар кайчан языла?
– Төрлечә була. Илһам, диләр бит әле, кайчак кисәк кенә килә. Кайвакыт, дәресләргә, кирәк, дип эшләгән чакта авыррак була.

Ә СИН ТАНЫЙСЫҢМЫ?

Уенның чираттагысын тәкъдим итәбез. Җырлар башка булса да, шартлар үзгәрмәде: җырчы һәм җырның исемен язып җибәрергә кирәк. Тулы, дөрес һәм беренче җавап бирүчегә бездән бүләк – телефонына 100 сум! Җавапларны +7 (904) 718-14-69 номерына юллагыз.

Әлеге җырда «кар» сүзе бик еш кабатлана. Шундый карлы көндә дә җырчының күңеле сиңа ашкына икән.

Бу җыр исә безне аңлашып яшәргә өнди. Тыштагы җилләр өйгә кермәсен, ди җырчы.

НӘРСӘ УКЫЙМ? НӘРСӘ КАРЫЙМ?

Бу юлы китап, фильм һәм спектакльләр исемлеген «Ни хәл?» сәхифәсе кунагы Эльмир Нургалиевтан сорадык. Аның киңәшләре дә күңелегезгә хуш килер дип уйлыйбыз.

КИТАПЛАР
1. «Тревожные люди» – Фредрик Бакман.
2. «Над пропастью во ржи» – Джером Сэлинджер.
3. «Не складывается – вычитай» – Ринат Валиуллин.
4. «Зөләйха күзләрен ача» – Гүзәл Яхина.
5. «Счастливые люди читают книжки и пьют кофе» – Аньес Мартен-Люган.

ФИЛЬМ, СПЕКТАКЛЬЛӘР
1. «Җил артыннан» (Әлмәт театры спектакле).
2. «Джанго освобождённый» (реж. – Квентин Тарантино).
3. «Зеленая миля» (реж. – Фрэнк Дарабонт).
4. «Джентельмены удачи» (реж. – Александр Серый).
5. «Малена» (реж. – Джузеппе Торнаторе).

Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде

12 гыйнвар | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК» 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия» 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
14.45 «Аулак өй» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Шома бас» һәм «Калеб» 0+
16.00 «Казаннан – казанга» 12+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Казаннан – казанга» 12+
00.00 «Соотечественники». Наби Даули. Я смотрю тебе в глаза 12+
00.25 «Черное озеро». Отморозки 16+
00.50 «Җырлыйк әле!» 6+
01.30 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара» 6+
02.50 «ТАМАК». Телесериал 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
07.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
09.40 «Ачыктан-ачык» 12+
10.30 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
14.00, 02.00 «Ком сәгате» 12+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Яшьләр тукталышы» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
23.05, 05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
03.25 «Онытa алмыйм» 6+
04.15 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 02.30, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
18.40 Премьера. Концерт к 300-летию прокуратуры России. Прямая трансляция из Кремля (S)
21.00 «Время»
21.30 Премьера. «ИЩЕЙКА». Новый сезон (S) 12+
22.35 «Горячий лед». Фигурное катание. Чемпионат Европы 2022. Пары. Короткая программа. Прямой эфир из Таллина (S)
23.50 Мировая премьера. Экранизация романа Жюля Верна «ВОКРУГ СВЕТА ЗА 80 ДНЕЙ» (S) 16+
00.50 «Вечерний Ургант». Лучшее (S) 16+
01.45 «Наедине со всеми» 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Детективный телесериал. «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ» 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Максим Аверин. «СКЛИФОСОВСКИЙ». 16+
00.40 Мария Порошина, Елена Панова, Ирина Розанова, Светлана Иванова, Зоряна Марченко, Владимир Епифанцев, Константин Юшкевич, Игорь Бочкин, Владимир Юматов, Михаил Пшеничный. «ЧЕЛНОЧНИЦЫ. ПРОДОЛЖЕНИЕ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.50, 12.30, 15.05, 18.35, 22.35 Новости
06.05, 18.40, 21.50, 00.45 Все на Матч! Прямой эфир
08.55 «Дакар – 2022» 0+
09.25 «НОЛЬ-СЕДЬМОЙ» МЕНЯЕТ КУРС» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.35, 05.15 Специальный репортаж 12+
12.55 «ДЕСАНТ ЕСТЬ ДЕСАНТ» 16+
15.10 Смешанные единоборства. UFC. Забит Магомедшарипов против Келвина Каттара. Александр Волков против Грега Харди. Трансляция из Москвы 16+
16.10 Биатлон. Кубок мира. Спринт. Женщины. Прямая трансляция из Германии
18.15 «Есть тема!» 12+
19.25 Хоккей. КХЛ. «Авангард» (Омск) – «Салават Юлаев» (Уфа). Прямая трансляция
22.40 Футбол. Кубок Английской лиги. 1/2 финала. «Тоттенхэм» – «Челси». Прямая трансляция
01.30 Баскетбол. Евролига. Мужчины. «Панатинаикос» (Греция) – ЦСКА (Россия) 0+
03.20 Новости 0+
03.25 Волейбол. Лига чемпионов. Мужчины. «Берлин» (Германия) – «Зенит» (Россия) 0+
05.35 «Третий тайм» 12+

НТВ

05.15 Сериал «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
06.50 Детектив «НЕВСКИЙ. ПРОВЕРКА НА ПРОЧНОСТЬ» (S) 16+
08.00 Сегодня
08.25 «НЕВСКИЙ. ЧУЖОЙ СРЕДИ ЧУЖИХ» (S) 16+
10.00 Сегодня
10.25 «НЕВСКИЙ. ЧУЖОЙ СРЕДИ ЧУЖИХ» (S) 16+
13.00 Сегодня
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 Детектив «НЕВСКИЙ. ЧУЖОЙ СРЕДИ ЧУЖИХ» (S) 16+
16.00 Сегодня
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
19.00 Сегодня
20.00 Премьера. Детективный сериал «БИМ» (S) 16+
00.20 Остросюжетный сериал «ШУБЕРТ» (S) 16+
02.15 «ТАКСИСТКА» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.35 «Реальная мистика». «Хлопну в ладоши» 16+
07.35 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.40 «Давай разведёмся!» 16+
09.45 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.10 «Порча». «Кукольный домик» 16+
13.40 «Знахарка» 16+
14.15 «Верну любимого» 16+
14.50 «НЕСЛУЧАЙНЫЕ ВСТРЕЧИ» 16+
19.00 «Я ЗАПЛАЧУ ЗАВТРА» 16+
23.10 «ЧТО ДЕЛАЕТ ТВОЯ ЖЕНА?» 11-я 15-я серии 16+
03.50 «Реальная мистика» 16+
04.40 «Верну любимого» 16+
05.10 «Порча» 16+
05.35 «Знахарка» 16+
06.00 «Понять. Простить» 16+
06.25 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «РАЗВЕДЧИЦЫ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+.
09.20, 01.25 «КАРЬЕРА ДИМЫ ГОРИНА» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир» 12+
13.25 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+
13.40, 14.05 «РАЗВЕДЧИЦЫ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.30 «Специальный репортаж» 16+
19.00 «Битва коалиций. Вторая мировая война». Док. сериал 16+
19.45 «Главный день». «Рождество» 16+
20.30 «Секретные материалы». Док. сериал 16+
21.15 Новости дня. 16+
23.05 «Между тем» 12+
23.40 «ГОЛУБАЯ СТРЕЛА» 12+
03.05 «Хроника Победы». Док. сериал 16+
03.35 «РАЗВЕДЧИЦЫ» 16+

13 гыйнвар | Пәнҗешәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.00 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК» 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
14.45 «Аулак өй» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Бергәләп өйрәник» һәм «Сәйлан» 0+
16.00 «Таяну ноктасы» 16+
18.00 «Юлчы» 6+
19.30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Локомотив» – «Ак барс». Прямая трансляция 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
00.00 «Видеоспорт» 12+
00.25 «Соотечественники». Виктор Несмелов. Наука о человеке 12+
00.50 «Черное озеро». 16+
01.15 «Ватандашлар» 12+
01.35 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
02.50 «ТАМАК» 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълумати- күңел ачу программасы 6+
07.15, 23.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
08.00, 17.00, 22.25, 00.15 «Рәхәт яшибез!» Телесериал 12+
08.40 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
09.40 «Сакладым сине күңелемдә». Гәлшат Зәйнашева турында телеочерк 6+
11.00, 15.00, 18.00, 22.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 01.05 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
14.00, 02.00 «Ком сәгате» 12+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Халкым минем» 12+
19.30 Хоккей. КХЛ чемпионаты. «Локомотив» (Ярославль) – «Ак барс» (Казан) 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
03.25 «Онытa алмыйм» 6+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 02.25, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
17.00 «Горячий лед». Фигурное катание. Чемпионат Европы 2022. Женщины. Короткая программа. Прямой эфир из Таллина (S)
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 Премьера. «Ищейка». Новый сезон (S) 12+
22.35 «Горячий лед». Фигурное катание. Чемпионат Европы 2022. Пары. Произвольная программа. Трансляция из Таллина (S) 0+
23.40 «Познер». Гость Рената Литвинова 16+
00.45 «Вечерний Ургант». Лучшее (S) 16+
01.40 «Наедине со всеми» 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Детективный телесериал. «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ» 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Максим Аверин. «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
00.40 Мария Порошина, Елена Панова, Ирина Розанова, Светлана Иванова, Зоряна Марченко, Владимир Епифанцев. «ЧЕЛНОЧНИЦЫ. ПРОДОЛЖЕНИЕ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Смешанные единоборства. INVICTA FC. Алеша Заппителла против Джессики Коррея Делбони. Прямая трансляция из США
08.00, 08.50, 12.30, 15.05, 18.35, 22.35 Новости
08.05, 18.40, 21.35, 00.45 Все на Матч! Прямой эфир
08.55 «Дакар – 2022» 0+
09.25 «СЛЕД ТИГРА» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.35, 05.15 Спец. репортаж 12+
12.55 «ДЕСАНТ ЕСТЬ ДЕСАНТ» 16+
15.10 Смешанные единоборства. Fight Nights. Фёдор Емельяненко против Фабио Мальдонадо. Трансляция из Санкт-Петербурга 16+
16.10 Биатлон. Кубок мира. Спринт. Мужчины. Прямая трансляция из Германии
18.15 «Есть тема!» 12+
19.25, 05.35 Матч! Парад 16+
19.55 Гандбол. Чемпионат Европы. Мужчины. Россия – Литва. Прямая трансляция из Словакии
22.40 Футбол. Кубок Английской лиги. 1/2 финала. «Ливерпуль» – «Арсенал». Прямая трансляция
01.30 Баскетбол. Евролига. Мужчины. «Олимпиакос» (Греция) – «Зенит» (Россия) 0+
03.20 Новости 0+
03.25 Баскетбол. Евролига. Мужчины. «Милан» (Италия) – УНИКС (Россия) 0+

НТВ

05.15 «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
06.50 Детектив «НЕВСКИЙ. ЧУЖОЙ СРЕДИ ЧУЖИХ» (S) 16+
08.00 Сегодня
08.25 «НЕВСКИЙ. ЧУЖОЙ СРЕДИ ЧУЖИХ» (S) 16+
10.00 Сегодня
10.25 «НЕВСКИЙ. ЧУЖОЙ СРЕДИ ЧУЖИХ» (S) 16+
13.00 Сегодня
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «НЕВСКИЙ. ЧУЖОЙ СРЕДИ ЧУЖИХ» (S) 16+
16.00 Сегодня
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
19.00 Сегодня
20.00 Премьера. Детективный сериал «БИМ» (S) 16+
00.20 Остросюжетный сериал «ШУБЕРТ» (S) 16+
02.20 «ТАКСИСТКА» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «Реальная мистика». «Стеклянная порча» 16+
07.25 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.30 «Давай разведёмся!» 16+
09.35 «Тест на отцовство» 16+
11.50 «Понять. Простить» 16+
13.00 «Порча». «Далёкая» 16+
13.30 «Знахарка» 16+
14.05 «Верну любимого» 16+
14.40 «НИ СЛОВА О ЛЮБВИ» 16+
19.00 «КРОВЬ АНГЕЛА» 16+
23.15 «ЧТО ДЕЛАЕТ ТВОЯ ЖЕНА?» 16-я – 20-я серии 16+
03.55 «Реальная мистика» 16+
04.50 «Верну любимого» 16+
05.20 «Порча» 16+
05.45 «Знахарка» 16+
06.10 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «РАЗВЕДЧИЦЫ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.25 «БРАТЬЯ ПО КРОВИ» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир» 12+
13.35 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+
13.50, 14.05 «НАЗАД В СССР» 16+
14.00 Военные новости. 16+
18.30 «Специальный репортаж» 16+
19.00 «Битва коалиций. Вторая мировая война». Док. сериал 16+
19.45 «Легенды кино». Александр Лазарев 12+
20.30 «Код доступа» 12+
21.15 Новости дня 16+
23.05 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.40 «Звездная ночь» 6+
01.55 «Салют, страна!» 6+
02.30 «Фронтовые истории любимых актеров. Юрий Никулин и Владимир Этуш». Док. фильм 16+
03.10 «НАЗАД В СССР» 16+

14 гыйнвар | Җомга

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 20.45 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК» 12+
10.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
11.00 «Нәсыйхәт» 6+
11.30, 16.30, 21.00 «Татарлар» 12+
12.00 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 6+
14.15 «Рыцари вечности» 12+
14.45 «Аулак өй» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Тәймә» һәм «Сәйлан» 0+
16.00 «Мин» 12+
18.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
19.00, 20.00 «Точка опоры» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «МЕНӘ УЛ БӘХЕТ!» 6+
23.45 «Яңа елны ТНВ белән бергә каршылыйк!» Музыкаль программа 6+
04.20 «Соотечественники». В плену слухов. Абдулла Баттал 12+
04.45 «Черное озеро». Последняя главная роль 16+
05.10 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00 «Манзара». Мәгълуматикүңел ачу программасы 6+
07.15, 19.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
08.00, 17.00 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40 «Ком сәгате» 12+
09.40 «Нәсыйхәт» 6+
10.30 «Казаннан – казанга» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 03.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
14.00, 04.15 «Ком сәгате» 12+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Нәсыйхәт» 6+
20.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Нәҗип Җиһанов турында телеочерк 6+
21.25 «МЕНӘ УЛ БӘХЕТ!» 6+
22.50 «Яңа ел бәхет!» Концерт 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00, 03.30 «Мужское/Женское» 16+
17.00 «Горячий лед». Фигурное катание. Чемпионат Европы 2022. Танцы. Ритм-танец. Прямой эфир из Таллина (S)
18.40 «Человек и закон» с Алексеем Пимановым 16+
19.45 «Поле чудес» 16+
21.00 «Время»
21.30 Новогодняя ночь на Первом. 30 лет спустя (S) 16+
01.05 «Наедине со всеми» 16+
02.00 «Модный приговор» 6+
02.50 «Давай поженимся!» 16+
04.50 «Россия от края до края» 12+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Детективный телесериал. «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ» 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
20.45 Местное время. Вести-Татарстан
21.00 Премьера. «Аншлаг. Старый Новый год» 16+
00.00 Новогодний голубой огонёк-2022
03.30 Иван Ургант и Сергей Светлаков. «ЁЛКИ-5» 6+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.50, 12.30 Новости
06.05, 22.00, 00.30 Все на Матч! Прямой эфир
08.55 «Дакар - 2022» 0+
09.25 «БОЛЬШОЙ БОСС» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.35 Специальный репортаж 12+
12.55 «ДЕСАНТ ЕСТЬ ДЕСАНТ» 16+
15.05 На лыжи с Еленой Вяльбе
15.25 Лыжные гонки. Кубок мира. Спринт. Прямая трансляция из Франции
16.10 Биатлон. Кубок мира. Эстафета. Женщины. Прямая трансляция из Германии
18.15 Лыжные гонки. Кубок мира. Спринт. Трансляция из Франции 0+
19.55 Баскетбол. Евролига. Мужчины. ЦСКА (Россия) – АСВЕЛ (Франция). Прямая трансляция
22.25 Футбол. Чемпионат Германии. «Боруссия» (Дортмунд) – «Фрайбург». Прямая трансляция
01.15 Смешанные единоборства. UFC. Валентина Шевченко против Джессики Андраде. Трансляция из США 16+
02.20 Бобслей и скелетон. Кубок мира. Трансляция из Швейцарии 0+
03.20 Новости 0+
03.25 «Макларен». Документальный фильм 12+
05.00 Хоккей. НХЛ. «Колорадо Эвеланш» – «Аризона Койотис». Прямая трансляция

НТВ

05.15 «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
06.50 Детектив «НЕВСКИЙ. ЧУЖОЙ СРЕДИ ЧУЖИХ» (S) 16+
08.00 Сегодня
08.25 «НЕВСКИЙ. ЧУЖОЙ СРЕДИ ЧУЖИХ» (S) 16+
10.00 Сегодня
10.25 «НЕВСКИЙ. ЧУЖОЙ СРЕДИ ЧУЖИХ» (S) 16+
13.00 Сегодня
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «НЕВСКИЙ. ЧУЖОЙ СРЕДИ ЧУЖИХ» (S) 16+
16.00 Сегодня
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
19.00 Сегодня
20.00 Премьера. Детективный сериал «БИМ» (S) 16+
00.20 Остросюжетный сериал «ШУБЕРТ» (S) 16+
02.40 «ТАКСИСТКА» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.35 «Реальная мистика». «Телефонный приворот» 16+
07.35 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.40 «Давай разведёмся!» 16+
09.45 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.10 «Порча». «Сёстры» 16+
13.40 «Знахарка» 16+
14.15 «Верну любимого» 16+
14.50 «АВАНТЮРА» 16+
19.00 «ПИСЬМО НАДЕЖДЫ» 16+
23.20 «ЗДРАВСТВУЙ, ПАПА!» 16+
03.00 «Реальная мистика» 16+
03.50 «Верну любимого» 16+
04.20 «Порча» 16+
04.45 «Знахарка» 16+
05.10 «Понять. Простить» 16+
06.00 «Домашняя кухня» 16+
06.25 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

04.50 «НАЗАД В СССР» 16+
06.25 «ДОМ, В КОТОРОМ Я ЖИВУ» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.20, 13.25, 14.05 «КРЕСТНЫЙ» 16+
14.00 Военные новости. 16+
18.40, 21.25 «СТО ДНЕЙ СВОБОДЫ» 16+
21.15 Новости дня 16+
23.10 «Десять фотографий». Александр Панкратов-Черный 12+
00.00 «БРАТЬЯ ПО КРОВИ» 12+
01.40 «СЕМНАДЦАТЫЙ ТРАНСАТЛАНТИЧЕСКИЙ» 12+
03.10 «ПРАВДА ЛЕЙТЕНАНТА КЛИМОВА» 12+
04.35 «Ким Филби. Моя Прохоровка». Док. фильм 12+
05.25 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+

15 гыйнвар | Шимбә

ТАТАРСТАН

08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
07.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 6+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12 +
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 «Мин»12+
11.30 «Казаннан – казанга» 12+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
13.30 «КАЗАНГА КАЗАНДА» 12+
15.00 «Татар халык җырлары» 0+
15.30 «Юлчы» 6+
16.00 «Әйдә, шаяРТ!» 12+
17.00 «Әдәби хәзинә» 6+
17.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Кәмит Җәвит» 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу 12+
20.00 « Ватандашлар « 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБиТ шоу» 12+
23.00 «ЧТО ГЛОЖЕТ ГИЛБЕРТА ГРЕЙПА?» 16+
01.05 «Каравай» 6+
01.30 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР» 12+
04.20 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Нәҗип Җиһанов турында телеочерк 6+
07.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 6+
09.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00, 18.15, 03.00 «Башваткыч» 12+
12.05, 19.05, 03.50 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Әлфия Авзалова 6+
14.00 «Әйдә әле мәхәббәт иленә». Концерт 6+
17.10 «Казаннан – казанга» 12+
17.45 «Халкым минем» 12+
20.00 «КАЗАНГА КАЗАНДА» 12+
21.30 «60 яшь тә узып китте, 61 килеп җитте». Татарстанның халык артисты Виталий Агаповның юбилей кичәсе 12+
00.35 Т.Миңнуллин. «ӘНИЛӘР ҺӘМ БӘБИЛӘР». Уфа «Нур» Татар дәүләт театры спектакле 6+
04.40 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
05.05 «Халкым минем» 12+

1 КАНАЛ

06.00 Телеканал «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00, 12.00 Новости (с субтитрами)
10.15 К юбилею Константина Хабенского. Премьера. «ЛЮДИ, КОТОРЫХ Я ЛЮБЛЮ» 16+
11.20, 12.15 «Видели видео?» 6+
14.10 Ко дню рождения Раймонда Паулса. Юбилейный вечер (S) 12+
16.25 «Кто хочет стать миллионером?» 12+
18.00 «Сегодня вечером» 16+
21.00 «Время»
21.30 «Горячий лед». Фигурное катание. Чемпионат Европы 2022. Танцы. Произвольный танец. Женщины. Произвольная программа. Прямой эфир из Таллина (S)
23.45 К юбилею Константина Хабенского. «Ночной Дозор» (S) 16+
02.05 «Наедине со всеми» 16+
02.45 «Модный приговор» 6+
03.35 «Давай поженимся!» 16+
04.15 «Мужское/Женское» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Местное время. Вести-Татарстан
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
11.30 «Юмор! Юмор! Юмор!!!» 16+
12.35 «Доктор Мясников». Медицинская программа 12+
13.40 Елена Полянская, Дмитрий Белякин, Ирина Новак, Сергей Радченко. «БУМАЖНЫЙ САМОЛЁТИК» 12+
18.00 «Привет, Андрей!» Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
20.00 Вести в субботу
21.00 Екатерина Астахова, Виктория Литвиненко, Александр Кобзарь. «ВИРАЖИ СУДЬБЫ» 12+
01.00 Полина Сыркина, Константин Стрельников, Сергей Комаров, Анна Казючиц, Елена Дубровская, Павел Харланчук-Южаков. «В ПОЛДЕНЬ НА ПРИСТАНИ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 Хоккей. НХЛ. «Колорадо Эвеланш» – «Аризона Койотис». Прямая трансляция
07.30, 08.50 Новости
07.35, 19.35, 22.00, 00.05 Все на Матч! Прямой эфир
08.55 «Дакар – 2022» 0+
09.25 «СНЕЖНЫЕ ДОРОЖКИ». Мультфильм 0+
09.35 «ШАЙБУ! ШАЙБУ!» Мультфильм 0+
09.55 Лыжные гонки. Марафонская серия Ski Classics. 75 км. Прямая трансляция из Италии
13.50 Хоккей. Фонбет Матч Звёзд КХЛ 2022. Трансляция из Челябинска 0+
14.55 Лыжные гонки. Кубок мира. Мужчины. 15 км. Прямая трансляция из Франции
16.30 Биатлон. Кубок мира. Эстафета. Мужчины. Прямая трансляция из Германии
18.15 Лыжные гонки. Кубок мира. Женщины. 10 км. Трансляция из Франции 0+
19.55 Футбол. Чемпионат Италии. «Салернитана» – «Лацио». Прямая трансляция.
22.25 Гандбол. Чемпионат Европы. Мужчины. Россия – Норвегия. Прямая трансляция из Словакии
00.50 Санный спорт. Кубок мира. Трансляция из Германии 0+
01.55 Бобслей и скелетон. Кубок мира. Трансляция из Швейцарии 0+
02.55 Новости 0+
03.00 Смешанные единоборства. UFC. Гига Чикадзе против Келвина Каттара. Прямая трансляция из США

НТВ

04.45 «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
08.00 Сегодня
08.20 «Поедем, поедим!» (S) 0+
09.20 Едим дома (S) 0+
10.00 Сегодня
10.20 Главная дорога (S) 16+
11.00 «Живая еда с Сергеем Малозёмовым» (S) 12+
12.00 Квартирный вопрос (S) 0+
13.00 «Однажды...» (S) 16+
14.00 Следствие вели... (S) 16+
16.00 Сегодня
16.20 Следствие вели... (S) 16+
19.00 Сегодня
19.25 «Новогодний Суперстар!» (S) 16+
22.00 «Квартирник НТВ у Маргулиса. Новогодний андеграунд» (S) 16+
01.35 «Новогодняя сказка для взрослых» (S) 16+
02.25 «ТАКСИСТКА» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.45 «Пять ужинов» 16+
07.00 «СРОК ДАВНОСТИ» 16+
10.50 «ПЛЕННИЦА». 1-я – 8-я серии 16+
19.00 «ВЕЛИКОЛЕПНЫЙ ВЕК». 5-я и 6-я серии 16+
23.00 «КРОВЬ АНГЕЛА» 16+
02.50 «ПЛЕННИЦА». 1-я – 4-я серии 16+
05.55 «Домашняя кухня» 16+
06.20 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.35 «ТАЕЖНЫЙ МОРЯК» 12+
06.55, 08.15 «ПОСЛЕ ДОЖДИЧКА, В ЧЕТВЕРГ...» 6+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
08.40 «Морской бой» 6+
09.45 «Круиз-контроль» 12+
10.15 «Легенды цирка с Эдгардом Запашным» 12+
10.45 «Улика из прошлого». «Дело о «черной смерти». Загадки эпидемий» 16+
11.35 «Война миров». Док. сериал. «Советские офицеры против японских самураев» 16+
12.30 «Не факт!» 12+
13.15 «СССР. Знак качества» с Иваном Охлобыстиным» 12+
14.00, 18.25 «ДУМА О КОВПАКЕ» 12+
18.15 «Задело!» с Николаем Петровым 16+
21.40 «ОТ БУГА ДО ВИСЛЫ» 12+
00.40 «ВТОРЖЕНИЕ» 12+
02.10 «В НЕБЕ «НОЧНЫЕ ВЕДЬМЫ» 12+
03.30 «ПИРОЖКИ С КАРТОШКОЙ» 12+
05.15 «Москва фронту». Док. сериал 16+

16 гыйнвар | Якшәмбе

ТАТАРСТАН

08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «60 яшь тә узып китте, 61 килеп җитте». Татарстанның халык артисты Виталий Агапов 6+
08.30 «ХАЙКЮ». Мультфильм 12+
09.00 «Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
09.15 «Тамчы-шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 12+
10.15 «Ачыктан-ачык» 12+
11.00 Саҗида Сөләйманова исемендәге XVI әдәби премиясен тапшыру тантанасы 6+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 12+
13.00 «Зур туган көн концерты». Гөлназ Сафарова 6+
15.35 «Татар халык җырлары» 0+
16.00 «Ком сәгате» 12+
17.00 «Видеоспорт» 12+
17.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Башваткыч» 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
20.00 «Чёрное озеро» 16+
20.30 «Болгар радиосы» концерты 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12 +
23.00 «ЛАБИРИНТЫ ПРОШЛОГО» 16+
00.15 «Ком сәгате» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
02.50 «ТАМАК» 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 00.40 «Татарлар» 12+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
07.00 «Гомерләрне үлмәс җыр итеп». Хания Фәрхи концерты 6+
09.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Аяз Гыйләҗев турында телеочерк 6+
10.00 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
10.30 «Калеб» 6+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы» 12+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.35 «Нәсыйхәт» 6+
14.05 А.Гыйләҗев. «ШИКӘРЕМ СИН, БАЛЫМ СИН». К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакле 12+
15.50 Татарстанның халык артисты Зөфәр Харисовның юбилей кичәсе 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате» 12+
20.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
21.10 Хәмдүнә Тимергалиеваның якты истәлегенә багышланган концерт 6+
23.20 «Халкым минем» 12+
01.05 «Манзара» 6+
02.05 «Мин – Буран кызы!» Хәмдүнә Тимергалиеваның юбилей концерты 12+

1 КАНАЛ

04.55, 06.10 Ирина Пегова, Анна Снаткина. «ГАЛКА И ГАМАЮН» (S) 16+
06.00 Новости
06.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.40 «Часовой» (S) 12+
08.10 «Здоровье» 16+
09.20 «Непутевые заметки» 12+
10.00, 12.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других» (S) 12+
11.15, 12.15 «Видели видео?» 6+
14.00 «Детский КВН» (S) 6+
15.15 «Геннадий Хазанов. Без антракта» (S) 16+
17.35 «Две звезды. Отцы и дети» (S) 12+
19.25 Шоу Максима Галкина «Лучше всех!» Новый сезон (S) 0+
21.00 «Время»
22.00 «ДНЕВНОЙ ДОЗОР» (S) 16+
00.40 «Константин Хабенский. «ЛЮДИ, КОТОРЫХ Я ЛЮБЛЮ» 16+
01.40 «Наедине со всеми» 16+
02.25 «Модный приговор» 6+
03.15 «Давай поженимся!» 16+
03.55 «Мужское/Женское» 16+

РОССИЯ 1

05.20 Татьяна Догилева, Пётр Красилов. «КОРОЛЕВА ЛЬДА» 16+
07.15 «Устами младенца»
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым»
09.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
11.30 «Парад юмора» 16+
13.10 Премьера. Марина Коняшкина, Илья Акинтьев, Максим Щёголев, Елена Антипова. «ЗАГС» 12+
17.20 Премьера. «Танцы со Звёздами». Новый сезон 12+
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.30 Надежда Маркина, Андрей Смирнов, Елена Лядова. «ЕЛЕНА» 18+
03.20 «КОРОЛЕВА ЛЬДА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 Смешанные единоборства. One FC. Ксион Жи Нань против Аяки Миюры. Трансляция из Сингапура 16+
07.00, 08.50 Новости
07.05, 19.35, 22.00 Все на Матч! Прямой эфир
08.55 «КОСМИЧЕСКИЙ ДЖЕМ» 6+
10.45 Хоккей. Фонбет Матч Звёзд КХЛ 2022. Прямая трансляция из Челябинска
13.45 Лыжные гонки. Кубок мира. Гонка преследования. Женщины. Прямая трансляция из Франции
14.40 Биатлон. Кубок мира. Гонка преследования. Женщины. Прямая трансляция из Германии
15.30 Биатлон с Дмитрием Губерниевым
16.35 Биатлон. Кубок мира. Гонка преследования. Мужчины. Прямая трансляция из Германии
17.25 Лыжные гонки. Кубок мира. Гонка преследования. Мужчины. Прямая трансляция из Франции
18.35 Смешанные единоборства. UFC. Гига Чикадзе против Келвина Каттара. Трансляция из США 16+
19.55 Футбол. Чемпионат Италии. «Рома» – «Кальяри». Прямая трансляция
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Аталанта» – «Интер». Прямая трансляция
00.45 Гандбол. Лига чемпионов. Женщины. ЦСКА (Россия) – «Вайперс» (Норвегия) 0+

НТВ

04.45 «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
08.00 Сегодня
08.20 «У нас выигрывают!» (S) 12+
10.00 Сегодня
10.20 «Первая передача» (S) 16+
11.00 «Чудо техники» (S) 12+
11.50 «Дачный ответ» (S) 0+
13.00 «НашПотребНадзор» (S) 16+
14.00 Следствие вели... (S) 16+
16.00 Сегодня
16.20 Следствие вели... (S) 16+
19.00 Сегодня
19.25 «Основано на реальных событиях» (S) 16+
23.00 Ты не поверишь! (S) 16+
00.00 Владимир Меньшов. «ДЕД МАЗАЕВ И ЗАЙЦЕВЫ» (S) 16+
03.45 «ТАКСИСТКА» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.50 «Пять ужинов» 16+
07.05 «ТЫ ТОЛЬКО МОЙ» 16+
11.00 «РЕФЕРЕНТ» 16+
15.00 «Я ЗАПЛАЧУ ЗАВТРА» 16+
19.00 «ВЕЛИКОЛЕПНЫЙ ВЕК» 16+
23.35 «ПИСЬМО НАДЕЖДЫ» 16+
03.15 «ПЛЕННИЦА». 5-я – 8-я серии 16+
06.20 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.35 «ГОЛУБАЯ СТРЕЛА» 12+
07.25 «БЕРЕМ ВСЕ НА СЕБЯ» 12+
09.00 «Новости недели» с Юрием Подкопаевым 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.45 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах №83» 16+
11.30 «Секретные материалы». Док. сериал» 16+
12.20 «Код доступа». «50 оттенков «зеленого». За ширмой экологии» 12+
13.10 «Специальный репортаж» 16+
13.30 «СТО ДНЕЙ СВОБОДЫ» 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой 16+
19.25 «Легенды советского сыска». Док. сериал 16+
22.45 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+
23.00 «Фетисов». Ток-шоу 12+
23.45 «Освобождение. Висло-Одерская операция. Прорыв». Док. фильм 16+
00.20 «КРЕСТНЫЙ» 16+

РАДИО РОССИИ

«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?

Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

Дүшәмбе, 10 гыйнвар

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10 «Әдәбиятыбыз сәхифәләре». Гарифҗан Мөхәммәтшин шигырьләре
11.45 Рабит Батулла. «Соңгы чабыш». Хикәя
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 Әнгам Атнабаев. «Яралы гармун». Моноспектакль
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердәшханә»
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

Сишәмбе, 11 гыйнвар

6.00-8.00 «Новый день». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуальное интервью»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Пар канатлар»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Хәдичә Гыйниятова язмалары

Чәршәмбе, 12 гыйнвар

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
7.45 «Юллар чатында»
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Актуальное интервью»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Яшьлек аланы»
18.25 Композитор Рәзим Вәлиуллин әсәрләре

Пәнҗешәмбе, 13 гыйнвар

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Перекресток»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Офыклар»
18.25 Эстрада концерты

Җомга, 14 гыйнвар

6.00-8.00 «Иртәнге нур». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр».
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Вести ПФО
11.30 «Доброе братство лучше богатства» (на марийском языке)
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Татарстан сәнгать осталары концерты

Шимбә, 15 гыйнвар

8.10, 11.10 Язучы һәм журналист Фәез Зөлкарнәйне искә алу кичәсеннән репортаж
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00 -15.10, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Гөлбакча»
10.30 «7 көн». Атналык күзәтү
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 Дания Гайнетдинова. «Тальян моңы». Моноспектакль

Якшәмбе, 16 гыйнвар

8.10-9.00 «Между Волгой и Уралом». Объединенный радиожурнал семи республик
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-16.10, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Кәмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий недели
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Ял концерты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10, 16.10 Мирсәй Әмир. «Тормыш җыры». Актаныш районы Богады авылы үзешчән театры спектакле язмасы

ЕРЫК АВЫЗ

Хатын иртән кайткан иренә ташлана:
– Син кайда йөрдең? Мин төне буе көттем, күз дә йоммадым!
Ир арыган кыяфәт белән:
– Син мине йоклап ятты дип уйлыйсың мәллә?

* * *

Депутатлар фикер алыша. Чернобыльдән калган басуларны ничектер файдалану турында карар кабул итәргә кирәк.
– Бөртекле культура үстереп булмый, тамырзыклы бигрәк тә...
– Әйдәгез, без анда тәмәке чәчәбез һәм тәмәке кабына: «Минздрав соңгы тапкыр кисәтә...» – дип язабыз.

* * *

– Вәли, син бүген бик көяз күренәсең, әллә берәр бәйрәмме?
– Әйе, алтын туемны билгеләп үтәм.
– Ничек алтын? Синең өйләнгәнеңә биш кенә ел бит!
– Ул елларның һәркайсы 10 елга тора!

САНДЫГЫМДА КҮПМЕ ДИПЛОМ?

Белем генә җитмәячәк: спортта да, иҗатта да үзеңне күрсәтә белергә кирәк. Рособрнадзор БДИ урынына укучыларның дәрестән тыш уңышларын да исәпкә алырга тәкъдим итә. Үзгәрешләр 2030 елга кадәр кертелергә мөмкин. Шул ук вакытта бердәм дәүләт имтиханнарын вузларга укырга керүче абитуриентларга гына калдыру турында да сөйләшүләр бар. БДИга тиңдәш табылырмы?

Кызыксыну җитми

Рособрнадзор башлыгы Анзор Музаев белдергәнчә, казанышлар системасы кертелсә, укучылар 6 нчы сыйныфтан башлап, иҗат, спорт, волонтерлык һәм башка юнәлешләр буенча уңышларын туплап барачак. Болар вузга кергәндә исәпкә алыначак. Әлегә бу хакта 9–11 нче сыйныф укучылары гына уйлана. Башка сыйныфларда кызыксыну җитми.

Цифрлы портфолионың имтиханнарны алыштыра алуына укытучыларның күбесе шикләнеп карый. Әмма MAXIMUM Education компаниясе уздырган сораштыру нәтиҗәләре педагогларның 65 процентының әлеге фикерне хуплавын күрсәтә. 35 проценты исә моңа каршы. Ни өчен?

– Мондый яңалык гамәлгә керсә, укучы 1 нче сыйныфтан ук кайсы вузга укырга керергә дип баш вата башлаячак. Шулай итеп, уку түгел, казанышлар турында уйлый торган буын барлыкка киләчәк. БДИны яки теләсә кайсы сынауны укучыларның уңышларына алыштыру дөрес түгел, – дип белдергән бу фикерне хупламаучы укытучылар.

Тәртибе кирәк

Сарман районының Мәгариф идарәсе башлыгы Гөлшат Идрисова әйтүенчә, портфолиога керган Мактау кәгазе, Рәхмәт хаты, казанышларның бәяләнүе төрлечә.

– Район эчендә дә әле аны белеп бетерү бик авыр. Министрлык билгеләгән конкурслар, онлайн бәйгеләр һәм башкалар бар. Сертификатларның кайсының мөһимрәк икәнлеген билгеләү җиңел түгел. Без мәктәпләр арасында рейтинг уздырабыз. Портфолио кертелсә, гадел бәяләп булырмы икән, дип шикләнәм. Кайсыдыр бәйгегә өстенлек бирелә икән, укучылар шунысында катнашырга тырышачак. Монысы балаларны ниндидер кысаларга куып кертү була. Шуңа күрә республика, министрлык тарафыннан кайсы конкурска нинди бәя булачагы билгеләнергә тиеш дип уйлыйм. Дәрестән тыш эшләрне бәяләүнең бер тәртибе кирәк, – ди Гөлшат Идрисова. – БДИга ияләштек. Укучылар, имтихан тапшырасы бар дип тырыша, белем дәрәҗәләре дә арта бара. Ләкин стресс, бер яктан да гадел булмау – сынауның хәл ителмәгән ягы. Дәрес программасын күбрәк БДИга кайтарып калдырырга мәҗбүрбез. Мәктәп күрсәткече дигәндә, ешрак шуның нәтиҗәсенә карыйбыз. Тик БДИ белән уку программасы – икесе ике әйбер. Тестка әзерләү фикерләү сәләтен үстерүгә дә комачаулый. Әгәр укучы сынауларны яхшы биреп тә, иң мөһим вакыйгаларны, мәсәлән, Октябрь инкыйлабының кайчан булганын яки Ленинның кем икәнен белми икән, бер дә күңелле түгел. Андыйлар күп димим, әмма очрый. Укытучыларның укытырга вакыты аз калу да борчый. Кәгазь эше бик күп. Электрон почтаны ачып карасаң, анда нинди генә бәйгеләр, анкеталар юк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Фикер

Гөлнара ИСЛАМОВА, Республика олимпиада үзәге директоры:

„ БДИ тапшырганда укучылар мәктәп программасын үзләштерә, ә олимпиадаларга өстәмә әзерләнергә, түгәрәкләргә йөрергә кирәк. Бөтенроссия этабында призер яки җиңүчеләр профиль буенча теләсә кайсы ил вузына керә ала. Әгәр дә профиль буенча булмаса, башка уку йортына кергәндә нәтиҗә шул фәннән 100 баллга тиң. БДИ авыр дип куркыталар, әмма чынбарлыкта алай түгел. Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгында БДИ комиссиясендә эшләп караган белгеч буларак әйтәм мин моны. Әгәр бала мәктәп программасын өйрәнә икән, бер куркыныч әйбер дә юк. Имтиханны да яхшы бирәчәк. Хәзер БДИ тест кына түгел, анда уйлап җавап язарга кирәк. Портфолионы вуз үзе хәл итә. Әгәр укучы төбәк этабында призер яки җиңүче икән, аңа бер балл өстәлә. Кайбер вакытта ярты яки бер балл да күп нәрсәне хәл итә бит. Республика буенча олимпиада нәтиҗәләре арта бара. 2020 елда пандемия сәбәпле, бөтенроссия олимпиадасының тәмамлау этабы уздырылмады. Олимпиадага узган 11 нче сыйныф укучылары автомат рәвештә призер булды. Бөтенроссия олимпиада этабында 2019 елда 148 призер һәм җиңүче булса, 2021 елда – 211. Татарстан тугыз ел рәттән олимпиада күрсәткечләре буенча өченче урында бара. Сыйфат буенча бары Мәскәүдән генә калышабыз. Мәктәп этабында бөтен бала катнаша ала. Быел андыйлар 190 меңгә якын.

Ахирилләр булмаса...

Казандагы 12 нче кызлар гимназиясенең укыту эшләре буенча директор урынбасары, олимпиадаларга әзерләү өчен җаваплы белгеч Мәйсәрә Вәлиеваның да фикерләрен белештек.

– Портфолио белән теләсә кем укырга керә алмаска мөмкин. БДИның уңай ягы: сынау нәтиҗәләре буенча, матди ягы авыррак гаиләдәге балалар да илнең теләсә кайсы вузында укый ала. Тискәре ягы – «бәхет эше». Әйтик, белеп бетермәгән бала сынауны яхшы балларга бирергә, ә яхшы укыганы югалып калырга мөмкин. Мәсәлән, гимназиядәге шулкадәр яхшы укый торган укучыбызның бик нык каушый торган гадәте бар. Андыйлар белгәнен дә яза алмаска мөмкин. Бу – курку халәте. БДИ тапшыру пунктында үз мәктәбең укытучылары юк. Психологик яктан да икенче төрле. Конференция, бәйгеләргә баргач, жюрида гадел булмаган белгечләр утырырга мөмкин. Бәйге нәтиҗәләре буенча – һәр мәктәпнең үз рейтингы. Конкурс күрсәткечләре буенча баллар куела. Аны уздырган һәр районның үз кешеләренә бирәсе килә. Саесскан кебек, койрыгына бассаң – түше, түшенә бассаң, койрыгы ябыша, – ди Мәйсәрә Вәлиева.

Урынбасар әйтүенчә, кызлар гимназиясе булгач, барысы да югарыга, карьерага омтыла. Омтылышның беткәне дә юк. Узган ел олимпиадада җиңгән бер укучылары Санкт-Петербург вузына укырга кергән. БДИ биргән очракта да вузларда укучыларның портфолиосы карала. Район, республика күләмендәге бәйгеләрдә җиңүче укучылар елдан-ел арта бара. Күптән түгел Ел укучысын билгеләгәннәр. Ел саен «Туфан бәләзеге» премиясен тапшыру гадәткә кергән. Көмеш бәләзек күп кызларның күзен яндыра икән. Май аенда «Йолдызлар кабына» дигән чара уздыралар. Анда ел дәвамында уңышка ирешкән балаларны бүләклиләр.

Бер кочак Мактау кәгазе...

Валерий Хасанченко Казандагы 112 нче мәктәпнең 11 нче сыйныфында белем ала. Аның уңышлары берничә дистәдән артык. Ул – «Россия укучылар хәрәкәте» лидеры. Берничә тапкыр Татарстан Яшьләр эшләре министрлыгының, «Сәләт» лагеренең Рәхмәт хатлары белән бүләкләнгән. «Зур тәнәфес» бәйгесен оештыруда, лагерьларда мастер-класслар үткәрүдә катнашкан.

– Минем сертификатлар күп, ә дусларныкы юк. Андыйлар авыр хәлдә калмасмы? Берәүләр ел буе тырышып укып та, аларның спортта, иҗатта уңышлары булмаска мөмкин бит. Портфолионы әкренләп кертергә кирәк дип уйлыйм, – ди ул.

Валерия Казан яки Мәскәүдәге югары уку йортларын сайларга җыена. Аны реклама, бизнес юнәлешләре кызыксындыра.

– БДИ укучыларның физик һәм психологик халәтенә бик нык йогынты ясый. Өстәвенә укытучылар да, бирә алмыйсың, дип кабатлап тора. Имтихан алдыннан, әлбәттә, курку артачак. Кемдер яхшы укыса да, начар билге алырга мөмкин. Аның урынына контроль эш яки җиңелрәк сынау кирәк, – ди Валерия.

Сәрия МИФТАХОВА

2022 ел яңалыклары

✓ 1 гыйнвардан мәгариф системасында эшләүчеләрнең, шул исәптән кече тәрбиячеләр, пешекчеләр, техник хезмәткәрләрнең хезмәт хаклары артачак. Уртача алганда, оклад 2,5 меңнән 5,5 мең сумга кадәр күтәрелә дигән сүз.

✓ Мәктәпләрдә укучылар финанс белемен өйрәнә башлый. Ул булган дәресләр хисабына укытылачак.

✓ Укучыларның кышкы каникулы 16 гыйнварга кадәр озайтылырга мөмкин. Дәүләт Думасының Мәгариф комитеты рәисенең беренче урынбасары Яна Лантратова, коронавируска бәйле вазгыять сәбәпле, мәгърифәт министры Сергей Кравцовка шундый тәкъдим белән чыккан.

✓ Төбәкләргә мәктәпләрне яңарту өчен ил казнасыннан 90 миллиард сум акча бүлеп биреләчәк. Әлеге сумма ике меңнән артык мәктәп, ашханәләрне төзекләндерүгә тотылачак. «Безнең укучылар заманча мәктәпләрдә укырга тиеш. Бүлеп бирелгән акча уңайлыклар, имин шартлар тудырырга ярдәм итәчәк», – дип белдерде Премьер-министр Михаил Мишустин.

✓ Илдәге барлык 33 педагогик вузда да факультетара технопарклар булдырылачак. Әлеге технологик шартлар педагогика ысулларын яңартуны, фәнне үстерүне күздә тота.

✓ Татарстанда беренче, икенче, өченче категориягә кертелгән мәктәпләрдә иминлекне саклауга 1,2 миллиард сум акча бүлеп биреләчәк.

✓ Киләсе елда республикада «Үсеш ноктасы» федераль проекты буенча 117 авыл мәктәбендә химия, биология, физика кабинетлары җиһазландырылачак. 52 мәгариф оешмасында, ягъни 46 мәктәптә һәм 6 урта һөнәри уку йортында компьютерлар яңартылачак.

✓ Җиде тулай торакны төзекләндерү өчен 190 миллион сум акча бүленәчәк. Алар арасында Тәтеш авыл хуҗалыгы, Әлмәт сәүдә-икътисад, Чаллы педагогика көллиятләре, Казан технология һәм дизайн, Сарман, Кукмара, Алексеевск аграр көллиятләре тулай тораклары бар.

✓ 2022 елдан татар теле һәм әдәбияты, дәүләт теле буларак, укыту планының мәҗбүри өлешенә кертеләчәк. Татарстанның мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин белдергәнчә, туган тел ул – фән, аны һәркем укырга тиеш. Кайсы телне укытуны әти-әниләр үзләре сайлый. Федераль стандартлар буенча, катнаш гаиләдә тәрбияләнүче бала татар телен белмәсә дә, аны дәүләт теле буларак сайлый ала. Әгәр рус баласы татар телен сайлый икән, аның өчен ул – туган тел түгел, ә дәүләт теле.

– Һәр кеше туган телен сайлый ала, без шартлар тудырабыз. Туган тел буларак татар теле, дәүләт теле буларак татар теле, татар әдәбияты – өч программа федераль исемлеккә кертелде. Кайвакыт, без туган телне укырга теләмибез, дигән сүзне ишетергә туры килә. Әмоны беркем сорамый, гомуми белем турында аттестат аласың килә икән, теге яки бу телне сайларга тиешсең. Ул уку планында бар, – ди Илсур Һадиуллин.

БИШБАЛТАДА БАЛТА ОСТАЛАРЫ ЯШӘГӘН

Башкалабызның Үзәк паркындагы «канатлы» юлларны хәтерләүчеләр бардыр әле. Революциягә кадәр үк төзелеп, халыкны агарту эшләренә зур өлеш керткән «Йолдыз» кинотеатрын да онытып бетермәгәннәрдер. Бишбалтадагы Идел ярында күңел ачу урыннары да әдәби әсәрләрдә урын алган. Димәк, анда заманында тормыш гөрләп торган.

Беренче карашка төрле булып тоелган бу вакыйгаларны искә алуыбыз юкка түгел. Аларның барысы да нәкъ менә шул татарлар күпләп яшәгән Бишбалтадагы «Урак һәм чүкеч» заводы тарихына барып тоташа. Үзгәреш җилләре туздырып ташламаса, без могҗизага тиң бу заводның 170 еллыгын билгеләп үткән булыр идек. Ни кызганыч, ахыр чиктә аның урынында төзелгән «Адмирал» сәүдә йортында янгын чыгып, бу урын кара күмергә әйләнде. **Гарәфетдин ХИСАМЕТДИНОВ** гомеренең күп өлешен шушы заводка багышлаган, музей төзү эшендә башлап йөргән. Кыскасы, уйлары белән заводтан бер генә көн дә аерылмаган. Хәзер ул шушы тарихи байлыкның кыйпылчыгын гына булса да саклап калу өчен тырыша.

:: Гарәфетдин абый, Бишбалтаның без кайчандыр татар авылы булганын беләбез. Монда тарихка кереп калырлык зур эшләр ничек һәм кайчан башлана?

– 1718 елда Петр I Бишбалта авылына килә. Андагы балта осталарын күрә. Иранны басып алу хыялын тормышка ашыру йөзеннән, Россия флотын яңартырга уйлый. Шулай итеп, корабльләр төзелешен башлап җибәрү өчен, Бишбалта авылы янында Адмиралтейство оештыру турындагы Указга кул куя. Шуннан соң бирегә урман кисүчеләр, агач материаллары әзерләү артельләре барлыкка килә. Аннары акрынлап күн эшкәртү артельләре, җилкәннәр, брезентлар әзерләү өчен җитен комбинаты, суднoларны корал белән тәэмин итү өчен дары заводы эшләп китә. Суднолар ремонтлау һәм металл әйберләр – якорь, чылбыр ише кирәк-яракны җитештерү эшләрен Россиянең 2 нче гильдия сәүдәгәре Александр Свешников үз кулына ала. Бу – 1851 ел була. Ул Казан губернасында бердәнбер машина төзелеше заводы була. Башта заводта биш тимерче сандалы, чуен, бронза, латунь әйберләр кою миче һәм өч тимерче учагы була. Свешников заводны үстерүгә акчасын кызганмый. 1877 елны, аның вафатыннан соң, завод, мирас булып, улына күчә. 1911 елда ул, бурычка бату сәбәпле, заводны баш инженер Ярцевка тапшыра. Соңгысы исә бигрәк тә шул төбәктә яшәүче халык өчен беренче мәртәбә «Синема» ачуы белән тарихка кереп кала. Соңыннан ул «Йолдыз» кинотеатры итеп үзгәртелә.

:: Илдә барган вакыйгалар, Беренче Бөтендөнья сугышы, революция, Бөек Ватан сугышы елларының һәрберсе бистә тормышына үзенчә үзгәрешләр керткәндер дип уйларга кирәк...

– Чыннан да, завод 1914 елда башланган сугыш өчен заказлар үти башлый. Октябрь инкыйлабы вакытында бөтенләйгә туктап кала, чөнки Ярцев ак чехлар белән качып китә. 1922 елда Совнарком карары белән завод авыл хуҗалыгы инвентарьлары һәм авыл кирәк-яраклары җитештерүгә йөз тота. Нәтиҗәсе буларак, шушы елларда «Урак һәм Чүкеч» дип атала башлый.

«Бишбалта остазлары» дип аталган бу һәйкәлне завод янәшәсендәге Столяров паркында Гарәфетдин Хисаметдинов 2020 елда үз акчасына салдыра.

Бөек Ватан сугышы елларында күп кенә эшчеләр фронтка китә. Калганнары, өчәр смена эшләп, фронт өчен кирәк-яраклар – снарядлар, каскалар, сапер көрәкләре һәм башка шундый әйберләр эшләүгә алына.

> Бу елларда тарих битләренә кереп калырлык вакыйга була: 1942 елның 5 октябрендә Сталин фәрманы белән Ленинградтан 20 кг уран һәм 200 кг аппаратура китерелә. Бу – илнең бөтен уран запасы дигән сүз. Заводта Курчатов җитәкчелегендә, атом бомбасы ясау өчен, Ланге центрифугаларында уранны баету эшләре башланып китә.

:: Белгәнебезчә, завод сугыштан соң да уңышлы эшли.

– Сугыштан соң монда тыныч тормышка кирәкле продукцияләр, халык куллану товарлары җитештерелә башлый. Алтмышынчы елларда завод яңа төзелеп килә торган автогигантлар – КамАЗ белән Тольяттины җыелма конвейерлар белән тәэмин итеп тору, шулай ук, туристлык индустриясенә «канатлы» юллар әзерләү эшенә керешә. Мондый продукция җитештерү буенча Советлар Союзында ул бердәнбер була.

«Урак һәм Чүкеч» үз эшчеләрен социаль инфраструктура белән тәэмин итү өлкәсендә башкаларга үрнәк була. Бу эшне беренчеләрдән булып башлый. Кызганыч, мондый система озак еллар көчен саклап килсә дә, үзгәртеп кору елларында тулысынча җимерелә.

Җитмешенче елларда, КамАЗ төзелеше уңаеннан, Татарстанга СССР премьер-министры Николай Косыгин килә. Директор Мирсәет Рәхимкулов кунакны һәм Татарстанның КПСС Өлкә комитеты секретаре Фикрәт Табеевны заводка чакыра. Заводны үзгәртеп кору турында сөйләшәләр. Иң мөһиме, халык турында онытмыйлар. Шул чорларда биш катлы ике йорт, тулай торак, балалар бакчасы, Аккош күле буенда «Ялкын» пионер лагере салына. Казан шәһәренең Үзәк паркында «канатлы» юллар сузыла. Завод эшчәннәре өчен беренче 14 катлы йорт күтәрелә. Рәхимкулов Адмиралтейства – Идел буенда «кече Пицунда» салырга хыяллана. Ләкин өлгерә алмый, каты авырудан соң бакыйлыкка күчә.

:: Игелекле эшләрнең дәвамы булгандыр дип уйлыйк?

– Әйтергә кирәк, җитәкченең уй-фикерләренә, теләгенә күп нәрсә бәйле. Башта заводны төзекләндерү, финанслау эшләре тукталып калган иде. Башланган эшне төгәлләү өчен генә булса да, КПСС Үзәк Комитеты секретаре Андрей Кириленкога мөрәҗәгать итәргә туры килде. Нәтиҗәдә «Йолдыз» кинотеатры торгызылды. 14 катлы тагын ике йорт салынып бетте. Микрорайонга хезмәт күрсәтү өчен кирәкле коммуникацияләр сафка басты. Тимер юл белән Идел елгасы арасында футбол кыры, волейбол һәм баскетбол мәйданчыклары, спорт-сәламәтләндерү зонасы барлыкка килде. Елга буйлап эскәмияләр сузылды. Шунда ук йөгерү юллары, атынгычлар, турниклар булдырылды. Ни кызганыч, бүген инде аларның берсе дә юк. Завод шулай ук Кырымдагы «Ай-Петри» тавына «канатлы» юллар салырга да булышты. Вьетнам, Югославия, Болгария, Куба кебек илләргә продукция җибәрә башлады. Завод шулкадәр үргә күтәрелде ки, хәттә 1984 елда илнең Машина төзелеше министрлыгы «Урак һәм Чүкеч» заводы базасында «Хуҗалык механизмын камилләштерү» темасына Бөтенсоюз семинары үткәрде...

:: Ә аннары илдә үзгәреш җилләре башланды...

– Бер-бер артлы предприятиеләр ябылды. Ни гаҗәп, гөрләп торган, аягында нык басып торган «Урак һәм Чүкеч» заводы да шундый язмышка дучар булды. Вьетнам базарында янгын булганнан соң, завод урынында тиз арада «Адмирал» сәүдә үзәге ачып җибәрделәр. Югыйсә бирегә сәүдә өчен бернинди шартлар юклыгы аңлашыла иде бит инде. 2015 елның мартында аны да ялкын ялмап алды. Корбаннар да күп булды.

:: Эшчеләре өчен күп йортлар төзегәч, бу фатирларда заводта эшләп киткән ветераннар, аларның балалары, оныклары яшидер әле? Димәк, бу – хәтер бар, юкка чыкмаган дигән сүз.

– Без, чыннан да, хәтерне җуймыйча, истәлекләрне барлап яшәргә тырышабыз. Соңгы елларда Адмиралтействоды үстерүгә Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов, шәһәр башлыгы Илсур Метшин зур игътибар бирә. Безнең микрорайонга алар кат-кат килеп китте. Шәһәрнең иң матур почмагы, гөлбакчасы итү өчен проектлар эшләнде.

:: Бишбалтаның киләчәген ничек күрәсез?

– Мин үзем 2019–2020 елларда Бишбалтаны саклап калу буенча проект эшләп, Министрлар Кабинетына, шәһәр мэриясенә тапшырдым. «Урак һәм Чүкеч» заводының бүгенгә кадәр исән килеш сакланган биналарын, коммуникацияләрен файдаланып, шул урында рус, татар, инглиз, кытай, казах телендә укытылачак халыкара Полилингвистика университеты салу тәкъдиме белән чыктым. «Ефәк юлы» проектын гамәлгә ашыру өчен, белгечләр әзерләүнең иң отышлы юлы шул дип саныйм. «Ефәк юлы» ул Россия, Казахстан, Кытайны тоташтырып торучы күпер булачак. Аны «Адымнар» дип тә атарга мөмкин. Ул Минтимер Шәймиев инициативасы белән оештырылган «Адымнар» урта мәктәбен тәмамлаучылар өчен үзенә күрә бер баскыч булыр иде.

:: Бүген үк тормышка ашыра башларга мөмкин булган хыялларыгыз бармы?

– Клара Цеткин урамында сакланып калган дүрт катлы йортка (элек анда инструменталь цех, техник бүлек, ике китапханә һәм модель цехы булган, хәзер «Пятерочка» кибете) түбәндәге текстлар белән истәлек тактасы куярга тәкъдим итәм.

- «Бирегә 1851–2015 елларда Казан шәһәренең машина төзелеше үзәге – «Урак һәм Чүкеч» («Серп и Молот») заводы урнашкан була».
- «Бирегә Бөек Ватан сугышы елларында «Уран» лабораториясендә СССР атом бомбасын уйлап табучы, академик И.В. Курчатов эшләгән. 1942–1945 еллар».
- «Танкист, капитан, Советлар Союзы Герое В.А. Иовлев 1940 елда «Урак һәм Чүкеч» заводында токарь булып эшләгән».

Мондый гамәлләр Казан читендәге бердәнбер татар авылы Бишбалтаның, димәк, татар халкының да үткәннәрен барлау булыр иде. Тарих битләреннән күренгәнчә, бу төбәктә, чыннан да, эш-гамәлләре белән тирә-якта дан тоткан балта осталары яшәгән. Авылның исеме дә шуннан алынган.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

САНИЯ САФИУЛЛИНА:

«ӨНЕМДӘ КҮРМӘГӘН МАТУРЛЫК ТӨШЛӘРЕМӘ КЕРӘ»

Апас районының Иске Йомралы авылында гомер итүче Сания Сафиуллина бу дөньяны күңел күзләре белән күрә. Маңгай күзең күрмәсә, күңел күзеңне эшкә җик, дип әйтергә ярата ул.

Ә бит кайчандыр ул да башкалар кебек, дөньяның бар матурлыгын күреп яшәгән. Әмма кинәт килеп чыккан авыру аны гомерлеккә күрү сәләтеннән мәхрүм итә. Шулай булса да, бирешми ул. Гаиләсен, балаларын кайгыртып яшәргә тырыша.

– Аллага шөкер, бөтен эшне башкарам. Яраклашасың икән ул. Ашарга да пешерәм, камыр да куям. Мәҗлесләргә дигән бәлешне дә миңа пешертәләр. Балаларым бигрәк тәмле дип ашый, – дип сөйли Сания апа. – Ирем Рифат та ныклы терәк булды. Әгәр аның яратуын тоймасам, яши алыр идемме соң? Без ирем белән дүрт бала үстердек. Мин аңа бик рәхмәтле. Какмады, сукмады, хәлемне аңлап яшәде. Гаилә коруыбызга 50 ел тулды.

Сания апаның моннан 40 ел элек башы авырта башлый. Аның күренмәгән табибы калмый. Тикшеренер өчен кая гына бармыйлар. Бер табиб аның башы авыртуының сәбәбен әйтә: ул күзләргә бәйле була. Ныклап тикшерә башлагач, анда бик сирәк очрый торган авыру барлыгын беләләр. Баксаң, әлеге авыру нәселдән килә икән. Сания апага «пигментная дегенерация сетчатки» диагнозы куела. Шунда ук кисәтәләр дә: күзләрне дәвалап булмаячак.

– Килешмичә нишлисең инде?! Язмышыма язылгач, риза булдым. Димәк, күрәчәгем шул, дип үземне юаттым. Аяк-кулларым эшләгәнгә сөендем. Әмма авыру үзенекен итте. Башта төсләр буталды. Аннары инде начар күрә башладым. Хастаханә юлын яңадан таптадым. Күңел яхшыга өметләнде. Янәсе, ярдәм итүче булмасмы? Тик булмады. 2004 елда миңа инвалидлык бирделәр, – дип сөйли Сания апа.

Ул яктылыкны гына күрә. Әнә шуңа да чиксез сөенә ул.

– Аллаһы Тәгалә миңа яшәр өчен көч бирде. Күрү сәләтем кимегәч, кулларым белән тою яхшырды. Әйтерсең, аларның күзләре бар. Сизү, тоемлау хисем артты. Әнә шулар миңа тормышта югалып калмаска ярдәм итә дә инде, – ди ул. – Минем күңел күзләрем ачылды. Матурлыкны бик яратам. Тәрәзә төбемдә гөлләрне сыйпап, назлап узам. Әйтерсең, мин су сипкәч, яратып узгач, алар миңа елмая. Яраннар күңелемә хуш килә. Аның әллә ничә төрлесен үстерәм.

Сания апа күрмим дигән уйны башыннан алып ташлаган инде. Гаиләсе дә аның кимчелеген сизми. Бар да элеккечә төсле аларда. Балалары «әти», «әни» дип өзелеп торалар. Еш кына Казанга концерт-театрларга алып баралар икән.

– Бөтен артистларны таныйм. Радио тыңлыйм, телевизор карыйм. Ирем бер генә яңалыктан да читтә калдырмый. Өйгә килгән газеталарны кычкырып укый, – ди Сания апа. – Беләсезме, мин өндә күрмәгән матурлыкны төштә күрәм. Төннәр буе гел болыннарда йөрим. Кайчак балачагым узган инеш буйларын, мәктәп бакчаларын күрәм. Тик күңелгә ул гына да җитми кайчак. Әллә кайларга барып кайтасым килә.

Сания апа оста бакчачы да икән әле. Балалары, аның яшелчәләре бигрәк уңа, ди. Баксаң, кишерне дә ул гына сирәкли икән. Әллә ярату тойганга, әллә Сания апаның кул җылысы тигәнгә, алар ел да мул уңыш бирә. Тагын бер шөгыле – Сания апа җырга-моңга оста. Кечкенәдән биергә яраткан, җырлаган да. Гел сәхнәдә булган. Хәзер дә тик тормый: «Асылъяр» фольклор ансамблен җитәкли. Мәдәният йортында эшләүче кызы Резедага гел ярдәмгә атлыгып тора икән.

– Әниемә шаккатам. Аның көчле рухы сокландыра. Берәү булса, мин – авыру, дияр иде. Ә ул башка бик күпләргә, минем үземә дә үрнәк булып, гомер итә, – ди кызы Резеда. – Нинди генә хәл булмасын, әни киңәшен бирә. Аның пешергән ризыкларын ашап туеп булмый. Әнинеке булганга гына түгел ул, җан җылысын, яратуын биреп, яхшы уйлар белән әзерләгәнгә шулайдыр. Әнигә карагач, без зарлануны да оныттык. Исән генә булсын, дибез. Өебезнең нуры бит ул!

БЕР КАРАШЫ ҖИТӘ

Балтач районының Арбор авылында гомер итүче Рания Мостафина әнә шулай ди. Ире Рәмзисне сүзсез дә аңлый ул. Озак еллар бергә яшәп, ияләшү галәмәте генә түгел бу. Рәмзис кечкенәдән берни ишетми һәм сөйләшә алмый. Аларның балачагы гел бергә үтә. Ул чакта бергә буласыларын кем белгән? Рания, мәктәпне тәмамлагач, Казанга укырга китә. Шунда эшкә урнаша.

– Гомеремдә Рәмзискә кияүгә чыгармын димәгән идем. Без аның белән бары тик дуслар гына идек. Бервакыт авылга кайткач, Рәмзис яныма килде дә, ишарәләр белән: «Миңа кияүгә чыгасыңмы?» – ди. Уйнап кына, әйе, дидем.Тик авыздан сүз чыгып очкач, кирегә юл юк иде. Рәмзис эшне тиз тотты. Февраль аенда никах укыттык, мартта туебыз узды, – дип сөйли Рания.

Баскан җирдән ут чыгара торган кызның сөйләшә алмаучы егеткә кияүгә чыкканын аңлап та бетермиләр. Янына килеп: «Телсез кеше белән ничек яшәмәкче буласың?» – диючеләр дә була. «Балаларың сөйләшә алмаса», – дип тә куркыталар. Тик Рания иренең сөйләшмәве нәселдән түгел, каенанасының корсаклы чакта пешүеннән икәнен белә. Шуңа да кеше сүзенә бирешми. Иң мөһиме – Рәмзис тә аның өчен нишләргә белмичә тора, иренең әти-әнисе дә бик җылы кабул итә. Кыз балага күп кирәкме инде?! Ул төп йортта килен булып яши башлый.

– Каенанама бик рәхмәтлемен. Беренчедән, минем өчен нинди акыллы ир үстергән. Икенчедән, нәрсә булса да, әни миңа киңәше, терәк булды. Хәтта кияүгә чыккач, бәби алып кайта алмыйча йөргәндә дә, табиблар, балагыз булмый, дигәндә дә, әни юатты. Табиблар да ялгыша ала, дип тынычландырды. Аның сүзләре хак булды. Мин башта Сәет улымны, аннары Зиннәтне алып кайттым, – ди Рания. – Икенче баламны тапкач, миндә бик көчле депрессия булды. Ике ай урыннан тормадым. Хәтта балага исем кушканда да ятып кына тордым. Мине якыннарым ташламады. Кәүсәрия әни сабыр булган да инде! Улымны берсүзсез карады. Мин ул чакларны бик хәтерләмим дә. Авыруым көчле булган. Әле ярый фельдшерыбыз, уколлар салып, мине дәвалады. Казан хастаханәсенә җибәрмәделәр. Мин аңа бик рәхмәтле.

Ире дә шушы чакта сынала. Ул хатыны өчен өзелеп торганын тагын бер кат исбатлый. Рания үзе дә, безнең мөнәсәбәтләрдә сүзләр артык, ди.

– Рәмзискә теге вакытта ярый әле кияүгә чыгам дигәнмен. Мин – бик бәхетле хатын. Иремнең яратуын тоям. Ул бик игътибарлы. Җәйләрен болыннан бер дә чәчәксез кайтмый. Бәйрәмнәрне исендә тотып, гел мине сөендерергә тырыша. Сөйләшә алмый торган кеше дип әйтмәссең дә аны. Рәмзиснең дусларының күплеге! Бик аралашучан ул. Кулыннан килмәгән эше юк, – ди хатыны. – Әтиебез аны, 18е тулгач, колхозга эшкә урнаштырган. Ул эретеп ябыштыручы булып эшләде. Әле менә соңгы вакытларда сәламәтлеге какшап тора. Тиздән операциягә җыена.

Хатыны Рәмзисне мактаса, ир туганнары киленне зурлый. Раниянең чаялыгын, үткенлеген яраталар икән. Рания үзе дә, бер эштән курыкмыйм, ди.

– Эшләмәгән эшем калмады. Сәүдә өлкәсендә дә, балалар бакчасында да эшләдем. Тегәргә дә өйрәндем, заводка да барып кердем. Бу эшләрем күрше авылларда иде. Юл йөреп арган чагымда, үзебезнең колхоз җитәкчесе: «Рания, әйдә, мал фельдшеры бул әле», – диде. Баштарак куркып калдым. Бер көн дә эшләмәгән килеш, башкара алмам кебек тоелды. Тик җитәкче мине күндерде, – ди Рания. – Теләк булса, өйрәнәсең икән ул. Ике ай дигәндә, мал табибы итеп куйдылар. Тырыштым, үземә кирәген эзләп укыдым. Махсус курслар уздым. Әле бер имтихан вакытында вуз укытучылары дөрес җавап биргәнемә шаккатып, кайда укыдың, диделәр. Мин исә яшермичә: «Белемем юк, тәҗрибәм бар», – дидем. Мине алар югары белем алырга Казанга чакырдылар. Быел 36 яшемдә укырга керергә җыенам.

Раниянең кызларга киңәше дә бар: кияүгә яраткан кешегезгә чыгыгыз, ди ул.

– Иремдә бер генә кимчелек тә күрмим. Аның күңеленең яхшылыгын белсәгез иде! Ике улым әти дип өзелеп тора. Яныннан да китмиләр. Бәхет өчен тагын ни кирәк?! Уйнап әйткән сүзем өчен әле дә сөенәм, – ди Рания.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

vk.com

БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ: ШӘВӘЛИГӘ АЛМАШ БАРМЫ?

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Язучы, мөхәррир **Ләбиб Лерон** Кирләмән, Курай-малай кебек каһарманнар тәэсирендә үскән. «Ни өчен хәзер шундый геройлар тумый?» дигән сорауга ул, хәзер вакытын балалар әдәбиятына гына багышлаган кешеләр юк, дип җавап бирде:

– Советлар иле таркалгач, балалар әдәбиятының сыйфаты төшә башлады. Дөрес, Бари Рәхмәтләрдән килгән, Шәүкәт Галиевтә дәвам иткән, Роберт Миңнуллинда чарланган балалар шигърияте бар, ул дәвам итә әле. Ә менә проза жанры авыр хәлдә. Без Җәүдәт Дәрзаман, Җәвад Тәрҗеманов, Роза Хафизова әсәрләрен укып үстек. Безнең Кирләмәннәр бар иде, балаларга Шәвәлиләр эләкте. Аннары тынлык урнашты. Мин үзем дә төрле эшкә чәчелүем белән балалар әдәбиятыннан читләштем. Кыям ага Миңлебаев: «Ләбиб, сиңа балалар өчен зуррак әсәрләргә тотынырга кирәк», – дип әйтә иде. Чуковскийның Мойдодыры, Успенскийның Кот Матроскины, Шапоклягы кебек образлар иҗат итәргә кирәк иде. Мин шушы фикерне вакытында эләктереп ала алмадым. Әкиятләргә, төрле жанрларга чәчелдем. Әйе, балаларга геройлар кирәк. Юкса балалар өчен әсәр тумый дип тә булмый. Язучылар да бар. Тик күбесе балалар өчен түгел, балачакларын сагынып яза. Мин еш әйтәм аны: без инерция буенча язабыз. Образ тумый, стиль дә үзгәрми кебек. Соңгы елларда балалар әсәрләре өчен конкурслар барлыкка килде, бәлки ул күтәрелешкә китерер.

Татарстан Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе игълан иткән бәйгедә балалар прозасы номинациясендә җиңү яулаган **Лилия Гыйбадуллина** геройлар рус әдәбиятында да тумый дигән фикердә:

– Геройлар рус әдәбиятында да тумый хәзер. Шуңа күрә балалар чит ил мультфильмнары геройлары тәэсирендә үсә. Герой китапта туса да, бала аңына барып җитсен өчен аның медиа киңлеккә чыгуы кирәк. Кызганыч, балаларыбыз ни хәлдә, әдәбиятыбыз да шул хәлдә инде. Мин мәгариф системасына, мәктәпләрдәге укытуга, «Школа России» программаларына бәйле рәвештә деградация бара дигән фикердә. Ике балам да башлангыч сыйныфта укый, боларны үз күзәтүләремнән чыгып әйтәм. Мәктәпләрдә әдәбият, рәсем, музыка дәресләренә игътибар юк дәрәҗәсендә. Укучылар шул ук музыка дәресендә «Учи.ру» платформасында утырырга мөмкиннәр. Чөнки укытучылардан рейтинг сорыйлар. Димәк, мәктәп үзе үк балаларны телефонга утырта. Әдәбиятка урын юк, чөнки ул – уйларга, анализларга, чагыштырырга, тормышка өйрәтә торган фән. Аны кирәксенмиләрдер инде. Шуңа хәзерге балалар әдәбияты менә шул коточкыч тизлектә примитивлашып барган бала аңына яраклашырга мәҗбүр. Ник дигәндә, без укып үскән балалар, үсмерләр әдәбиятын хәзергеләргә укытып булмый.

> Язучыларга балалар әсәре язу намус эше кебек ул. Шуңа без хәзерге балаларга үзебез укып үскән әдәбиятны укытыр өчен күпер ролен үтәргә тиешбез. Бу инде гади әсәрләр тудыру дигән сүз. Анда милләт дигән югары идеяләр, тәрбия мәсьәләләре дә куелмаска мөмкиндер, «татар» сүзенә басым ясамыйча гына татарча укытырга тырышырга кирәктер. Татар теленең хәзерге хәле ул – безнең җәрәхәт, безнең сызлану. Без аны балаларга бирергә тиеш түгел.

Бала татарча укуны гадәти хәл итеп кабул итәргә тиеш. Кибеттә, башка урыннарда татарча сөйләшүгә ул олы мәгънә итеп карарга тиеш түгел, фәкать татарча сөйләшергә тиеш. Мин андый буынны белән дә әле. Туксанынчы елларда Чаллыдагы татар мәктәпләрендә тәрбияләнгән татар балалары бу. Алар урам тәрбиясен дә күргән, татар мәктәбендә дә укыган, шуңа өйдә татарча сөйләшү – алар өчен гадәти хәл. Балалары да татарча сөйләшә. Һәм алар татарча сөйләшүне милләт өчен янам дигән олы мәгънә салмыйча, табигый хәл дип кабул итә. Хәзерге балаларны да шулай үстерергә кирәк. Уйлап карасаң, без бит Тукай китабын да алып укымас идек, әгәр Ләбиб Леронның гади хикәяләрен, Рәшит Бәшәрнең әкиятләрен укымаган булсак. Эчтәлеге дә, морале дә гадиләштерелгән әсәрләр болар. Һәм шулар безне Тукайга әзерләгән. Балалар яраткан геройларга килсәк, төп герой бар инде ул. Шук, бераз гына тәртипсезрәк тә бер татар малае. Дөрес, аның исеме юк. Кара әле, бу хакта уйланганым юк иде...

Язучы **Алмаз Гыймадиев** балаларга китапка караганда виртуаль дөнья күбрәк тәэсир итә дип уйлый:

– Без бала чакта фильмнар бар иде. Баксаң, Россиядә 2000 елдан соң балалар өчен бер фильм да чыкмаган. 20 ел бушлыкта үткән дигән сүз бит инде бу. Безнең буын исә «Электроник маҗаралары», «Чук һәм Гек» кебек фильмнар карап үсте. Димәк, бу вазгыять бөтен ил буйлап бара. Балалар да башка форматка күчеп бетте бит инде хәзер, алар виртуаль дөньяда уйный да, яши дә. Алай дисәң, чит ил әдәбияты балалар өчен геройларны тудырып кына тора. Аларның Поттерлары да, башка супергеройлары да бар. Үзебезнекеләрдән Шәүкәт Галиев, Роберт Миңнуллинны алсак, алар балалар әдәбиятына җаны-тәне белән бирелгән әдипләр иде. Хәзер исә күңелләрен балалар әдәбиятына гына багышлаган кешеләр юк бугай инде ул. Язучылар күп, тик бит алар барысы да олылар өчен язучылар. Галимҗан Гыйльманов, Батулла, Ләбибә апа Ихсанова, мәсәлән – балалар психологиясен нечкә белгән, алар дөньясы белән яшәгән шәхесләр. Хәзер андыйлар юк ни өчендер... Моңа каләм хакының түбән булуы яки бөтенләй булмавы да сәбәпчедер. Балалар өчен язучы яшьләр белән аралашам. «Казан утлары»нда эшләгән дәвердә китапларын чыгарырга да ярдәм иткән булды. Ун ел элек китапның гонорары бар иде әле. «Казан утлары»нда ул чакта Рәфыйк Юныс белән «Ак җилкән» дигән сәхифә дә оештырган идек. Яшьләргә стимул иде инде ул.

Татарстан китап нәшриятының балалар редакциясе мөдире **Айсылу Галиева**, бүгеннән мультфильм төшерерлек әсәр бар, ди:

– Шәвәлиләр тумый икән, димәк, безнең Шәүкәт Галиев, Роза Хафизова кебек авторларыбыз юк. Гомумән, яңа китапларга күзәтү ясасак та, яшь авторлар күренми. Хәзерге заман авторларыннан Илгиз Зәйни, Йолдыз Миңнуллина бар. Таһир Шәмсуаров, Флера Мәрданова да балаларга яза, болар – олы яшьтәге авторлар.

Балалар өчен язучылар элек тә күп булмаган. Үз вакытында Шәүкәт Галиев, Хәкимҗан Халиков булган, сиксәненче елларда Роберт Миңнуллин килгән. Туксанынчы еллардан соң Галимҗан Гыйльманов килде, аннары прозага кереп китте. Айгөл Әхмәтгалиева да балалар хикәяләре белән килеп керде дә аннары прозага күчте. Мөгаен, язучылар арасында да балалар әдәбиятына җитди итеп карамау бардыр инде ул. Балалар әдәбияты белән башлап, аннан зурларга күчкән язучылар шактый.

> Басма табакка карап түләгән заманда, әлбәттә, авторларга күп итеп язып, калын китап бастырып гонорар алу отышлырак. Ә балалар әдәбияты белән акча эшләп булмый. Балалар матбугаты белән дә шул ук хәл.

Шәвәли ни өчен безнең аңга уелып калды? Ул цикл иде. «Яшь ленинчы» газетасында кабатлап бирә-бирә, аны күпме бала укып үсте. Роза Хафизованың «Кирләмән»е белән дә шул ук хәл. Ул «Ялкын» журналында еллар буе басылды, матбугат аша күпме кеше укыды, аннан китап булып басылып чыкты. Хәзер инде матбугатның да, китапларның да тиражы бәләкәй, республиканың бөтен балаларын колачлап ала торган түгел. Берара «Мырау батыр» популярлашты, чөнки Нәкый Исәнбәт әсәре нигезендә телевизион фильм чыкты. Бу җәһәттән, бәлки, «Шаян ТВ» берәр образны танытыр әле.

Хәзер хәл, гомумән, катлаулы. Элек бала өчен китап юаныч булса, хәзер телефон, компьютер. Димәк, китап геройларының да шунда күчүе кирәк. Геройлар тумый, дип зарланып утырып булмый, булганын җиткерә белергә кирәк. Мәсәлән, мин Факил Сафинның «Кырмыска малае»н 7–8 серияле шәп мультфильм итеп күрәм. Кырмыч белән Чикертмән шәп герой булырлар иде. Әлеге әсәр кай ягы беләндер «Лунтик» мультфильмын да хәтерләтә. Шулай ук маҗаралы, кызык.

Шәвәлигә алмаш тусын өчен, күп тә түгел, аз да түгел, балалар әдәбиятының хәлләнеп китүе кирәк. Яңа авторлар һәм геройлар тууга әдәби конкурслар этәргеч булмасмы әле. Алай гына да җитми, татар геройлы фильмнар, компьютер уеннарының да булуы мәҗбүри. Килер бер көн, Поттер кебек экраннарны биләп алган татар каһарманы да туар. Аның өчен киноның да хәлләнеп китүе кирәк шул...

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ЛЮЦИЯ ӘБЛИЕВА

«НАРАТ БАШЫННАН КОРЫЙ»

(ХИКӘЯ)

< Дәвамы. Башы узган елның 30 декабрь санында

– Ә-ә-ә, радиода ич!

Хуҗа хатын радионың тавышын шәбәйтте.

«Басылмады йөрәк ярсулары, басылса да юллар тузаны...»

«И-и-х», – дип сузып җибәрде Вәсимә һәм өстәл өстенә капланып үксергә тотынды. Рәйфә юатырга тырышып караса да, аракы белән кушылган хисләр тыңларга ашыкмады. «Нишләп мин аны башкалар белән бүлешергә тиеш әле? Кыз башым белән инвалидка чыктым. Өйләнешкәндә прастуй хисапчы булып кына эшли иде бит! Читтән торып институтта укыганда, яшь балалар белән авызыбыздан өзеп, булган акчаны аңа тоттык. Хуҗалыктагы бөтен эш минем җилкәдә диярлек. Инде менә тормышлар җиңеләеп, балалар үсеп җиткәндә... Кеше алдында ояты гына ни тора!»

Вәсимә, радио тавышын да уздырып, кычкырып сөйләгәнлектән, Фәрихәттәйнең кергәнен икесе дә сизмәде. «Шакыйм, шакыйм, ишетүче юк», – дип дәгъва белдерә-белдерә, ул ишек төбендәге урындыкка килеп утырды. Рәйфә тиз генә өстәлдәге аракыны шкаф артына шудырды.

– Әйдә, түргә уз, Фәрихәттәй, мактап кына йөрисең!

– Рәхмәт. Вәсиманең сезгә кереп киткәнен күреп калдым да кердем әле.

Шактый гына «күңелләнеп» киткән Вәсимә шаркылдап көлеп җибәрде. «Нәрсә, әллә иремә «яучы» булып килдеңме, Фәрихәттәй?» Бүген генә дөньяга килмәгән Фәрихәттәй, әлбәттә, хатынның нигә аңа кадалганын аңлый иде. Тик сөйләшү килеп чыкмаячагын чамалагач: «Ярый, чыгыйм, башка көнне күрешербез», – дип, урыныннан кузгалды. Артыннан Вәсиләнең бугаз киереп: «Постой, Фәрихәттәй, постой!» – диеп кычкырганын ишетсә дә, туктамады.

***

Зилфәт Сиринәнең хатын берничә тапкыр укыды. Анда артык берни дә язылмаган, бары сеңлесенә күз-колак булып, читкә какмый гына эшкә өйрәтүләрен сораган булып чыкты. Иң кызыгы, хат Сәбилә эшкә килгән вакытта язылган, тик ни өчендер тапшырылмаган иде. Бәлки, кыенсынгандыр. Алай дисәң, хатның эчтәлеген белми ич ул. Әллә белмәгәнгә, тапшырмаганмы? Зилфәт өчен болар караңгы иде. Ни булса да, булгандыр, анысы хәзер мөһим түгел. Күз алдына яшел күлмәк кигән Сиринәне беренче тапкыр күреп, «Яшь наратлар»ны җырлап җибәргән чагы килде. «Яшьлекнең мәгънәсен дөнья мәшәкатьләренә генә кайтарып калдыра башлаганбыз лабаса! Ә мәхәббәт, ярату хисләре белән үрелеп бармаганда аның нинди мәгънәсе бар?»

***

Үзенә генә хас бизәге булган тавышыннан агылган гаҗәеп моң ташкынына ияреп агып китәрлек көчне Аллаһы гына бирәдер. Көллият укучылары арасында үткәрелгән үзешчән сәнгать смотр-конкурсларында Зилфәтне зал белән тын калып тыңлаганда, аның уйлары Сиринә тирәсендә генә булды. Сиринә генә ошатсын, шул җитә! Башкалардан чибәрлеге белән генә түгел, эчке матурлыгы, ихласлыгы, мөлаемлыгы белән аерылып торган кыз борыннан чөеп йөрмәве белән дә үзенә тартып тора иде. Көллият урнашкан эшчеләр поселогының күркәм бакча-паркларында күп булдылар алар. Зилфәт җырлап, Сиринә тыңлап туялмады. Икесенең дә күңелендә «Яшь наратлар» җыры аерым урын билиде. Тик «дус» дигән кысадан чыга алмадылар. Төс-кыяфәте белән Голливуд актерларына охшаган, баянда өздереп уйнап җырлаган Зилфәт тирәсендә, дөрес, башка кызлар да күп бөтерелде. Тик кияүгә чыгар вакыт җиткәч, мәктәп елларында бер аягын өздергән егетне түгел, дүрт саны төгәлләрне сайладылар. Сиринә дә, практика узарга кайткан җиреннән, кияүгә чыгып килде.

Көллиятне тәмамлап, үз авылларына эшкә кайткач, Зилфәтне малчылык буенча хисапчы итеп билгеләп куйдылар. Аш-су хезмәткәрләр курсыннан соң колхоз ашханәсендә эшләп йөргән Вәсимәне туган тиешле апасы димләде. «Кулыннан килмәгән эше юк, менә дигән итеп яшәрсез», – дия торгач, беркөн кинодан соң озатырга китте. Бер ай чамасы капка төбе саклаганнан соң, никах укытып, туй ясадылар. Чынлап та, Вәсимә уңган хуҗабикә булып чыкты. Зилфәтнең әбиләреннән калган иске генә йортка кучкач, атна дигәндә аны танымаслык итеп бизәп тә куйды. Килен сандыгы белән килгән әйберләре әллә ни кыйммәтле-затлы булмаса да, заманына күрә ярыйсы иде. Туйда бүләк иткән стена сәгате белән келәмне дә элеп куйгач, өй эченә байлар кыяфәте керде. Тәрәзә төбендәге гөлләре чәчкәгә күмелгәндә, Вәсимәнең йөрәк астында беренче җимешләре бөреләнде. Башка бик күп парлар кебек, бер-берсенә җайлаша-җайлаша дөнья көтә башладылар. Зилфәт читтән торып, авыл хуҗалыгы институтына укырга керде. Диплом алган елны ике малайлы әти иде инде ул. Тагын өч елдан, бурычка керә-керә, бүрәнәләреннән нарат исе аңкып торган йорт җиткезеп керделәр. Баш хисапчы итеп куйгач, әкренләп бурычларын да түләп бетерделәр. Гаилә акчасы Зилфәтнең үзендә булды, шуңа күрә Вәсимә җаны теләгән әйберләрен алып, килешетереп киенеп йөрмәде. Бигрәк тә йорт салганда, аннан соң да әле берничә ел кысылып яшәргә туры килде. Ә инде өченче баласыннан соң эштән дә киткәч, шикәр-сабынга дигән акчаны да ире санап кына бирде. Башкалардан артык югары күтәрелеп тә, түбәнгә дә тәгәрәми генә, гадәти көннәр аша, тормыш йомгагы сүтелде.

***

– Зилфәт абый, сезне бик матур җырлыйсыз дип ишеткән бар.

– Әйе, әйе, нәкъ өстенә бастың, Сәбилә!

– Әйдәле, Зилфәт, «Яшь наратлар»ны!

Эштән соң баш хисапчының туган көнен билгеләп үтәргә җыелган хезмәткәрләр чәбәкәйләп алдылар. Бу юлы Зилфәт, башка вакыттагы кебек: «Юк, сорамагыз да, булмый», – дип ялындырып тормады. Каршыда утырган Илфиргә ымлау белән, тегесе ялт иттереп баянны китереп тә тоттырды. «И-и-и, әзерләнеп килгән икән үзе дә», – диештеләр өстәл янындагылар. Бүлмә эче илаһи бер моңга күмелгәндә, Зилфәтнең Сәбилә утырган якка карап җырлаганын «мыеклары на чорнап» утыручылар да булды. Авылда «Сәбилә, Зилфәт, Вәсимә» өчпочмагы хакында чыш-пыш хәбәрләр йөри башлаганга да хәтсез генә вакыт үткәнгә, бу бер дә гаҗәп түгел иде, әлбәттә. Дөрес, кемдер бу «чыш-пыш»ларга ышанды, кемдер: «Язмаганны сөйләмәгез инде, әллә нинди асыл егете бардыр әле. Аннан килеп, Зилфәт тә башына тай типкән ир түгел», – дип, кул гына селтәде. Зилфәт хатынының беренче тапкыр Сәбиләдән көнләшеп тавыш чыгарганына исе китмәгән кеше булып кыланса да, чынлыкта исә, бераз эченә курку йөгерде. Бәй, кыз балага күрәләтә яла ягу матур күренеш түгел ич. Ярый ла, Вәсимәсе шул бер белән генә тукталып калса. Юк, уенда да юк. Җае туры килгән саен «чеметеп» алырга гына тора. Сәбиләгә генә ишетелмәсен, гариза язып китеп барырга да күп сорамас. Ә Зилфәтнең аны бер дә яныннан җибәрәсе килми. Яшәү тәме бөтенләй икенче яктан ачылды ич! Иртәннән кичкә кадәр тау җимерерлек көч биргән кыз белән ничек итеп җиңел генә аерылышырга була? Эштән соң өенә кайткач та, элеккечә телевизор каршында утырып, аннан-моннан гына малайларының дәресләренә күз салып алмый ул хәзер. Киресенчә, җентекләп тикшерә, кирәк чагында ярдәм итә. Уртанчы малайларының баян тарткалый башлаганын күргәч, сөенеп, дәресләр бирде. Тик Вәсимәсе генә менә... «Зәмзәм» суы белән шаяруы артыгракка китте кебек. Үзенең әнисе орышкач, бераз туктаган кебек тә булган иде. Тик озакка бармады. Бикләп өйдә тотасыңмыни?! Көн дә бәйрәм, көн дә туй булмаса да, сәбәбе чыгып кына тора. «Урам буенча алкаш хатыннар кебек эчеп йөрмим», – дип, авызны каплый да куя. Бер уйласаң, ул да хаклы кебек. Тик, икенче яктан, урам буенча йөрмәсә дә, «төшергән» килеш йортта аунап ятуы да ачуны чыгара.

– Афәрин!

Бәй, хатынын уйлый-уйлый, җырны тәмамлап та куйган ич! «Кемне уйласаң, шул каршыңа килеп чыгар», – дип кайсы беренче әйткәндер, анысы мөһим түгел. Аның шулай туры килеп торганын тулы рюмкаларны мәҗлес сәбәпчесе исәнлеге өчен чәкештергән мизгелдә тәрәзә пыялаларны зеңләп коелып төшү тагын бер тапкыр исбатлады.

Икенче көнне Вәсимәнең бухгалтерия тәрәзәсен таш атып ватуын бишектәге сабыйлар гына белми калды бугай. Дөресрәге, ишеттеләр, тик сөйләргә телләре ачылмаган булгач, елап көйләделәр. Вакыйганың буяуларын һәркем үзенчә куертты, көн азагында Сәбиләнең чүт кенә күзе чыкмаган булып чыкты. Чынлыкта исә, таш баянны гына «яралаган» иде. Иренең: «Үзеңне кулга алмасаң, исәрләр йортына китеп барганыңны сизми дә калырсың», – дигән сүзләрен кат-кат башыннан кичерә-кичерә, Вәсимә атна буе өеннән чыкмыйча, тәнендәге кара янган җирләре төзәлгәнен көтеп ятты.

***

Фәрихәттәй фатирда торган кызын Зилфәт белән бәйләп сөйләгәннәрен бер дә ошатмады. «Бер егет белән хат алыша бугай үзе, төпченсәң, килешеп бетмәс». Үткән кыш Вәсимә Сәбиләне эзләп килгәч, күңелендә хасил булган төерен бушаталмый хәтсез генә йөрде. Тәвәккәлләп, баштан Сәбиләнең кылын тарткалады. Андый-мондый шикле әйберләр сизмәгәч, Вәсимә белән җаен туры китереп сөйләште.

< Ахыры киләсе санда

Әнвәр ШӘРИПОВ

БИРЕШМӘБЕЗ

Күпме газап чиктек тарихта без,
Искә алсак, шаклар катарлык...
Утта янмас, суда батмас булды
Минем сөйгән халкым, татарым!
Үзәге нык, татар чыныккан ул,
Төшенкелек безгә килешми.
Афәтләрне җиңә-җиңә яши,
Алга бара,
Татар халкы һич тә бирешми.
Ялкын яши безнең йөрәкләрдә!
Ялкын яши, әле сүнмәгән.
Мәңге сүнмәс тә ул: йөрәкләрдә
Эчке ялкын әле бетмәгән.
Без сузмыйбыз зурга өметләрне,
Тыныч яшәп,
Чәчәк атсак әгәр – шул җитә.
Дөнья халыклары бездән
Иң беренче бердәмлек көтә.
Һәр татарның йөрәк ритмы бердәй,
Бергә тибә, бергә берләшә...
Бергә кушсаң йөрәк ритмнарын,
Бөтен дөнья, бәлки, көнләшер...
Телне саклап калу – безнең бурыч,
Саклыйк аны уттан, салкыннан...
Бернинди көч һич тә җиңә алмас
Ихтыярын туган халкымның.

ЧӘКЧӘК

Болгар ханы бервакытны
Улын өйләндергән, ди.
Тәмле ризык әзерләргә!
Шундый әмер биргән, ди.
Ул әр-яңа азык булсын,
Дөньяда тиңсез булсын!
Болгар халкының уңганлык
Символы булып торсын.
Вакытлар узу белән дә,
Үз тәмен югалтмасын.
Чит илгә җибәргәндә дә,
Йөзләрне кызартмасын.
Түгелмәсен, бозылмасын,
Кояштай балкып торсын!
Ат өстендә йөргәндә дә
Ашап барырлык булсын.
Чәкчәк дигән данлы азык
Шул чакта килеп чыккан.
Гасырларны уза-уза,
Бүгенгә килеп җиткән.
Табыннарның яме – чәкчәк,
Татарның даны – чәкчәк!
Татып кара әле чәкчәк, –
Барыннан тәмле чәкчәк!
Эх, нинди тәмле чәкчәк!

ӘНИЛӘР

Гомер буе безне озата бара
Әниләрнең күңел аклыгы.
Тирә-юньгә якты нурлар сибә
Әниләрнең күңел сафлыгы.
Җир йөзендә оҗмах ясый ала
Әниләрнең җылы кочагы.
Бары әни һәрчак сүндермичә
Саклап тора гаилә учагын.
Әниләр бит һәр баласын ала
Үзләренең канат астына.
Әни – изге кеше,
«Оҗмах та бит –
Әниләрнең аяк астында».
Бу дөньяда татып калыйк әле
Әниләрнең күңел җылысын.
Әниләрнең исән булулары
Күңелләрне безнең җылытсын!
Аңардан да зур бәхетләр юктыр, –
Әниләрнең күңел җылысы!

Язучы фикере

Кеше кадере

Бу дөньяда бөтен кеше дә кирәк, һәркемнең – үз урыны, үз вазыйфасы, үз язмышы. Мин шулай дим. Ә танышым килешмәскә итә. Һәр кеше дә кирәкми, кайберләре бөтенләй артык, ялгыш яратылган нәрсәләр, ди. Күпчелегебез кебек гади, надан һәм беркатлы булса, аптырамас та идем. Юк. Бу танышым – бик башлы кеше, әллә кайларда укып чыккан, бөтен яңалыкларны белеп тора. Әле дә минем авызны ябарга маташа:

– Менә Казанның «Пятерочка» дигән кибетендә шундый хәл булган. Бер кеше кибеткә керә дә бер ярты аракы алып, касса яныннан узып китә. Нәрсәдер сизенеп юлына аркылы төшкән каравылчы ханымны төртеп җибәрә дә йөгерә башлый. Шул вакытта моның урлаган аракысы идәнгә төшеп ватыла. Ачы кайгыдан аптырап калган каракны шундук эләктереп алалар...

– Кит әле, тузга язмаганны сөйләмә, – дип бүлдерәм аны. – Шундый сантый кеше буламыни?!

– Була, әлбәттә! – Танышым һаман үзенекен сөйли. – Бу хәл март аенда ук булган инде. Теге каракны күптән түгел генә хөкем иттеләр. Каравылчы ханымга мораль зыян китергән өчен ул адәм биш мең сум акча түләргә һәм өч ел төрмәдә утырырга тиеш дип тапканнар.

Мин ни әйтергә белмичә тел шартлатып кына куям. Сүз әйтеп булмый бу очракта. Тел әйләнми. Ну, ике-өч йөз сум чамасы торган аракыны шулкадәр бәягә төшереп эчү өчен аерым бер талант кирәктер кебек тоела. Эчү... Эчә дә алмаган бит әле, бахыр, төшереп ваткан... Күргән хәсрәте өчен моның үзенә компенсация түләргә була.

– Менә шундый ахмаклар да кирәк дип уйлыйсыңмы инде син, – дип һөҗүм итә танышым. – Аларның да кадерен белергә кирәк дисеңме?

Мин төртелеп калам. Бу очракта һәркемнең «үз урыны, үз вазыйфасы...» дип сайрасаң, бик мескен хәлдә калыр кебек тоеласың. Чынлап та, танышым хаклы микәнни соң, кайбер кешеләр, чынлап та, ялгыш яратылган нәрсәләр микәнни?!

Соңыннан, ялгызым гына калгач, әлеге хәлне кабат күздән үткәрәм. Һәм ни өчендер миллионнар, миллиардлар урлап та бер җәзасыз калучылар керфек читенә дә кагылмаган кебек тоела. Исемнәре дә искә төшкән кебек була. Мин инде артык тирәнгә кермәскә, темадан читкә китмәскә тырышам. Бер шешә аракы, ике-өч йөз сум, биш мең штраф, өч ел төрмә... Бу хәлне март аенда ук булган ди танышым. Ну, бер дә юктан гына бирмәгәннәр бит инде ул җәзаны. Димәк, биш ай буена җентекләп өйрәнгәннәр, тикшергәннәр, бөтен нечкәлекләрен ачыклаганнар... һәм үземне хаклы итеп тоям.

Кирәк!

Кирәк... Әлбәттә, кирәк мондый кешеләр. Бу адәм үзенең бер гамәле белән генә дә әллә күпме кешене биш айлык эш белән, димәк, хезмәт хакы белән тәэмин иткән. Аның кебекләр булмаса, тикшерү органнары, хөкем әһелләре нәрсә белән шөгыльләнер иде? Кемнедер торгарга, хөкем итәргә кирәк ич инде. Шулай булгач, караклар да кирәк. Олы, дәрәҗәле караклар – без карап соклансын өчен, ә менә шундый кечкенәләре – зур бурларны ышыклау өчен.

Әйтәм бит, җәмәгать, бу дөньяда һәрбер кеше кирәк, һәркем – бердәнбер. Һәркайсының – үз урыны, үз йөге, үз язмышы.

Марат КӘБИРОВ

			Немец композиторы / Сыр сорты		Прививка / Ирекле, азат				
									Бик юка, үтә күренмәле япма
			Ачык яшел төстәге минерал		Германия каласы	... Ши Мин			Тележурналист Урмас ...
			Татарстандагы район	Фатих Әмирхан повесте					
	Актер ... Месхи	Грек мифологиясендә сугыш Алласы					Хөснул Вәлиуллин операсы		
		Грузиннарга кардәш халык	Зәңгәр чәчәкле, хуш исле гөл						Драматург ... Камал
					Урта Азия овчаркасы				
		Актер ... Прыгунов	Юка, йомшак, күн						Бер өркәчле дөя
			«Тойота» моделе		Винсент ... Гог				
	... Крид / Шоколад		Хәрби блок						Татарстан вертолеты
				Ышану / Перу каласы					
Индонезия составындагы утрау		Күкнең төньяк ярымшарындагы йолдызлык							
Механиканың бер бүлеге		Пермь краендагы шәһәр			Төче су балыгы				

Рәис Габдулла

30 декабрь санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: нәүрәп, нәүбәт, иприт, Агасси, Куга, Симон, тута, нанду, икс, Нэнси, укра, Алиготе, дайкон, Саташу, сизгер. **Вертикаль буенча:** Юкатан, әләк, эра, Агутин, Рабига, Аксак, силос, патиссон, Инари, пси, ашуг, Риман, Коба, дүрт, шае, тынчу, аеру.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Гыйнвар аенда үзенең бөтен гомерен Тукай районы Мусабай-Завод урта мәктәбендә балалар укытуга багышлаган, бүген Арча шәһәрендә гомер итүче хөрмәтле кешебез – Ильматова Любовь КОНСТАНТИНОВНАның 75 яшьлек күркәм юбилее.

Хөрмәтле Любовь Константиновна! Еллар үткән саен, Сезнең тормышыбызда никадәр кадерле һәм мөһим кеше булганлыгыгызны ныграк аңлыйбыз. Сез биргән белемнәр, сезнең үгет-нәсыйхәтләрегез безгә бүген дә дөрес юлдан тайпылмыйча, гел алга барырга ярдәм итә. Сез һәр укучының тормышына үз өлешегезне керттегез, җан җылыгызны, энергиягезне бирдегез. Ата-аналар белән дустанә мөнәсәбәттә булдыгыз. Безгә, хезмәттәшләрегезгә, төпле киңәшләр бирдегез, авыр вакытларда ярдәм кулы суздыгыз. Гадилегегез белән авыл халкының абруен казандыгыз. Тирән белемегез, тырышлыгыгыз нәтиҗәсендә Россия Федерациясенең атказанган укытучысы дәрәҗәсенә ирештегез.

Сезне чын күңелдән юбилеегыз белән тәбрик итәбез! Сәламәтлек, ак бәхетләр, шатлык-куанычлар гына телибез. Һәрчак укучыларыгызның рәхмәтләрен ишетеп, аларның ярдәмен тоеп яшәгез. Тормыш иптәшегез – Ильматов Аренат Гарифович белән тигезлектә гомер итегез!

Тирән ихтирам белән,
Тукай районы Мусабай-Завод урта мәктәбе коллективы

Газетаның киләсе саны 11 гыйнварда чыга.

ВИКТОРИНА

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 1887 елда Габдрахман Ильяси пьеса яза һәм ул өй шартларында куела. Бу пьесаның исеме нинди була?
А) «Әлдермештән Әлмәндәр»;
Б) «Өч хатын белән тормыш»;
В) «Бичара кыз».

2 Пар машинасын ничәнче елда уйлап табалар?
А) 1999;
Б) 1765;
В) 1761.

3 «Россия җире үз Платоннарын һәм зирәк акыллы Ньютоннарын тудыра ала». Бу сүзләрне кем әйткән?
А) Лев Толстой;
Б) Петр I;
В) Михаил Ломоносов.

4 Нейтралитет ул – ...
А) сугышта, дипломатик конфликтта һ.б. да низаглашучы якларның берсенә дә кушылмау;
Б) Пугачев исемендәге күтәрелешләр;
В) монастырь һәм чиркәү җирләрен дәүләт идарәсенә тапшыру.

Җаваплар: 1) В; 2) Б; 3) В; 4) А.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Индекс П2435
Тираж – 18156 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 201

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+